# ТИРӘН УЙЛАНУ

Алар аякта килеш,утырганда, ятканнары вакыт Аллаһны зикер итәрләр (искә алырлар) һәм күкләрнең һәм җирнең яратылышы турында уйланырлар. (Һәм диярләр ки): “Раббыбыз, Син боларны бушка яратмадың. Син бик Бөексең, безне утның газабыннан сакла!”

(Али Имран сурәсе,191)

www.harunyahya.org – www.harunyahya.net

www.harunyahya.com

**ХАРУН ЯХЪЯ**

# ТИРӘН УЙЛАНУ

**ХАРУН ЯХЪЯ**

# УКУЧЫГА

Бу китапта һәм башка әсәрләрдә дә эволюция теориясенең бетүвенә аерым бер урын бирелүвенең сәбәбе - бу теориянын һәртөрле дингә каршы булган фәлсәфәнең асылында булганлыгы. Яратылуны һәм шулай ук Аллаһның барлыгын инкяр иткән Дарвинизм, 150 ел буенча күп кенә кешеләрнең иманын югалтувына яки кешеләрне шикләндереп, аларның иманнарының какшауна сәбәпче булган. Шуның өчен, бу теориянын бер уйдырма булганлыгын күрсәтү бик әһәммиятле иман вазыйфасы. Бу мөһим хезмәтнең бөтен кешеләргә ирешүве исә катлаулы. Кайбер укучыларыбызның, бәлки тик бер генә китабыбызны уку мөмкинлегенә ия булганлыкларыннан, һәр китабыбызда, кыска булсада, бу темага урын бирелде.

Белгертелергә тиеш булган башка бер хосус, китапларның эчтәлеге белән бәйле. Язучының бөтен китапларында иман белән бәйле булган темалар Коръән аятьләренә курә аңлатыла, кешеләр Аллаһның аятьләрен өйрәнергә һәм шулар буенча яшәргә чакырыла. Аллаһның аятьләре белән бәйләнгән темалар укучының асылында һичбер шик яки сорау калдырмыячак формада аңлатыла.

Бу аңлатылу вакытындагы җитди, гади, тоташ ысул китапларның җиде яшеннән алып җитмешкәчә булганнарга, ягъни һәркем тарафыннан җиңел аңлашувна сәбәпче була.

Бу китаплардагы тәэсирле һәм ячык аңлату рәвеше аларны “бер сулышта укылган китаплар” рәтенә кертә. Хәтта динне кискен рәвештә инкяр иткән кешеләрнең дә, бу китапларда аңлатылган хакыйкатьләрдән тәэсирләнүве һәм аңлатылганнарны инкяр итә алмауларпы күренә.

Бу китап һәм язучының башка әсәрләре укучының барытик үзе тарафыннан укыла алганы кебек, җыелма хәлдә дә укылырга мөмкин. Бу китаплардан файдаланырга теләгән бер группа укучыларның берләшеп, җыелышып китапларны укулары, тема белән бәйле булган үзләренең фикерләре һәм тәҗрибәләре белән уртаклашувы ягыннан файдалы булачак.

Моның белән бергә, барытик Аллаһнын ризасы өчен генә язылган бу китапларны таныту һәм аларның укылувын булдыру бөек бер хезмәт булачак. Чөнки язучының бөтен китаплары исбатлау һәм ышандыру ягыннан гаять көчле. Шул сәбәпле, динне аңлатырга теләгәннәр өчен иң тәэсирле ысул – бу китапларны башка кешеләр тарафыннан укуга этәрү.

Китапларның артында язучының башка әсәрләрен таныткан булек булганлыгының мөһим сәбәбе бар. Аның аркылы, бу китапларны кулына алган кеше, югарыда сүз ителгән сыйфатларга ия булган һәм сәяси темаларда файдалана алачагы бай бер китап көллиятенең булганлыгына шаһит булачак.

Бу әсәрләрдә, башка кайбер әсәрләрдәге кебек, язучының шәхси фикерләрен, шикле урыннардан алынган аңлатмаларны, изгелекне ихтирам итмәгән начар әхълакны, ихтирамсыз ысулларны, өметсезлек бирүче, шикле аңлатмаларны тапмаячаксыз.

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ӘСӘРЛӘРЕ ХАККЫНДА

Харун Яхъя псевдонимын кулланучы язучы Аднан Октар, 1956 елда Анкарада туды. Башлангыч, урта мәктәп белән бергә лицейны Анкарада тәмамлады. Аннан соң Истанбулдагы Мимар Синан университетының гүзел сәнгатьләр факультетында һәм Истанбул университеты фәлсәфә бүлегендә белем алды. 1980 нче еллардан алып хәзерге көнгәчә иман, фән һәм сәясәт белән бәйле бик күп әсәрләр хәзерләде. Болардан тыш, язучының эволюционистларның яңлышлыкларын, идеологияләренең уйдырма икәнлеген һәм Дарвинизмның "канлы" идеологияләр белән бәйле булганлыгын фаш итүче бик күп һәм мөһим әсәрләре бар.



Харун Яхъяның әсәрләре якынча 30 000 рәсемнән һәм тулаем алганда 45 000 биттән торган бер көллияткә керә. Һәм бу көллият 60тан артык телгә тәрҗемә ителгән. Язучының псевдонимы инкярчыларга, аларның, фикерләренә каршы көрәшкән ике пәйгамбәрне хәтерләтеп, аларга хөрмәт йөзеннән Харун һәм Яхъя исемнәреннән тора. Язучы тарафыннан китапларның тышлыгында Аллаһ рәсүле (с.а.в.)нең тамгасы кулланылган булувы исә, китапларның эчтәлеге белән бәйле. Бу тамга Көрьәни-Кәримнең Аллаһның соңгы китабы һәм соңгы сүзе, пәйгамбәребез (с.а.в.) нең исә соңгы (Хатәмүл әнбия) пәйгамбәр икәнлеген мөһерли.

Язучы бөтен әсәрләрендә Көрьәнне һәм Аллаһ Рәсүленең сөннәтен юл күрсәтүче итеп алган. Шулай итеп, инкярчылыкка корылган барлык фикри системалар тарафыннан фундаменталь буларак якланган претензияләрне бөтенләй сүзсез калдырып, соңгы сүз әйтүне максатлаган һәм камиллек иясе булган Аллаһ рәсүленең тамгасы, бу соңгы сүзне сөйләү ниятеннән язучы тарафыннан бер дога буларак кулланылган.

Язучының бөтен әсәрләрендәге асыл максаты - Көрьән тәблиген (чакырувын) Дөньяга ирештерү, шуның аркылы кешеләрне Аллаһның барлыгы, берлеге һәм Ахирәт кебек асыл, иман белән бәйле булган хакыйкатьләр турында уйлануга этәрү һәм инкярчы системаларның черек һәм ялган уйдырмаларын фаш итү.

Харун Яхъяның әсәрләре Һиндыстаннан Америкага, Англиядан Индонезияга, Польшадан Босния-Герцеговинага, Испаниядан Бразилияга, Малайзиядан Италияга, Франциядан Болгарияга һәм Россияга кадәр Дөньяның бик күп илләрендә яратылып укыла. Инглиз , француз, алман, итальян, испан, португаль, урду, гарәп, албан, рус, уйгур, Индонезия, Малайзия, бенголи, кытай, кишваһили (Танзания теле), һауса (Африкада таралган тел), дһивелһи (Мавританияда кулланыла), Дания һәм Швеция кебек бик күп телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләрдән һәм алар чит илләрдә күп кенә китап укучы тарафыннан күзәтелеп бара.

Бөтен Дөнья буенча күп кешеләр тарафыннан укылган, көтеп алынган бу әсәрләр, бик күп кешенең иман итүвенә, бик күбесенең дә иманнарының көчәюенә, артувына вәсилә булып тора. Китапларны укыган, җентекләгән һәркем бу әсәрләрдәге хичакрымәтле, үзенчәлекле, җиңел аңлашылучан һәм җитди ысулның, акыллы һәм фәнни алымнарның барлыгына шаһит була. Бу әсәрләр дәвамлы тәэсир, кискен нәтиҗә бирү, инкяр ителә алмау сыйфатларына ия. Бу әсәрләрне укыган һәм алар турында җитди буларак уйланган кешеләрнең, материализм фәлсәфәсен, атеизм һәм башка яңлыш карашларны һәм фәлсәфәләрне җитди буларак яклауларын дәвам итүләре мөмкин түгел. Чөнки язучының әсәрләре аларның фикри нигезләрен юк итә, черетә. Моннан соң шундый карашларны һәм фәлсәфәләрне яклауны дәвам итү бары тик эмоциональ киреләнү, эмоциональ кабул итмәү сәбәпле генә булырга мөмкин. Заманыбыздагы бөтен инкярчы агымнарның Харун Яхъя көллияте каршында, үзләренең яраксыз икәнлекләрен күрсәтү белән бергә, җиңелеп барганлыклары күренә.

Һичшиксез, бу сыйфатлар Көръәннең хикмәт һәм камил аңлату үзенчәлекләренә ия булганлыгыннан килә. Язучы үзенең әсәрләре белән мактану халәтендә түгел, барытик кешеләрне Аллаһның тугъры юлына, хакыйкатькә эндәргә генә ниятле. Басылган һәм таралган әсәрләреннән матди мәнфагать күрми, андый максатлардан саклана. Күп хакыйкатьләрне ирештерүче, кешеләр күрмәгән нәрсәләрне күрсәтүче, кешеләрнең тугъры юлны табуларына вәсилә булучы бу әсәрләрнең укылувына сәбәпче булу бик әһәммиятле бер хезмәт икәнлеге аңлашыла.

Бу кыйммәтле әсәрләрне тарату урынына, кешеләрнең зиһенләрен бутаган, фикер буталчыгы яралдырган, шик һәм шөбһәләрне таратуда, иманны коткаруда көчле һм кискен тәэсире булмаганлыгы гомуми тәҗрибә белән расланган китапларны тарату исә, көч һәм вакыт югалуга гына сәбәпче булачак. Иманны коткару максатыннан башка, язучысының әдәби көчен белдерүгә юнәлгән әсәрләрдә дә, бу тәэсирнең була алмаячагы ачык күренә.Бу мәсьәләдә шикле булганнар, Харун Яхъя әсәрләренең бердәнбер максаты  динсезлекне черету һәм Көръән әхлагын тарату булганлыгын, бу олы хезмәтендәге тәэсирнең, уңышлы булуның һәм җитдилекнең ачык буларак куренувен укучыларның гомуми хуплауларыннан аңлый алалар.

Белергә кирәк, җир йөзендәге золым һәм буталчыкның, мөселманнар чиккән изаларның төп сәбәбе – динсезлекнең фикри хакимияте. Болардан

котылуның юлы исә, динсезлекнең фикри яктан җиңелүве, иман хакыйкатьләренең ирештерелүве һәм Коръән әхлагының кешеләр аңлап яши алырлык формада аңлатылувы булып килә. Дөньядагы һәркөн артып баручы золымга, әхлаксызлыкка һәм буталчыкка игътибар ителгәндә, бу хезмәтнең булдыра алынган кадәр тиз һәм тәэсирле булырга тиеш икенлеге аңлашыла. Киресенчә булганда бик соңга калынырга мөмкин.

Бу мөһим хезмәттә баш рольга ия булучы Харун Яхъя көллияте, Аллаһның теләге белән, 21 нче гасыр кешеләрен Көръәндә белдерелгән хозур һәм салыхка, дөреслек һәм гаделлеккә, гузәллек һәм сәгадәткә ирештерүгә вәсилә булачак.

Бу китаптагы кулланылган аятьләр Али Булачның “Көръәни-Кәрим һәм төрекче аңлатмасы” исемле хезмәтеннән алынды

1. Басма: сентябрь 1999
2. Басма: июль 2002
3. Басма: сентябрь 2005
4. Басма: май 2006
5. Басма: январь 2010

ARAȘTIRMA
YAYINCILIK
Talatpașa Mah. Emirgazi Caddesi
Ibrahim Elmaz Ișmerkezi
A blok Kat 4 Okmeydani Istanbul
Tel (0212) 222 00 88

Baski: Entegre Matbacilik
Sanayi: Cad. №: 17 Yenibasna-Istanbul
Tel (0212) 451 70 70

AHMED ISA group тарафыннан Аллаh ризасы өчен тәрҗемә ителде һәм хәзерләнде. Безгә бу китапны хәзерләүдә бик ярдәме тигән иманлы сеңелебезгә аеруча рәхмәтлебез.

# Эчтәлек

Кереш суз.........................................................................10

Тирән уйлану......................................................................13

Кешеләр гомумән ниләр турында уйланыр?....................20

Уйлануга киртә булган сәбәпләр ниләр?..........................23

Уйланырга тиешле булганнар...........................................31

Көръән аятьләре өстендә уйлану......................................63

Нәтиҗә.................................................................................73

Эволюция ялганы.............................................................74

# Кереш сүз

Дөньга килер алдыннан юк булганыгызны һәм юк булган килеш бер мәлдә бар булганыгызны һич уйладыгызмы?

Өегездә һәркөн күргәнегез чәчәкнең ничек итеп тә кап-кара, балчыклы туфрактан, мускус кебек хуш ис чыгарып, төрле-төрле төстә чыгувы турында уйландыгызмы?

Тирәгездә очып сезне гел рәхәтсез итүче черкинең, ничек итеп тә үз канатларын без күрә алмаслык дәрәҗәдә хәрәкәт иттергәне турында һич уйландыгызмы?

Банан, карбыз, кавын, апельсин кабыкларының сыйфатлы этикетка вазыйфасын үтәгәнен, бу җимешләрнең тәмләре һәм исләре саклансын өчен хас буларак бу этикеткалар эченә пакетланганы турында һич уйландыгызмы?

Төн уртасында, йоклаган вакытыгызда бермәлдә килеп чыккан җир тетрәвенең,яшәгән шәһәрегезне, өегезне, эш урыныгызны җир белән бер итә алачагын, дөньяда ия булганыгыз һәрнәрсәне берничә секунд эчендә югалта алачагыгызны һич уйладыгызмы?

Тормышыгызның зур тизлек белән үткәнен, бер көнне зәгыйфьләнеп карт булачагыгызны, матурлыгыгызны, сәламәтлегегезне, көчегезне югалтачагыгызны һич уйладыгызмы?

Бер көнне, сез көтмәгән бер мәлдә Аллаһның вазыйфалы үлем фәрештәләрен каршыгызда күреп, бу дөньядан аерылып китәчәгегезне һич уйладыгызмы?

Кешеләрнең кыска вакыттан соң ташлап китәчәкләре бу дөньяга нидән бу кадәр көчле багланулары һәм асыл тырышлык күрсәтүләренең Ахирәт өчен булырга тиешлеге турында һич уйландыгызмы?

Кеше Аллаһ тарафыннан яратылган һәм үзенә фикерләү сәләте бирелгән бер барлык. Шулай ки, кешеләрнең күпчелеге бу бик мөһим сәләтне кирәктергәнчә кулланмый. Хәтта, әлегә хәтле һич тә һич уйланмаган кешеләр бар дип әйтә алабыз.

Югыйсә, һәркеше үзе дә белмәстән бер фикерләү потенциалына ия. Кеше бу потенциалны куллана башлавы белән, ул көнгә хәтле күрелмәгән бик күп хакыйкатьне күрә башлар. Уйлануда тирәнләшә-тирәнләшә фикерләү потенциалы да үсәр һәм бу һәркем өчен мөмкин булган нәрсә. Ләкин, бу ноктада әһәммиятле булганы, кешенең “уйлануны” кирәк дип табувы. Кулыгыздагы бу китапның максаты да, “кирәгенчә уйлануга” чакыру һәм “кирәгенчә уйлануның” юлларын күрсәтү. Чөнки уйланмаган кеше хакыйкатьләрдән бөтенләй ерак калачак, яңлышлар һәм ялганнар арасында тормышын сөрдерәчәк. Моның нәтиҗәсендә дә, дөньяның яратылу максатына һәм үзенең җир йөзендә бар булувы максатына төшенмәячәк. Югыйсә, Аллаһ һәрнәрсәне билгеле максат белән яраткан. Бу хакыйкать Көръәндә шулай белдерелгән:

***Без күкләрне, җирне, һәм икесе арасында булганнарны бер "уен яки кәеф-сафа" булсын дип яратмадык. Хак шул гына ки, Без аларны яраттык. Ләкин аларның күбесе белмәсләр.*** (Духан сүрәсе, 38-39)

***Безнең сезне буш максат белән яратканыбызны һәм чыннан да Безгә кайтарылып китерелмәячәгегезне исәпләдегезме?*** (Мүэминүн сүрәсе, 115)

Шуның өчен, һәркеше башта үзенең, аннан соң галәмдә күрелгән һәрнәрсәнең һәм тормышы буенча каршылашылган һәр вакыйганың яратылу максатларын уйларга тиеш. Уйланмаган кеше хакыйкатьләрне барытик үлгәч, Бөек Раббыбыз булган Аллаһның хозурында хисаб бирелгәндә генә аңлар, ләкин инде бик соң булыр.

***Ул көнне җәһәннәм дә китерелгән. Кеше ул көнне уйланып хәтерләр, ләкин (бу) хәтерләүдән аңа ни файда?***

***Дияр ки: "Әгәр тормышым өчен (алдан берәр нәрсәләр) хәзерләгән булса идем."*** (Фәҗер сүрәсе, 23-24)

Аллаһ безгә бу дөнья тормышында форсат биргән килеш уйланувыбыз һәм уйлаганнарыбыздан нәтиҗә чыгарып хакыйкатьләрне күрүвебез, Ахирәт тормышыбызда безгә олы казаныш китерәчәк. Шуның өчен Аллаһ илчеләре һәм китаплары аркылы бөтен кешеләрне үзләренең һәм бөтен галәмнең яратылышы хаккында уйлануга чакырган. Аятьтә шулай боерыла:

***Үзләре турында уйланмыйлармы? Аллаһ хак буларак һәм билгеләнгән бер вакыт (әҗәл) белән күкләрне, җирне һәм бу икесе арасында булганнарны яратты. Чыннан да, кешеләрнең күбесе Раббыларына кавышуларын инкар итә.*** (Рум сүрәсе, 8)

## Аднан Октарның (Харун Яхъя) 2008нче елның 15нче март көнендә Ахи ТВдагы (Кыршәһир) туры эфир репортажыннан...

**Аднан Октар:** Харун Яхъя әсәрләре иң башта иман хакыйкатьләрен максат буларак алган, иман хакыйкатьләренең әһәммиятенә игътибар иткән әсәрләр. Чөнки кешеләргә берәр нәрсә тәкдьим итәр алдыннан, башта аларның иманнарының куввәтләнүве бик әһәммиятле. Бик көчле иман ияләре булулары мөһим. Көчле иман өчен дә иман хакыйкатьләре бик әһәммиятле. Ягъни яратылыштагы Аллаһның хәйран калдыручы нәрсәләре. Аллаһ "уйланмасლармы, акылланмаслармы" дияр еш-еш Көръәндә - шәйтаннан Аллаһка сыенам . Бу тема изге, бөек ислам галимнәре тарафыннан бик әһәммият белән телгә алынган тема. Бик бик әһәммиятле тема...

***Ул ки, сезне туфрактан, соңыннан бер тамчы судан, соңыннан бер "аляктан" (эмбрионнан) яратты; соңыннан сезне бер бәбәй буларак чыгара, соңыннан көчле***

***(балигъ) чагыгызга ирешүвегез, соңыннан да картаювыгыз өчен сезгә (билгеле бер гомер бирә). Сездән кайберләрегезнең гомеренә тагын да алданрак соң бирелә; исеме билгеле бер әҗәлгә ирешүвегез һәм бәлки акылыгызны куллануыгыз өчен (Аллаһ сезне болай яшәтер). Терелтүче һәм яшәтүче Ул  (Аллаһ). Бер нәрсәнең булувын теләсәсә, аңа барытик: "Бул" дияр, ул да шунда ук булыр.***

**(Мүэмин сүрәсе, 67-68)**

# Тирән уйлану

Куп кенә кеше “тирәнтен уйлану” өчен башын ике кулы арасына алуны, берәр булмәгә, хәтта бер төрле уйлану бүлмәсендә калуны, ботен кешеләрдән һәм вакыйгалардан читләшүне,качуны күз алдына китерер. Хәтта “тирәнтен уйлануны” шул кадәр зурайтып күзаллар ки, узе өчен моны була алмас дип зан кылар, моны барытик кайбер галимнәр, фәлсәфәчеләр, бөек кешеләргә генә хас дигән нәтиҗә ясар. Югыйсә, Аллаһ кешеләрне уйлануга чакыра һәм ***“(Бу Көръән,)Аятләре өстендә яхшы-яхшы уйлансыннар һәм чиста акыл ияләре үгет алсыннар дип сиңа иңдерелгән изге китап”*** (Сад сүрәсе,29) аяте белән Көръәннең кешеләргә уйланулары өчен иңдергәнен белдерер. Иң мөһиме,кешенең уйлану сәләтен җитди буларак камилләштерүве, уйлануда тирәнләшүведер.

Бу темага игътибар итмәгән кешеләр исә, гомеләрен тирән гафләт өчендә кичерер. Гафләт сүзе “онытмыйча мөһимсенмәу, ваз кичү, хаталану, игътибарсызлык күрсәтү” мәгънәсенэ туры килә. Уйланмаган кешеләрдә булучы гафләт хәле дә, яратылу максатларын һәм дин белдерүче хакыйкатьләрне онытү һәм боларны белгән хәлдә мөһимсенмәүнең нәтиҗәсе. Ләкин, бу кеше өчен югары дәрәҗәдә куркыныч һәм соңы җәһәннәм белән бетуче бер юл. Шуңа күрә, Аллаһ кешеләрне гафләткә кермәүләре өчен болай искәртә:

***Раббыңны иртән-кич үзеңнән, югары булмаган тавыш белән, өркеп, ялвара-ялвара һәм эчтән-эчтән зикер ит (исеңә тошер). Гафләттә булучылардан булма .***(Агъраф сүрәсә,205)

***Эш(нең) хөкемгә бирелеп бетәчәге хәсрәт коне белән аларны кисәт; алар гафләт өчендәләр һәм алар инанмыйлар.*** (Мәрьям сурәсе,39)

Көръәндә уйланып, вөҗданы белән хакыйкатьләрне күрүче һәм шул сәбәпле Алаһтан куркып, сакланучы кешеләрдән хәбәр бирелә. Һич уйланмыйча, ата-бабаларыннан күргәннәре яңлыш инану һәм фикерләргә сукырларча ияреп баручыларның исә, хаталы икәнлекләре белдерелә. Әмма, кирәгенчә уйланмаганнары өчен Аллаһтан куркып, сакланып узтотышларын төзәтмәсләр. Астагы аятьләрдә уйланмаучы бу кешеләрнең зиһеннәрендә булганнар турында шулай хәбәр ителә:

***Әйт ки: “Әгәр белсәгез (әйтегез), җирйөзе һәм эчендә булганнар кемнеке?” “Аллаһныкы”,- диячәкләр. Әйт ки: “Янә дә үгет алып уйланмаячакмысыз?” Әйт ки: “Җиде күкнең Раббысы һәм бөек Аршның (тәхетнең) Раббысы кем?” “Аллаһ”,- диячәкләр. Әйт ки: “Янә дә сакланмаячакмысыз?” Әйт ки: “Әгәр белсәгез (әйтегез),***

***һәрнәрсәнең мөлке (мал һәм идарәсе) кемнең кулында? Ки Ул,сакласа да, узе сакланмый." "Аллаһтыр",- диячәкләр. Әйт ки: "Шулай исә, сезгә ни була да, бозымга биреләсез (бозымланган кебексез)?" Юк, без аларга хакны китердек, ләкин алар чын ялганчылар.*** (Мүэминүн сүрәсе,84-90)

## Уйлану кешеләрдәге "бозымны" юк итәр

Аятьләрдә Аллаһ кешеләргә: ***"Шулай исә, сезгә ни була да, бозымга биреләсез (бозымланган кебексез)?"***- дип сорый. Аятьтәге "бозым" сүзе, кешеләрне туплы хәлдә тәэсире астына алган зиһни, фикри йокыга, оешканлыкка ишарәт итә. Уйланмаган кешенең акылы оешыр, күреше томаланыр, ягъни күз алдындагы хакыйкатьләрне күрмәгән кебек хәрәкәт итәр, фикер йөртүве зәгыйфьләр. Бик ачык аңлашылган нәрсәне дә аңлый алмаслык дәрәҗәгә килер. Якын тирәсендәге булган могҗизалы вакыйгалардан гафил, хәбәрсез булыр. Вакыйгаларның иң мөһим нокталарын курмәс, абайламас. Кешеләрнең меңнәрчә еллардан бирле гафләт эчендә булуларының, нәселдән нәселгә мирас кебек күчкән тирән уйланудан бик ерак икәнлекләренең төп сәбәбе, чыганагы да менә бу оешканлык, фикри йокы.к уйланмаслар.

Бу җәмгыяви хәлдәге бозымның тәэсирләреннән берсен шундый үрнәк аркылы ачыклый алабыз:

Җирйөзенең асты бөтенләй магма дигәнебез бер "ут катламы" белән капланган. Җирйөзенең кабыгы бик нечкә, ягъни бу ут безгә бик якын, хәтта аягыбыз астында! Җирйөзе кабыгының ни кадәр нечкә икәнлеген аңлавыбыз өчен шундый чагыштырма бирә алабыз: җирйөзе кабыгыгының нечкәлеге бөтен дөньяга карата, алма кабыгының бөтен алмага карата нечкәлектә.

Җирйөзе астындагы югары температурадагы кайнаган кысымнар турында барысы да белә, ләкин кешеләр моның турында бик уйланмый. Чөнки бу кешеләрнең ата-аналары, туганнары, якыннары, иптәшләре, күршеләре, укыган гәҗитләренең язучылары, телевизор тапшыруларын алып баручылары, университеттагы укытучылары да моның турында уйланмас бит.

Без сезне болар турында бераз уйландырыйк. Бер кешенең хәтере югалганын һәм тирә-юнен таныргa тырышуын кузаллыйк. Бу кеше иң элек кайда икәнлеген сораячак. Аңа ул баскан туфракның астында ук ут-ялкынлы, кайнаучы бер массаның бар икәнлеге, куввәтле бер тетрәү аркылы яки янартау (вулкан) шартлавында боларның җирйөзенә чыга алачагы сөйләнсә,ул ни уйлар? Бераз алгарак китийк һәм бу кешегә дөньяның ни бары кечкенә генә бер планета булганлыгын, галәм диелгән чиксез, караңгы бушлыкта очканлыгын да аңа хәбәр

иткәнлегебезне тасвирлыйк. Космоста җир астында бар булган куркынычлыклардан тагын да хәтәррәкләре һәм масштаблыраклары бар. Үрнәге: тоннарча авырлыктагы күкташлары (метеоридлар). Боларның дөньяга юнәлмәүләре, бәрелмәүләре өчен дә һичбер сәбәп юк. Әлбәттә ки бу кеше үзенең шундый бик куркыныч халәтен бер мизгелгә дә исеннән чыгармас. Мондый куркыныч хәлдә, "җепкә бәйләнгән килеш" кешеләрнең ничек иттереп яшәгәннәрен җентекләр. Һәм кимчелексез бер система барлыкка китерелгәненә төшенер.Үзе яшәгән планетасының эче бөек куркынычлык белән тулы, әмма бу куркынычлыкның һәр мизгелдә кешеләргә зыян китерүве бик нечкә пропорцияләр белән туктатылган. Менә моңа төшенгән кеше, дөньяның һәм җир йөзендәге бөтен җанлыларның Аллаһның теләге белән, Ул барлыкка китергән кимчелексез система сәбәпле яшәгәннәрен һәм иминлек эчендә барлыкларын дәвам иткәнләрен дә ачык буларак аңлар.

Бу үрнәк кешеләрне уйландырырга тиешле үрнәкләрнең миллионда,  хәтта миллиардта берсе генә. Гафләтнең кешенең уйлау, төшенү сәләтенә ничек тәэсир итувен, кешенең зиһни, акыл мөмкинчелекләрен ничек чикләгәнен аңлар өчен тагын бер үрнәк китерүдә файда бар:

Кешеләр дөнья тормышының зур тизлек белән үткәнен, бетәчәген беләләр, ләкин моңа карамастан, үзләрен һич бу дөньядан аерылмаячак сыман тоталар. Тормышларында һич тә үлем юк сыман. Менә бу - нәселдән нәселгә күчүче бозым төре.Хәтта моның шундый көчле тәэсире бар ки, берәр кеше үлем турында сөйләшсә, кешеләр үзләрендә булган бозымның бетүвеннән һәм хакыйкатьләр белән кара-каршы килүдән соңгы дәрәҗәдәге курку күрсәтеп бу теманы шунда ук яптырырлар.Бөтен тормышларын яхшы берәр өй, вилла яки машина алу, балаларын иң яхшы колледжларда укытыр өчен багышлаган кешеләр, бер көн килеп тә үләчәкләрен һәм үзләре белән ни машиналарын, ни өйләрен, ни баларын да алыйп китә алмаячакларын уйларга теләмәсләр. Чыгыш буларак үлемнән соң булган Ахирәт тормышы өчен тырышу,берәр нәрсәләр хәзерләү урынына, уйланмауны сайларлар. Югыйсә, һәр кеше иртә ме соң мы әлбәттә үләчәк. Һәм үлгәннән соң һәр кеше өчен, иман иткән булсын яки булмасын, мәңгелек, соңсыз тормыш башлаячак. Бу мәңгелек тормышның җәннәттә яки җәһәннәмдә булувы исә, бу кыска, фани тормышта эшләнелгәннәргә бәйле. Бу хәтле ачык бер хакыкать булган хәлдә, кешеләрнең һич үлем булмаган сыман шундый узтотышларының бердән бер сәбәбе исә, уйланмаганнары өчен өстләрендә хасил булган бу бозымдыр. Ләкин, бу дөнья тормышында уйланып бу бозымнан, башкача әйткәндә, гафләт хәленнән котылмаган кешеләр, үлгәннән соң хакыйкатьләрне үз күзләре белән күреп аңлыячаклар. Бөек Раббыбыз булган Аллаһ бу хакыйкатьне шулай хәбәр итә:

***Ант ки, син монардан гафләт эчендә идең; инде Без дә синең өстендәге пәрдәне ачып күтәрдек. Инде бүген карашларың кискен.*** (Каф сүрәсе, 22)

Аятьтә дә белдерелгәнчә, уйланмау сәбәпле томаланган, буланыкланган караш, үлгәннән соң Ахирәттәге хисап заманында “кискенләшәчәк”.

Шуны да белдерергә кирәк, кешеләр үзләрен белә-белә шушындый бозым тәэсиренә дучар итә. Шулай итеп рәхәт тормыш итәчәкләрен хисапларлар. Югыйсә, асыл рәхәтлек, хозур, кәеф һәм комфорт барытик шул акылны каплаучы бозымның бетуве белән генә казанылa. Өстәвенә, кешенең бер мизгелдә карар алып, өстендәге бу зиһни оешыклыктан,йокыдан котылувы, ачык бер аңлаеш белән тормыш башлавы бик җиңел. Аллаһ моның чишелеш юлын кешеләргә күрсәтә. Уйланган кешеләр бу бозымны дөнья тормышларында булганнары хәлдә бетерә ала. Болай итеп алар вакыйгаларның бер максаты һәм эчтәлеге булганлыгын аңларлар һәм Аллаһ тарафыннан һәр мизгелне яратылучы хикмәтләрне күрә алырлар.

## Кеше һәрзаман һәм һәрҗирдә уйлана ала

Уйлануның вакыты, җире һәм шартлары юк. Кеше йөрегәндә, эшенә барганда, машина йөрткәндә, дуслары белән утырганда, компьютерда эшләгән вакытында, телевизор караганда, ашаганда уйлана, фикерли ала.

Үрнәге, машина белән барганда урамдагы йөзләрчә кешеләрне күрергә мөмкин. Бу кешеләргә карауучы кеше күп нәрсә турында уйлана ала. Күрелгән йөзләрчә кешеләрнең физик күренешләре бер-берсеннән бөтенләй аермалы икәнлеге акылына килә ала. Бу кешеләр бер-берсенә һич тә охшамаган. Кешеләрнең күп очракта күз, каш, керфек, кул, аяк, авыз, борын кебек бер үк органнарга ия булуларына карамастан, бер-берсеннән бу кадәр аермалы булулары шаккатырлык дәрәҗәдә. Тагын да бераз уйланувын дәвам итүче кеше шуларны хәтерләр: меңнәрчә еллардан бирле Аллаһ миллиардларча кешеләрне бер-берсеннән бөтенләй аермалы буларак яраткан. Шиксез, бу ачык рәвештә Аллаһның барлыгын курсәтер һәм Аның өстен ярату сыйфатын чагылдырыр.

Күп кенә кешенең каядыр барып җитәргә теләгәннәрен күрүче кеше, тагын да күп төрле уйларга тагылып калырга мөмкин. Беренче караштa бу кешеләрнең һәрбересе аерым шәхес, кеше буларак күренә алувы мөмкин. Һәммәсенең үз дөньясы, теләкләре, планнары, яшәу рәвешләре, шатлыклары, кайгалыры, ләззтләре, зәвыклары бар. Ләкин, бу аерымлыклар алдатучы. Чөнки, гомуми алганда, һәр кеше туа, үсә, мәктәпкә бара, эш эзли, эшли, өйләнә, балаларга ия була, балаларын

мәктәпкә урнаштыра, бабай яки әби була һәм үлә. Ягъни бу яктан караганда, кешеләр тормышында әллә ни  зур аерма юк. Истанбулның берәр районында урнашкан кеше белән Мексиканың берәр шәһәрендә яшәүче урыннары кеше белән алмаштырылса да, берни үзгәрмәс. Бу кешеләрнең һәрберсе бер көнне әлбәттә үләчәк; хәтта 100 елдан соң бу кешеләрнең берсе дә исән калмаячак. Менә моңа төшенгән кеше уйлануын дәвам итәр һәм үзенә шушы сорауларны сорар: “ Бер көнне барыбыз да үләчәгебезгә күрә, нигә соң һәркем бу дөньядан һич китмәячәк кебек хәрәкәт итә,яши бирә? Үләчәген төгәл рәвештә белүче кешенең үлемнән соң булган яшәеш өчен тырышувы кирәккән вакытта, кешеләрнең купчелеге нигә һич дөнья тормышлары бетмәячәк, һич улмәячәк кебек үз үзләрен тота бирә?”

Менә бу кеше-уйланган һәм уйлануларыннан бик мөһим, бөек нәтиҗә чыгаручу кеше. Әмма кешеләрнең купчелеге бу темалар турында уйланмас. Белдермәстән “хәзер ни турында уйлыйсың?” дип соралса, бик кирәксез һәм үзләренә файда китермәслек нәрсәләр турында уйланылганы беленер. Югыйсә, кеше уянган вакытыннан алып йоклаганчыга кадәр һәр мизгелендә “мәгьнәле”, “хикмәтле”, “әһәммиятле” темалар турында уйлана ала, уйланганнары аркылы нәтиҗәләр чыгара ала.

Аллаһ Көръәндә мөэминнәрнең һәртөрле шартларда уйланганнарын һәм моның аркылы файда бирүче нәтиҗәләр чыгарганнарын шулай белдерә:

***Шиксез, күкләрнең һәм җирнең яратылышында, кич белән төннең бер-бер артлы килешендә чиста акыл ияләре өчен чыннан да аятьләр (ишарәтләр) бар. Алар аякта килеш,утырганда, ятканнары вакыт Аллаһны зикер итәрләр (искә алырлар) һәм күкләрнең һәм җирнең яратылышы турында уйланырлар. (Һәм диярләр ки) “Раббыбыз, Син боларны бушка яратмадың. Син бик Бөексең, безне утның газабыннан сакла.”*** (Али Имран сурәсе,190-191)

Аятьтә дә белдергәнчә, мөэминнәр уйланучы кешеләр булганнары өчен, яратылышның могҗизалы якларын күрә ала һәм Аллаһның көченә, гыйльменә һәм акылына төшенә.

## Җитди һәм Аллаһка юнәлеп уйлану

***Әй кеше, Кәрим, “өстен юмартлык иясе” булган Раббыңа каршы сине ни алдатты, яңлыштырды? Ки, Ул сине яратты, “сиңа бер тигезлек  эчендә кыяфәт бирде”***

***һәм сине бер тәртип белән яратты. Теләгән сүрәтеңдә сине төзек итте.*** (Инфитар сүрәсе, 6-8)

Уйлануның берәр кешегә файда китерүве, аны дөрес нәтиҗәгә ирештерүве өчен даими буларак уңай юнәлештә фикер йөртүве кирәк. Үрнәге, берәр кеше каршысында үзеннән тагын да матуррак берәүне күреп, бу кешенең матурлыгын уйлап үзенең кимчелекләре сәбәпле авырлык тойса, үл кешегә карата көнчелек хис итә башласа, бу Аллаһны хуш итмәүче уй-фикерләрдән булыр. Ләкин, Аллаһны разый итәргә тырышучы кеше бу кешенең матурлыгына Аллаһның камильярату сәләтенең чагылышы буларак карар. Бу кешегә Аллаһ яраткан бер гүзәллек буларак каравыннан бөек ләззәт алыр.Аһирәттә Аллаһ тарафыннан бу кешенең матурлыгын, гүзәллеген тагын да арттыруы өчен дога кылыр. Дөньяда кешенең һичбер вакытта да камил була алмаячагын, дөньяның бер имтихан җире булганы өчен кимчелексез, авырлыксыз яратылмаганын фикерләр. Җәннәткә булган сагышы артар. Шиксез, бу җитди уйлануның бер генә үрнәге. Кеше тормышы буенча мондый нәрсәләр, вакыйгалар белән бик һәм бик еш очрашыр.Бу вакыйгалар аркылы Алаһны риза итүче яки итмәуче икәнлеге,әхлагы имтихан ителер, беленер.

Әлбәттә, бу сынауда уңышлы булуы һәм уйлануның бу кешегә хәерле, Ахирәттә берәр файда китерүве, аның уйланган нәрсәләреннән үгет һәм гыйбрәт алып алмавына бәйле.Моның өчен кешенең даими рәвештә җитди буларак уйлануы шарт. Аллаһ бу хакыйкатьне Көръәндә шулай белдергән:

***Ул сезгә аятьләрен (ишарәтләрен) күрсәтә һәм сезнең өчен күктән ризык иңдерә. Эченнән (Аллаһка) юнәлгәннән башка үгет алып уйланмас.*** (Мүэмин сүрәсе,13)

## Аднан Октар (Харун Яхъя) әфәнденең 2009нчы елның сигезенче март көнендәге Тэмпо ТВга туры эфирда бирелгән репортажыннан...

**Аднан Октар**: Кеше Аллаһка карата коллык үтәр өчен яратылган. Коллык вазыйфасы бар. Әмма Аллаһ безләрне имтихан итәр; ләкин, имтиханда безнең ни эшләгәнебезне контроль иткәннән соң, билгеләгәннән соң, Аллаһның безнең ни булганыбызны аңлауга ихтияҗы юк.Чөнки Аллаһ боларны алдан ук белуче, Аның өчен, Аның Катында инде һәрнәрсә булып беткән.Чөнки бөтен боларны Аллаһ яратты. Аллаһ белер, ни эшләгәнебезне белер. Аллаһның кайбер нәрсәләрне алдан ук белдермәвенең асыл максаты – безгә үз -үзебезне таныту; ягъни без нинди кеше, әхлакыбыз ничек, кешелегебез ни дәрәҗәдә?...Әгәр Аллаһ насыйп итеп җәннәткә керсәк, без узебез өчен: “ Бик яхшы кеше идем, тырыштым, хезмәт иттем, сөйләшә идек, аралаша идек, кешеләрне тугъры юлга чакыра идем, мохтаҗларга ярдәм итә идем, кешеләрне авыр вакытларында дистәкли идем” - диеп,

үз-үзебезгә карата ярату хасил булачак. Ягъни, без җәннәткә лаеклык казанган булабыз”.

***Күкләрнең, җирнең һәм икесе арасындагыларның Раббысы; шул хәлдә Аңа гыйбадәт ит һәм аңа булган гыйбадәтеңдә карарлы, нык бул. Һич аңа тиңдәш булганны беләсең ме? Кеше әйтә ки: “Чыннан да, үлгәннән соң мин тере буларак чыгарылачакмынмы ?” Кеше электән, һич бер нәрсә дә булмаган хәлен, чыннан да Без аны яратканын һич уйламыйммы?*** (Мәрьям сүрәсе, 65-67)

# Кешеләр гомумән ни турында уйланыр

Алдагы бүлемнәрдә кешеләрнең кирәгенчә уйланмаганлыклары, уйлану, фикер йөртү сәләтләрен үстермәгәнлекләре турында сүз йөреттек. Ләкин, монда яңлыш аңлашылмавы кирәк булган бер нокта бар. Әлбәттә, һәр кеше тормышының һәр мизгелендә акылыннан берәр нәрсәләр кичерер. Кеше акылының буш булган вакытлары – йокыдан башка – бик юк кебек. Әмма, бу уйлануларның бөек бер өлеше Ахирәте өчен файда бирмәячәк, “буш һәм кирәксез”, кешене һичнинди нәтиҗәгә китермәгән, аңа берни дә казандырмаган, яраксыз фикер-уйланулардан гыйбарәт.

Кеше көне буе ниләр уйлаганын хәтерләргә тырышса һәм боларны язып, теркәп барса, көннең бетүвендә дә моны җентекләсә, күбесенең ни кадәр файдасыз булганын аңлаячак. Яки боларның бер өлешен хәтта файдалы итеп күрсә дә, хаталы фикер йөрткән итеп санала ала. Чөнки, гомумән алганда, кешеләргә дөрес итеп тоелган нәрсәләр, чынлыкта аларга Ахирәттә бер файда да бирмәячәк уй-фикерләрдән хасил була ала.

Кешеләр көндәлек тормышларында ничек буш эшләр белән мәшгуль булып, буш нәрсәләргә вакыт сарыф иткән булса, шулай ук буш фикерләргә бирелеп тә вакытны бушка сарыф итә ала. Аллаһ Көрьәндә: ***“Алар “бөтенләй буш” нәрсәләрдән качынучылар”*** (Мүэминүн сурәсе,3) аяте белән мөэминнәрне мактый һәм моны гузәл үрнәк буларак күрсәтә. Шиксез, Аллаһның бу тасвиры кеше уй-фикерләре өчен дә яраклы. Чөнки уй-фикерләр, әгәр кеше аларны аңлы, белгән килеш контроль итмәсә, инсан акылында дәвамлы буларак урын алыр. Кич белән өенә кайтувында кибеттән нинди кирәкле нәрсәләрне сатып алувы турында уйланганы вакыт, бер мизгелдә ике ел алда бер иптәшенең үзенә сөйләгән сүзе турында уйлаганын төшенер. Бу буш һәм яраксыз уйлану көн буенча өзлексез дәвам итә ала.

Хәлбуки, кешенең уй-фикерләренә хуҗа булувы үзенең кулында. Һәр кеше аңлаешлы юнәлдерү ярдәмендә үзен, иманын, акылын, үзтотышын, тирә юнен камилләштерәчәк нәрсәләр турында уйланырлык сәләткә ия.

Бу бүлемдә гафләт эчендә булган кешеләрнең гомумән нинди төрле нәрсәләр турында уйланганнарын аңлатачакбыз. Бу темаларның җентекле буларак аңлатылувының сәбәбе, бу китапны укучы кешеләрнең, үрнәк буларак китергәндә, иртәгә эшләренә, уку йортларына барган вакытларында яки берәр төрле эш белән мәшгуль булганнарында, акылларына монда санап үтелгәннәр килгәндә, шунда ук буш нәрсә турында уйланганлыкларын аңлар өчен һәм уй-

фикерләренә хуҗа булган килеш, үзләренә чын мәгънәдә файда бирәчәк нәрсәләр турында фикер йөртүне булдырыр өчен.

## Буш борчылулар

Кеше фикерләрен файда китерәчәк юнәлештә контроль итмәгән халәтендә, еш-еш борчылуларга, хафалануларга бирелә ала яки әле булмаган вакыгалар сәбәпле, акылында боларны булган дип алдан тасвир итеп, шулар өчен кайгырырга, хәсрәтләнергә,куркырга һәм җәфаланырга мөмкин.

Үрнәге, баласы университет имтиханнарына хәзерләнгән кешенең, әле имтихан тормышка ашмаган килеш, баласының имтиханны казанмаса ниләр булачагы турында борчылувы: “Баласы киләчәктә яхшы эш таба алмаса, җитәрлек акча эшләп алмаса, ул вакыт өйләнә алмаячак. Өйләнсә дә, туй өчен акчаны кайдан табачаклар? Имтиханны казанмаса, әтисе аңа биргән бөтен акчалар бушка киткән дип саналачак,өстәвенә, кеше алдында да хур булачаклар. Йә иң яхшы дустының баласы казаныр да, үз баласы казана алмаса....”

Бу борчылулар шулай бара-бара күбәер. Югыйсә, баласы әле имтиханга да кермәгән. Диннән, дин әхлагыннан ерак булган һәр кеше тормышы буенча бу име буш борчулуларга дучар булыр. Әлбәттә, моның сәбәбе бар. Көръәндә кешеләрнең буш борчылулардан котыла алмауларының сәбәбе – шәйтанның вәсвәсәсенә колак салулары булганлыгы шулай хәбәр ителә:

***Аларны – ни булса булсын – шашыртып тайпылдырачакмын, була алмаган борчуларга төшерәчәкмен...*** (Ниса сүрәсе,119)

Югарыдагы аятьтә күрелгәнчә, буш борчылуларга бирелүче, Аллаһны онытучы һәм уйланмаган кеше,асылында шәйтанның даими вәсвәсәләренә, котыртуларына ачык вәзгыятьтә. Башкача әйткәндә, бер кеше дөнья тормышына бирелеп үз ихтиярын кулланмаса, вөҗданына колак салмаса, аны тыңламыйча хәрәкәт итсә һәм үз-үзен вакыйгаларның агымына тәслим итсә, бөтенләй шәйтанның контроле астына керер. Шәйтанны иң белдерүче үзенчәлекләрнең берсе дә, кешеләргә вәсвәсә һәм борчылулар ирештерү. Акылларында барлыкка килгән бу борчылулар, төшенкелек яки “бу шулай булса, мин ни эшләрмен?” име хафаланулар шайтанның пышылдавы, вәсвәсе белән барлыкка килер.

Әмма Аллаһ бу хәлдән үзләрен коткарулары өчен кешеләргә юл күрсәткән. Көръәндә кешеләргә шәйтаннан вәсвәсә килгәндә Аллаһка сыенулары, уйланулары тиеш икәнлекләре шулай белдерелгән:

***(Аллаһтан) Сакланганнарга шәйтаннан берәр вәсвәсә ирешкәндә (башта) яхшы итеп уйланырлар (Аллаһны зикер итәрләр, искә төшерерләр), соңыннан***

***шунда ук карарсын ки, күреп аңлаганнар. (Шәйтанның) Кардәшләре исә, аларны тайпылуга этәрерләр, соңыннан аларны ялгыз калдырмаслар.*** (Араф сүрәсе,201-202)

Аятьләрдә дә хәбәр ителгәнчә, уйланган кеше дөрес нәрсәне күрер, уйланмаган кеше исә, шәйтан аны кая алып барырга теләсә шунда барыр.

Әһәммиятлесе: бу төрле уй-фикерләүләрнең кешегә һичнинди файда китермәвен,киресенчә, мөһим вакыйгалар турында уйлануга киртә булувын белү һәм акылны болардан арындыру. Кеше барытик буш уйлардан арынган акыл аркылы гына кирәгенчә уйлана ала. Шулай итеп, Көрьәндә Аллаһ белдергән рәвештә “***буш нәрсәләрдән качынылган”*** булыр.

***Әйт ки: “Ул күкне һәм җирне яратканда ,Ул (гел) ризыкландыручы Үзе (һич) ризыкланмаганда, мин Аллаһтан башка булганныңмы идарасен кабул итәчәкмен, Аллаһтан башкасына мы баш иячәкмен? ” Әйт ки: “Чыннан да миңа мөселман булганнарның беренчесе булувым әмер ителде һәм һич тә мөшрикләрдән булма диелде.” Әйт ки: “Шиксез, мин Раббыма гыйсьян кылсам, ул бөек көннең газабыннан куркармын.”*** (Әнъам сүрәсе,14-15)

# Уйлануга киртә булган сәбәпләр ниләр?

Кешеләрнең уйлануvына киртә булучы куп кенә сәбәпләр бар. Болар кешеләрне уйланудан, хакыкатьләрне күрүдән мәхрум итү ала. Шуның өчен һәр кеше үзенә начар яктан тәэсир иткән сәбәпләрне фаш итүве һәм алардан котылувы шарт. Киресенчә булганда, дөнья тормышының хакыйкый йөзен күрә алмас. Бу исә аңа Ахирәттә бик олы югалтулар китерер.

Аллаһ Китабында бу төрле кешеләрдән шулай хәбәр бирә:

***Алар дөнья тормышыннан тыш башканы белмәс.. Ахирәттән исә гафил алар. Үз-үзләре (рух, гәудәләре) турында уйланмыйлар мы? Аллаһ күкләрне, җирне һәм икесе арасында булганнарны чыннан һәм барытик билгеле бер вакыт өчен (әҗәлләре,соңнары килгәнче) генә яратты. Чыннан да кешеләрнең кубчелеге Раббылырына кавышуын инкар итәр.*** (Рум сүрәсе,7-8)

Бу бүлемдә уйлануга киртә булган кайбер сәбәпләрне билгеләп үтәрбез.

## Күплеккә ияру сәбәпле барлыкка килгән акыл йокысы

Кешеләрне иң күп адаштыручы нәрсәләрнең берсе – күпчелек кешеләр тарафыннан эшләнелгәннәргә дөрес дип инанулары. Берәр кеше туры нәрсәләрне, хакыйкатьләрне уйланып, фикерләп табу урынына, гел тирәсендәге кешеләрнең өйрәткәннәрен кабул итүгә күнегер. Күп вакытта үзе тарафыннан да сәер дип беленгән нәрсәләрнең башка кешеләр тарафыннан табигый, нормаль рәвештә кабул ителгәнен күрер һәм бер вакыттан соң үзе дә боларны кабул итә, үземсенә башлар.

Үрнәге, тирәсендәге купчелек кеше бер көнне үләчәкләрен уйламас. Хәтта үлемне уйламас өчен бу темага бер кемне дә сөйләштермәсләр, бу теманы онытырга тырышырлар, бу темадан качарлар. Моны күрүче кеше дә тирәсенә карар, “һәркем шулай булганга күрә, минем дә шундый булувымда бернинди гаеп тә юк” дияр һәм үлемне һич тә аклына китермичә яши башлар.Югыйсә, тирәсендәге һәркеше Аллаһ куркусы белән хәрәкәт итсә һәм Ахирәт өчен җитди тырышлык эченә керсә, бик зур ихтимал ки, бу кеше дә үзтотышын узгәртәчәк.

Яки телевизор каналларында, журналларда һәркөн йөзләрчә һәлакат, хаксызлык, гаделсезлек, золым, суицид, җинаять, угърылык, хафаландыручы хәбәрләр укылыр, ярдәмгә мохтаҗ булган меңнәрчә кешеләрдән сүз ителер. Әмма, күп кенә кеше бу хәбәрләрне укып гәҗит битләрен күңел рәхәтлеге белән алмаштырыр. Гомумән, кешеләр мондый ише хәбәрләрнең нидән бу хәтле күп булганлыгы, боларны киметү өченниләр эшләнергә тиеш икәнлеге, хәтта моның өчен үзләре ни эшләргә тиеш булулары турында уйланмаслар.Чөнки тирәсендә күпчелекне тәшкил итүче башка кешеләр дә моның турында уйланмас. Күбесе " дөньяны коткару миңа калганмы? " мантыгы (логикасы) аркылы җавплылыкны башкалардан эзләр.

## Уйлануда ялкаулык күрсәтү

Ялкаулык – купчелек кешеләрнең уйланувына киртә булучы сәбәп.

Уйланырга ялкауланган кеше һәрнәрсәне гел булган кебек белер һәм күнеккән өчен эшләр. Көндәлек тормыштан урнәк китерергә кирәк булса: хуҗабикәләр тарафыннан ясалган чисталык гел әниләреннән күрелгән рәвештә. Гомуми алганда, " ни эшлим, үзгәртим дә яхшырак, чистарак булыр" дип уйланмаслар һәм яңа ысуллар эзләмәсләр. Шулай ук ирләр дә, берәр ремонт яки башкалар эшләнергә тиешле булганда бала чагыннан үзләренә өйрәтелгән ысул-юлларны кулланырлар. Яңа берәр методны, тагын да җайлырак һәм акыллырак булган нәрсәне кирәк дип тапмаслар, аларны мөһимсенмәсләр. Бу кешеләрнең сөйләшү ысуллары да гел бертөрле.Үрнәге, берәр хисапчының сөйләшү ысулы – тормышы буенча аның тарафыннан күрелгән хисабчылар ысулының нәкъ үзе. Докторларның, банкчыларның, сатучыларның... Кыскасы, һәрбер кысым кешеләренең үзләренә карата бер сөйләшү стиле бар.Чөнки бу кешеләр уйланып иң урынлысын, иң матурын, иң хәерлесен эзләмәсләр. Күргәннәрен генә гел кабатларлар.

Авырлыкларга, проблемаларга китерүче чишелешләр дә уйланудагы ялкаулыкны чагылдыра. Үрнәге, бер бинаның җаваплысы чүп проблемасын аңа хәтле булган җаваплы кебек чишә. Яки берәр район башлыгы юл проблемасын алданрак булган башлыкка карап, аның кебек чишәргә тырыша.Күп кенә нәрсәләр,вакыйгалар турында уйланылмаганы өчен, яңа чишелешләр китерә алмас

Әлбәттә, монда китерелгән үрнәкләр кешеләрнең көндәлек тормышта булган зарарлары белән бәйле. Ләкин, болардан тагын да әһәммиятле темалар бар ки, кешеләр тарафыннан ялкаулык күрсәтелеп болар турында уйланмау аларны бөек һәм мәңгелек хәсрәткә дучар итә. Кешенең дөньяда бар булу максаты турында уйланмавы, үлемнең үзеннән кача алмаслык бер хакыйкать булганын, үлемнән соң исә шиксез рәвештә Хисап Көне белән кара-каршы калачагын мөһимсенмәве - бу соңсыз хәсрәтнең чыганагы. Аллаһ Көрьәндә кешеләрне бу әһәммиятле хакыйкатьләр турында уйлануга чакыра. Бу аятьләрнең кайберәүләрендә шулай боерыла:

***Менә болар үзләрен хәсрәткә дучар итүчеләр һәм ялган булган, уйдырма (тезмә тәңреләре дә) алардан ерагаеп югалганнар. Һичшиксез, болар Ахирәттә иң күп хәсрәткә тап булучылар. Иман итеп изге гамәл кылганнар һәм "Раббыларына йөрәкләре хозур тапкан шикелдә багланганнар" - менә болар җәннәт халкы. Анда мәңге калачаклар. Бу ике төркемнең үрнәге: сукыр һәм саңгырау белән күрүче һәм ишетүче кебек. Болар үрнәк буларак тигез ме? Янә дә үгет алып уйланмаячакмысыныз?*** (Худ сүрәсе, 21-24)

***Яратучы һич яратмаучы кебекме? Инде үгет алып уйланмаячакмысыныз?*** (Нахл сүрәсе, 17)

## "Күп уйлау яхшы түгел" рәвешендәге яңлыш позиция

Җәмгыятьтә тирәнтен уйлануның бик кабул ителмәгәнен күрсәткән һәм бик таралган бер яңлыш инану бар. Хәтта кешеләрдән кайберүләре бер-берсен "артык уйланма, тилерерсең" дип кисәтерләр. Әлбәттә, бу диндән ерак булган кешеләр тарафыннан ясалган яңлыш уйдырмадан башка нәрсә түгел. Кеше үзеннән качу тиешле булган нәрсә уйлану түгел, киресенчә, начар һәм сыйфатсыз уйлану, борчылуларга һәм вәсвәсәләргә бирелү булырга тиеш.

Аллаһка һәм Ахирәткә көчле иманы булмаган, Көръәнне яхшы белмәгән кешеләр яхшылык һәм гүзәллек юнәлешендә түгел дә, начар, сыйфатсыз юнәлештә фикер иткәннәре өчен, уйланулары нәтиҗәсенедә бик файдалы нәтиҗәләр ясамаслар. Үрнәге, дөнья тормышының үтүчән икәнлеген, бер көн килгәч тә үләчәкләрен уйларлар, ләкин, бу сәбәптән олы хафалануга бирелерләр. Чөнки вөҗданнары белән дөньяда Аллаһның әмерләрен үтәмичә яшәлгән тормышлары өчен аларга Ахирәттә  начар соң булачагын сизерләр,белерләр. Бер өлеше дә "үлеп, юк булам" дигән яңлыш фикергә инанганнары өчен борчылыр.

Югыйсә, Аллаһка һәм Ахирәт Көненә ышанучы, акыл иясе булган берәр кеше  дөнья тормышының үтүчәнлеге турында уйланганда, бөтенләй башка һәм  бик яхшы нәтиҗәләргә килер.Һәрнәрсәдән элек дөньяның фани икәнлеген аңлавы, Ахирәттәге хакыйкый һәм мәңгелек тромышы өчен бик көчле тырышлык эченү керүве өчен сәбәп булыр. Мондагы яшәешнең иртә яки соң бетәчәген белгәнлегеннән , дөнья белән бәйле мәнфагатьләр һәм хисаплар,теләкләр белән үзен алдаттырмас. Соң дәрәҗәдәге ышанычлыкка ия булыр. Бу фани дөньядагы һичнинди вакыйга да аңа тәэсир итмәс, аны борчымас. Гел дәвамлы, мәңгелек һәм гүзәл бер тормышка кавышу өмете белән яшәр.  Дөньядагы нигъмәтләрдән һәм матурлыклардан да бик зур ләззәт табар. Чөнки Аллаһ дөньяны

кешеләрне имтихан итәр өчен кимчелекле итеп яратты. Шушындый кимчелекле дөньяда да хәтта, кешене хушландырырлык күп санлы гүзәллекләр бар булганда, җәннәттәге гүзәллекләрнең хыялга китерә алмаслык дәрәҗәдә икәнлегенә төшенер. Монда күрелгән һәрбер матурлыкның Ахирәттәге асылын да күрергә теләр. Һәм бу нәтиҗәләргә тирән-тирән уйланып килер.

Шулай итеп, берәр кешенең “нәтиҗәдә хакыйкатъләрне күрермен дә, борчылуларга, өметсезлеккә тап булырмын” дип хафалануы һәм бу сәбәпле уйлану, фикерләүдән качуы, аның өчен бик олы югалту булыр. Чөнки Аллаһка булган иманы аркылы даими өмет эчендә булучы һәм позитив фикер йөртүче берәр кеше өчен, аны өметсезлеккә китерәчәк, хафаландырачак берни дә юк.

## Уйлану нәтиҗәсендә барлыкка килүче җаваплылыклардан качу

Күп кенә кеше уйланудан, кайбер темалар белән үзенең зиһенен мәшгуль итүдән ерак торып, бик күп җаваплылыклардан кача алганын уйлар. Хәтта дөньяда килеш моны тормышка ашырып, күп кенә темаларга карата үзен битараф тота ала. Ләкин, кешеләрнең иң олы хаталарыннан берсе – уйланмыйча Раббыбызга карата булган җаваплылыклардан кача алуларын исәп итүләре. Бу кешеләрнең үлем турында һәм үлемнән соң булачаклар турында уйланмауларының асыл сәбәбе. Чөнки берәр кеше бер көнне үләчәген уйласа һәм үлемнән соң мәңгелек тормыш булачагын хәтерләсә, бөтен көче, мөмкинчелекләре белән үлемнән соң булган яшәеше өчен тырышлык күрсәтү мәҗбүриятендә калыр. Ләкин, Ахирәтнең барлыгын уйламыйча бу җаваплылыктан үзен котылган дип белеп, үз-үзен алдатыр. Бу бик олы алдану һәм кеше дөньяда килеш уйланып хакыкатькә ирешмәсә, үлем белән берлектә үзе өчен һичнинди качу булмаганын аңлаячак. Бу хакыкать аятьләрдә шулай белдерелә:

***Ул үлем исереклеге бер хакыйкать буларак килеп тә, (кешегә) “менә бу син анардан читләешеп качкан нәрсә” (дип әйтелгәне вакыт). Сурга да өрелгән. Менә бу кисәтүнең (чынга ашканы) көн.*** (Каф сүрәсе, 19-20)

## Көндәлек тормышның агымына бирелеп уйланмаулары

Кешеләрнең күпчелеге бөтен тормышларын бер “чабу, куыш” эчендә үткәрер. Билгеле бер яшькә җитүләре белән эшләүләре, үзләрен һәм гаиләләрен тәэмин итүләре кирәк. Моны “яшәеш көрәше” дип исемләндерерләр һәм бу көрәш эчендә тегендә-монда сугылулары

сәбәпле дә башка эшләргә вакыт калмаганлыгыннан үкенеч хәленә кергән булырлар. Теге яки бу нәрсәгә “вакыт юк, җитми” төшенчәсен еш-еш кулланырлар. Шулай итеп, көндәлек тормышлары аларны үз юнәлешендә сөйрәр. Күпчелек кеше бу тормыш рәвеше эчендә тирәсендәге вакыйгаларга карата битараф калыр.

Югыйсә, кешенең бу  дөньядагы максаты тегендә-монда сугылып, дөньяда вакыт сарыф итү генә булырга тиеш түгел. Асыл максаты - дөньяның хакыйкый йөзен күрә алувы һәм шуңа карата бер тормыш рәвеше билгеләве. Һичбер кешенең бердәнбер максаты акча казанувы, эшләве, университетта укувы, өй хуҗасы булувы түгел. Әлбәттә, кеше тормышы буенча бу нәрсәләр үтәлергә тиешле, ләкин, бөтен боларны үтәгән вакытта кеше акылында булырга тиешлесе, онытылырга тиеш булмаганы: һәркешенең дөньяда булу максаты Аллаһка кол булу, Аллаһның ризасын, рахмәтен һәм җәннәтен казану өчен тырышлык күрсәтү икәнлеге. Бу максатлардан тыш бөтен хәрәкәтләр, эшләр исә, барытик кешенең хакыйкый максатына ирешүвен булдыручы, ярдәм итүче бер арадашчы гына. Арада булган нәрсәләрне максат дип билгеләү, шайтан тарафыннан кешеләр өчен хәзерләнгән бик олы хаталану упкыны.

Ләкин уйланмыйча яшәүче кеше, бу арадашчыларны бик җиңел рәвештә үзенә максат итеп билгели ала. Моның өчен көндәлек тормыш белән бәйле булган шушы үрнәкне китерергә мөмкин: кешенең эшчәнлек күрсәтеп җәмгыятькә файда китерүве шиксез яхшы нәрсәләрдән. Аллаһка иман иткән берәр кеше бу эшне яратып эшләр, каршылыгын һәм дә дөньяда булганы килеш һәм дә Ахирәттә Аллаһ тарафыннан көтәр. Әмма башка, Аллаһны онытып шушы ук эшне эшләүче кеше, барытик бу дөньяга юнәлгән кайбер мәнфагатьләр өчен, кешеләрне хуш итәр өчен генә эшли икән, менә монда инде ул хаталы. Һәм дә Ахирәттә хакыйкатьләр белән каршылашкан вакытында бу сәбәптән тасвирлана алмаслык үкенү яшәячәк. Аллаһ дөнья тормышына бирелгәннәр өчен бер аятендә шулай боера:

***Сездән алдагы (мөнафикълар, кяферләр) кебек. Алар сездән куввәт ягыннан тагын да көчле, мал һәм балалар ягыннан тагын да күбрәк иде. Алар үз өлешләре белән файдалануда булдылар, сез дә сездән алдагылар үз өлешләре белән файдалануда булганнары кебек үзегезнең өлешләрегез белән файдалануда булдыгыз һәм сез дә (дөньяга һәм ләззәтләргә) бирелгәннәр кебек бирелдегез. Менә аларның дөньяда бөтен эшләгән гамәлләре Ахирәттә бушка чыкты һәм менә алар югалтуга тап булучылар.*** (Тәүбә сүрәсе, 69)

## Һәрнәрсәгә “күнеккәнлек” аркылы карау һәм бу сәбәпле уйлануны кирәк дип тапмау

Кайбер нәрсәләр белән беренче тапкыр каршылашкан заманда, кешеләр алардагы гадәттән тыш  нәрсәләрне аңлый ала һәм бу аларның уйлануларына, күрелгән нәрсәләрнең җентекләнелүвенә, эзләнелүвенә сәбәпче була ала. Ләкин бер вакыттан соң, кешедә бу нәрсәгә карата күнеккәнлек хасил булыр һәм инде ул кеше тәэсирләнмәс хәлгә килер. Аеруча, һәркөнне тап булынган берәр нәрсә яки күренеш инде алар өчен “чираттан тыш” булмаган бернәрсә хәлендә булыр.

Үрнәге, табип буласы кайбер кешеләр беренче тапкыр үле кешенең гәүдәсен күргәннәре заман, монардан соңгы дәрәҗә тәэсирләнерләр. Яки беренче тапкыр пациентлары улгәндә, бу аларны күп-күп уйландырыр. Берничә минут элек тормыш тулы, көлгән, планнары булган, сөйләшкән, ләззәт тоечу берәр кешенең, күзләре нурлы, үзе тере булган килеш, бер мәлдә җансыз, бер  хәрәкәтсез предмет кебек калган гәүдәсе күз алларында пәйда булыр. Беренче тапкыр мәетне ярып караганнары вакыт, бу гәүдәдә алар күргән бөтен нәрсә исләренә төшәр.Үрнәк буларак, бу гәүдәнең бик тиз черуве, эченнән чыдый алмаслык ис чыгувы, исән вакытында матурлыгы белән үзенә җәлеп иткән чәчләргә, хәзер инде хәтта кагылырга да теләмәгәнлек, аларны гел уйландыручы темалардан. Болардан соң да шуларны уйларлар: һәркеше берүк матдәләрдән тора һәм һәркемнең гәүдәсен нәкъ шундый ук бер соң көтә, ягъни үзләрен дә бер көнне шушы халәт көтә бирә.

Ләкин, берничә шушындый мәетләр белән эш ителгәненнән соң яки берничә пациент югалтылганнан соң, бу кешеләрдә күнеккәнлек барлыкка килүве башлана ала. Инде мәетләргә, хәтта пациентларга карата да булган мөгамәләләре предмет, берәр әйбергә карата булган мөгамәләне хәтерләтер.

Әлбәттә ки, бу хәл барытик докторларда гына булмый. Бу кешеләрнең купчелегенә хас һәм тормышның башка бөтен якларында да шундый ук хәл күзәтелә. Үрнәге, авыр шартларда яшәүче берәр кеше, бермәлне рәхәт тормыш белән яшәп китсә, ул күргән һәм ул ия булган һәрнәрсәнең аның өчен бер нигъмәт икәнлегенә төшенер. Яткан урының тагын да рәхәтрәк булувы, өеннән бик гүзәл манзаралар күренүве, җаны телəгән  һәрнәрсәне алып ашый алувы, кыш көнне өен ул теләгәнчә җылыта алувы, бер җирдән икенче җиргә җиңел рәвештә машинасы белән бара алувы һәм тагын күп кенә мөмкинчелекләр менә бу кеше өчен нигъмәт. Элекеге хәле искә төшкәндә,  һәрбер нәрсәсе өчен булган сөенече кат-кат тагын да артар. Ләкин, туганыннан бирле бу мөмкинчелекләргә ия булучы кеше, боларның кыйммәте турында ул хәтле уйланмас. Бу гүзәллекләрне аңлавы да– уйланмавы дәвам иткәнчә – бик мәмкин булмас.

Уйланучы берәр кеше өчен исә, ни туганыннан алып бу нигъмәтләргә ия булганлыгы, ни дә соңыннан ия булганлыгы арасында һич тә аерма юк. Чөнки ул һичкайчанда ия булган нәрсәләренә "күнеккәнлек" призмасы аркылы карамас. Һәрберсенең аның өчен Аллаһ тарафыннан яратылганын, Ул теләсә анардан боларны кире ала алганын белер. Үрнәге, мөэминнәр үзләрен ташучы хайваннарга атланганнары вакыт шулай дога кылырлар:

***...боларны безләр өчен муен идерткән (Аллаһ) ни Бөек, югыйсә, без моны (безгә хезмәт күрсәтүләрен) булдыра алмас идек...*** (Зухруф сүрәсе, 13)

***"Һәм без әлбәттә Раббыбызга кайтарылачакбыз".*** (Зухруф сүрәсе, 14)

Башка бер аятьтә дә, мөэминнәрнең үз бакчаларына кергән вакытларында Аллаһны тәсбиһ кылып: ***"...мәшәАллаһ, Аллаһтан башка куввәт юк..."*** (Кәхф сүрәсе, 39) әйткәнлекләрен белдерелә. Бу аларның һәрвакыт бакчаларына кергән вакытларында, бу бакчаны яратучы һәм аны тере, аякта тотучы Аллаһ булганы турында уйлаганнарын күрсәтә. Уйланмаучы кеше исә, берәр матур бакчаны беренче тапкыр күргән вакытында тәэсирләнүве мөмкин, ләкин, соңыннан вакыт үтү белән бу урын аның өчен чираттан тыш булмаган бер урынга әверелә башлар. Эчендәге гүзәллекләргә карата булган хәйранлыгы югалыр.Кайбер кешеләр һич уйланмаганнары өчен, әле иң башыннан бу нигъмәтләрне аңламаслар. Үзләренә бирелгән нигъмәтләрне "күнегелгән", "булырга тиеш" нәрсәләр буларак бәяләп хаталаныырлар. Шул сәбәптән, дөньядагы гүзәллекләрдән дә ләззәт ала алмаслар.

# Нәтиҗә: кеше үзенең уйлануына киртә булган бөтен нәрсәләрдән арынырга тиеш

Элегрәк тә билгеләгәнебез кебек, күпчелекнең уйланмавы һәм хакыйкатьләрдән гафил буларак яшәве, кешенең уйланмавы өчен сәбәп түгел. Чөнки һәркеше үзенә күрә мөстәкыйль барлык һәм Аллаһ каршында ялгызбашын җавап бирәчәк. Онытмаска кирәк ки, Аллаһ дөнья тормышында кешеләрне сыный. Башка кешеләрнең битарафсызлыгы, уйланмаган, акылланмаган, хакыйкатьләрне күрмәүче кешеләр булулары да бу имтиханның бер өлеше. Һәм җитди буларак уйланган бер кеше, "кешеләрнең күбесе уйланмый һәм бу нәрсәләрне сизми, абайламый, нигә мин берүзем уйланыйм" дип әйтмәс. Хәтта, күпчелек кешеләрне яулап алган гафләт турында уйланып гыйбрәт алыр һәм шул кешеләрдән берәрсе булмас өчен Аллаһка сыеныр. Башка кешеләрнең хәле үзе өчен сәбәп, гөзер була алмаганы бик ачык. Чөнки Аллаһ Көръәндә кешеләрнең күпчелеге

гафләт эчендә булганлыкларын һәм иман итмәгәнлекләрен бик күп аятьләре белән белдерә. Бу аятьләрнең кайберәүләре шуны боера:

***Син бик теләсәң дә, кешеләрнең күбесе иман итәчәк түгелләр.*** (Йусуф сүрәсе, 103)

***Әлиф, Ләм, Мим, Ра. Бу Китапның аятьләре. Һәм сиңа Раббыңнан иңдерелгән – хак.Ләкин кешеләрнең күбесе иман итмәсләр.*** (Рад сүрәсе, 1)

***Була алганчы антлары белән: "Үлгәнне Аллаһ терелтмәс", - дип ант иттеләр. Юк, бу Аның өстендә булган хак бер вәгъдә, ләкин кешеләрнең күбесе белмәс.*** (Нахл сүрәсе, 38)

***Ант булсын, моны аларның арасында үгет алып уйлансыннар дип төрле рәвештә ачыкладык. Әмма кешеләрнең күбесе рәхмәтсезлек итеп йөзләрен бордылар.*** (Фуркан сүрәсе, 50)

Аллаһ башка аятьләрендә кешеләрнең күпчелгенә ияреп юлдан язган, яратылу максаты турында уйланмыйча Аллаһ кушканнарны җиренә җиткермәгән кешеләрнең дучар булачаклары соң турында да хәбәр биргән:

***Эчендә алар (шулай) кычкырырлар: "Раббыбыз безне чыгар, кылганнарыбыздан тыш башка изге гамәл кылыйк." Сезгә анда (дөньяда) үгет ала алучының үгет ала алачагы кадәр гомер бирмәдекме? Сезне кисәтүче дә килгән иде. Алайса газапны татыгыз; инде залимләр өчен бер ярдәмче дә юк.*** (Фатир сүрәсе,37)

Шуның өчен һәркешенең үзенең уйлануына киртә булучы сәбәпләрдән арынып, җитди һәм ихласлы рәвештә Аллаһ яраткан һәр вакыйга һәм һәр барлык турында уйлануы, уйлаганнарыннан үзе өчен үгет һәм дәрес алуы тиешле.

Киләчәк бүлемдә берәр кеше тарафыннан көндәлек тормышында очратыла алынган кайбер вакыйгалар һәм барлыклар турында аның нәрсәләр уйлый ала алуы турында сүз алып барылачак. Максатыбыз – монда телгә алынган темаларның бу китапны укучылар өчен юл күрсәтүче маяк булувы һәм алдагы тормышларын " уйланган һәм уйланганнарыннан үгет-нәсыйхать һәм дәрес алучы " кешеләр буларак үткәрүләре.

# Уйланырга тиешле булганнар

Китапның башыннан бу биткә кадәр фикерләүнең әһәммияте, кешегә казандырганнары, кешене башка җанлылардан аерган бик мөһим бер узенчәлек булганы турында сөйләдек. Аеруча, фикерләүне киртәләгән сәбәпләргә дә кагылдык. Шиксез, боларның барысындагы максат - Аллаһның чиксез гыйлемен һәм кодрәтен тиешенчә бәяли алуларында ярдәмче булу иде.

Алдагы битләрдә исә, Аллаһка иман иткән кешенең бер көн эчендә яшәгән вакыйгалар каршысында ниләргә төшенергә тиешлеген, күргән вакыйгалардан ничек гыйбрәтләр чыгарырга, очрашкан һәрнәрсәдә Раббыбызның сәнгатен һәм гыйлемен күреп, ничек Аллаһка шөкер итергә һәм якынлашырга кирәк икәнен аңлатачакбыз.

Әлбәттә, монда сөйләнеләчәкләр кешенең фикерләү сәләтенең бик кечкенә бер бүлемен эчкә ала. Кеше яшәгән һәр мизгел уйлануга лаеклы. Һәм кешенең фикерләү офыгы (горизонты) шулкадәр киң ки, аларны кысу, рәткә төзү мөмкин түгел. Монда аңлатылачакларның максаты – бары тик фикерләү сәләтен кирәк булганча кулланмаган кешеләргә бер юл ачудыр.

Шуны онытмаска кирәк: фәкать фикерләгән кешеләр акылын куллана алыр һәм башка җанлылардан аермалы бер халәткә ирешә алыр. Тирә-ягындагы могъҗизалы вакыйгаларны күрмәгән, күреп тә аңлый алмаган кешеләрнең хәлен Аллаһ аятьләрендә шулай хәбәр биргән:

***Аллаһка ышанмаган кяферләрнең хәле, чакырып кычкырган тавышны ишетеп тә, һични аңламаган хайванныкы кебек. Аларның (кяферләрнең) күңел күзләре сукыр, алар телсез - чукрак кебек. Шуңа күрә, аларның башы уйлар дәрәҗәдә түгел.*** (Бакара Сүрәсе, 171)

***...йөрәкләре бардыр, аны кулланып аңламаслар; күзләре бардыр, аның белән күрмәсләр; колаклары бардыр, аның белән ишетмәсләр. Болар хайван кебектер, хәтта тагын да түбәндер. Менә алар - гафил булганнардыр. (Араф Сүрәсе, 179)***

***Әллә син аларның күбесен (сүз) ишетер яки дә акылын кулланыр дип саныйсыңмы? Алар бары тик хайваннар кебектер; юк, алар хайваннарга караганда да күбрәк юлдан ераклашкан (һәм түбән)дер.*** (Фуркан Сүрәсе, 44)

Аллаһның аятьләрен (ишарәтләрен), Ул яраткан җанлылардагы һәм вакыйгалардагы могъҗизалы якларны күрә алган, бу сәбәпле аңлый алган

кешеләр исә - бары тик фикерләгән кешеләрдер. Һәм бу кешеләр күргән кечкенә-зур һәрнәрсәдән бер нәтиҗә чыгара алыр.

# ИРТӘН УЯНГАНДА...

Кешенең фикерли башлавы өчен шәхси бер мөхит формалашуга кирәк юк. Иртән торган мизгелдән башлап фикерләү өчен каршына бик күп мөмкинлек чыгар.
Иртән уянган кешенең алдында озын бер көн бар. Гадәттә, арыган яки йокысыз түгелдер, һәрнәрсәне яңадан башларга хәзердер. Моны төшенгән кешенең акылына Аллаһның бер аяте килер:

***Ул төнне сезнең өчен бер күлмәк, йокыны бер ял итү һәм көнне дә төш (вакыты) иткәндер.*** (Фуркан Сүрәсе, 47)

Фикерләрен туплавы, тулысынча уяну өчен йөзен юувы, душ керүве җитәрлек. Моннан соң кеше үзе өчен файдалы бик күп нәрсәне аңлый алачак бер хәлдәдер. Иртәнге ашын ничәдә ашарга яки өйдән ничәдә чыгарга кирәклегеннән дә мөһимрәк мәсьәләләр бар һәм башта аларны уйларга кирәк. Башта иртән уяна алувы – бөек бер могъҗизадыр. Аңын тулысынча югалтувына карамастан, иртән яңадан элеккеге аңы һәм кешелеге белән кире кайткандыр. Йөрәге тибә, сулый ала, сөйләшә ала һәм күрә аладыр. Шулай булгач, төнлә йокыга киткәндә, бу нигъмәтләрнең иртән яңадан биреләчәгенең бернинди гарантиясе юк. Өстәвенә, төн буе башына бернинди бәла-каза да килмәгән. Мәсәлән, яшәгән квартирада бер күршесенең таркаулыгы газ чыгуга сәбәп була алыр һәм төнлә каты шартлау белән уяныргa мөмкин иде. Булган өлкә табигый бер һәлакәткә дучар кала алыр, бәлки тормышын югалта алыр иде.

Гәүдәсендә башка проблемалар була алыр, мәсәлән, ныклы бөер авыртуы, баш авыртуы белән уяна алыр иде. Әмма, боларның берсе дә булмаган һәм исән-сау уянгандыр. Боларның барысын уйлагач, Аллаһның үзе өстендәге киң мәрхәмәте һәм саклавы өчен Аңа шөкер итер.

Яңа бер көнне сау килеш башлау – Аллаһның, кешегә Ахирәте өчен тагын да кубрәк казаныч алуы өчен, аңа бер форсат бирүведер.

Шулай булгач, эшлиячәк иң матур хәрәкәт - көнне Аллаһ риза булачак рәвештә үткәрүдер. Кеше һәрнәрсәдән алда моның планнарын корырга, башын биләп алган уйлар – шушылар булырга тиеш. Аллаһны риза итүнең иң әһәммиятле якларыннан берсе - бу мәсьәләдә Аннан ярдәм сораудыр. Хз. Сөләйманның ихласлы догасы бу мәсьәләдә мөэминнәргә үрнәк булып тора:

***...”Раббым, миңа, әни һәм әтиемә биргән нигъмәткә шөкер итүемне һәм Син риза булачак изге бер гамәлдә булуымны илһам ит һәм мине мәрхәмәтең белән изге колларың арасына керт.”*** (Нәмл Сүрәсе, 19)

# КЕШЕ ГАҖИЗЛЕГЕНЕҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Кеше иртән ятагыннан торыр-тормас гаҗиз бер барлык булганын аңлап фикерли башлар. Һәр иртә, шөбһәсез, йөзен уювы, тешләрен чистартувы кирәк. Боларны күргән кеше башка гаҗизлекләрен дә аера башлар. Мәсәлән, һәркөн юынырга тиешлеге, тиресе артыннан карарга тиешлеге, гәүдәсенең инфекцияга бик ачык булувы, йокысызлыкка, ачлыкка һәм сусызлыкка түзә алмавы - һәрвакыт гаҗизлегенең күрсәткечләредер.

Иртән көзгегә караган кешенең әгәр яше алга барса, акылына тагын башка фикерләр дә килер. Тормышының якынча беренче 20 яшеннән соң беренче картаю билгеләре башлана. 30 яшьләренә килгәндә күз астлары, авыз кырыйлары җыерыла башлаган, тиресенең элеккеге яшьлеге калмаган, гәүдәсенең күп өлеше деформациялэнә башлаган. Яше дә алга киткән саен чәчләре агарган, хәтта куллары да картайгандыр.

Боларны фикерләгән кеше өчен картлык - дөнья тормышының үтүвен күрсәткән, кешенең дөньяга саранларча бaгланувын киртәләгән иң тәэсирле вакыйгалардан берседер. Картая башлаган кеше, моннан соң картлык тормышы белән бәйле кире бер исәп башланганын аңлар. Асылында, картайган һәм кире исәпне башлаган – кешенең гәүдәседер. Гәүдә көн үткән саен черер, барытик кешенең рухында картаю булмас. Кешеләрнең күбесе яшьлекләрендә матур яки ямьсез булуларының ныклы тәэсире астында калырлар. Гадәттә, матур булган горурдыр, ямьсез булган исә зәгыйфь һәм бәхетсез булыр. Картлык исә гәүдә матурлыгының яки ямьсезлегенең никадәр үтүче булганын, Аллаһ Катында бердән-бер яраклы булганының һәм кешенең бердән-бер казанычының Аллаһка булган баглылыгы белән күрсәткән матур әхлак икәнен күрсәткән мөһим бер гыйбрәт.

***Искәрмәсез һәр кеше, иртән торган вакыттан башлап, бик күп гаҗизлеген күрүуга дучардыр. Аллаһ дөнья тормышында яраткан бу кимчелекләрне фикерләвебезне теләр.***

***Аллаһ сезне көчсез итеп яратты, соңыннан (бу) көчсезлек артыннан бер куәт бирде, аннан соң бу көч артыннан бер көчсезлек һәм картлык бирде. Теләгәнне бар итер. Ул белүче, көч җиткерүчедер.*** (Рум Сүрәсе, 54)

Кеше бу гаҗизлекләре белән очрашканында, һәртөрле кимчелектән пакъ булган, бердәнбер хатасыз барлыкның Аллаһ булганын аңлар һәм Аллаһның бөеклеген тәсбих итәр. Аллаһ кешенең һәр гаҗизлеген бер хикмәт белән яраткандыр. Кешеләрнең дөнья тормышына багланмаулары, дөньяда ия булган белән азып китмәүләре – бу хикмәтләрнең кайберәүләредер. Боларны төшенеп аңлаган кеше Ахирәттә Аллаһның үзен барлык бу кимчелекләрдән арынган буларак яратувын теләр.

Булган гаҗизлекләр бик мөһим төшенчәне дә акылына китерер: кара туфрактан чыккан бер гөл бик тәмле исле, ә кешенең карамаган очракта гәүдәсендә барлыкка килгән иснең түзә алмаслык булувы, бигрәк тә тәкәбберле һәм үзен ошаткан кешеләрнең шул нәрсә өстендә төшенеп гыйбрәт алуларын кирәк иткән бер хәлдер.

# КЕШЕ ГӘҮДӘСЕНДӘГЕ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРНЕҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Кеше иртән көзгегә карауны дәвам иткәндә, башына һич уйламаган нәрсәләр дә килә алыр. Мәсәлән, кешенең керфекләре, кашлары, сөякләре, тешләре билгеле бер буйга җиткәндә үсүләрен туктатыр. Фәкать чәчләренең үсүве туктамас. Ягъни, үсүве зарарлы була алачак, начар бер күренешкә сәбәп була алачак чәчләр үзләренең үсүвен туктатыр. Монарда, ягъни сөякләр үскән вакытта да, нәкъ бер гармония һәм пропорциональлеге бар. Мәсәлән, кешенең кул сөякләре кирәгеннән артык үсеп, гәүдәсе кыска калмас. Һәрберсе никадәр үскәнен белгән кебек, нәкъ вакытында туктар. Әлбәттә, монда саналганнар гәүдәдә барлыкка килгән бертөркем физик йогынтыларның нәтиҗәсендә формалашыр. Барытик фикерләгән кешенең акылына шул да килер: бу химик реакцияләр ничек итеп чынга аша? Кирәк булган һәрнәрсәнең кирәк кадәр үсүвен тәэмин иткән гормоннар, энзималар гәүдә эченә кем тарафыннан урнаштырылгандыр? Һәм кем аларның микъдарын, бүленеп чыгу вакытларын контроль итә?

Шиксез, боларның барысын очраклык рәвештә барлыкка килгәнен раслау мөмкин түгел. Кешене барлыкка китергән күзәнәкләрнең, күзәнәкләрне формалаштырган акылсыз атомнарның шулай карар ала белүләре мөмкин түгел. Боларның һәрберсенең кешене иң матур сурәттә яраткан Аллаһның сәнгате булувы ап-ачык уртада.

# ЮЛДА БАРГАНДА...

Кешеләрнең күбесе иртән торып хәзерләнгәннән соң эшләренә, мәктәпкә китү яки тыштагы эшләрен хәл итү өчен юлга чыгар. Бер мөэмин өчен бу юлчылык – Аллаһ риза булачак хәерле эшләр эшләүнең бер башлангычы. Кеше өеннән аерылып, тышка чыгар-чыкмас фикерләргә тиешле чиксез мәсьәлә пәйда булыр. Тирә-якта зур-кечкенә меңнәрчә кеше, машиналар, агачлар, исәбе булмаган бик күп нечкәлек бар. Монда бер мөэминнең караш ноктасы бик аныктыр (ачыктыр). Ул күргән һәрнәрсәдән мөмкин булганча файдаланырга теләр. Вакыйгалар арасыдагы сәбәпләрне фикерләр. Чөнки каршында очраган күренешләр Аллаһның гыйлеме катнашувы һәм Аның теләве белән булгандыр. Шулай булгач, шөбһәсез, бер сәбәбе бар. Аллаһ, аны өеннән чыгарып, каршысына бу күренешләрне чыгарганына күрә, алар өстендә күрергә һәм фикерләргә тиешле нәрсәләр бар. Иртән торган мизгелдән башлап, үзенә дөньяда әҗер (савап)

казандырачак бер көнне тагын биргәне өчен Аллаһка шөкер итәр. Һәм хәзер дә бу әҗерләрне казана алачак бер юлчылыкны башлагандыр. Моны аңлаган кеше, һәрнәрсәне яраткан Аллаһның ***"көнне бер көн-күреш вакыты итеп кылдык"*** (Нәбә Сүрәсе, 11) аятен төшенер. Бу аятькә күрә, көнен башка кешеләргә файдалы булачак, Аллаһ ризасы булган гамәлләр кылачак рәвештә үткәрүнең планнарын төзер.

Акылында бу планнар белән машинасына яки башка бер сәбәпкә ирешкәндә янә Раббыбызга шөкер итәр.

## *Юлда барган вакытта күргәннәребездә дә фикерлиячәк бик күп нәрсә бар*

Чөнки барачак җире никадәр ерак булса да, анда барып җитү мөмкинчелеге бар. Аллаһ бер җиңеллек буларак кешеләргә ирешүдә куллана алыначак бик күп чара (васита) яраткан. Бигрәк тә көнебездә үсеш алган технология белән бу мөмкинлекләр тагы да ныграк арткандыр; машиналар, поездлар, очкычлар, көймәләр, вертолетлар, автобуслар... Боларны фикерләгән кешенең акылына тагын бер бик мөһим мәсьәлә килер: технологияне дә кешенең хезмәтенә биргән Аллаһтыр.

Галимнәр һәркөн яңа әйберләр белән очраша, тормышыбызны җиңелләштерәчәк яңалыклар таба. Һәм боларның барысы да Аллаһның дөньяда яраткан мөмкинлекләре белән чынга аша. Фикерләгән кеше боларның үзенең хезмәтенә бирелгәне өчен Раббыбызга шөкер итеп юлын дәвам итәр.

Бу фикерләр белән барачак җиргә таба юнәлгәнендә, урам арасында күргән бер чүп өеме, пычрак ис, караңгылык, тар, дымлы җирләр дә кешенең акылына төрле уйлар китерер.

Аллаһ дөньяда Җәннәтне дә, Җәһәннәмне дә хыялыбызда җанландыра алырлык итеп яки чагыштыру юлы белән ничек була алачагын чамалый алачагыбыз дәрәҗәдә урыннар һәм күренешләр бар иткән. Чүп өемнәре, пычрак исләр, тар, дымлы һәм караңгы җирләр кешенең рухына зур авырлык бирер. Кеше мондый мөхитләрдә берничек тә булырга теләмәс. Боларның һәркайсы Җәһәннәмне искә төшергән үзенчәлекләрдер һәм күренешләр белән очрашкан кешенең акылына Җәһәннәм аятьләре килер.

### *Фикерләгән кеше технологияне дә кешеләрнең хезмәтенә биргәннең Аллаһ икәнлеген күрер*

### *Юлда барганда күрелгән матур бер күренеш яки тар һәм дымлы бер җир кешегә бик күп нәрсәне аңлата алыр*

Аллаһ Коръәндә Җәһәннәмдәге ямьсез күренешләрне, караңгылыкны, пычракны бик күп аять белән хәбәр иткәндер:

***“Асхаб-и Шималь” (сулдагылар) никадәр (бәхетсез ул) “Асхаб-и Шималь”. Алар күзәнәкләрне яндырган бер кайнарлык һәм кайнар су һәм кап-кара томаннан бер караңгылык эчендә. Ул җиләс тә, рәхәт бирүче дә түгелдер.*** (Вакиа Сүрәсе, 41-44)

***Куллары муеннарына бәйләнгән хәлдә тәмугның иң тар җиренә ташлангач, алар: “(Ах, без) һәлак булдык!”, - дип акырырлар. (Ләкин аларга әйтелер ки): “ Бүген (сез) бер тапкыр һәлак (булуны) юрамагыз, куп тапкырлар һәлак (булуыгызны) юрагыз”.*** (Фуркан Сүрәсе, 13-14)

Коръәннең бу аятьләрен хәтерләгән кеше, шунда ук Аллаһка үзен Җәһәннәм газабыннан саклавы өчен дога итәр, ясаган хаталары өчен гафу сорар.

Бу төр фикерләүгә юнәлмәгән кеше исә көнен сөйләнеп, һәрвакыт бер гаепле табарга тырышып үткәрер. Чүпне атканнар һәм аны җыюны кичектергән шәһәр башлыгына тагылачак – шәһәр хуҗасының хаксыз булувы һәм бик күп мәсьәлә белән көне буе акылын мәшгуль итәчәк. Бу буш уйларның исә үзенә Ахирәттә һичбер файдасы юктыр. Бәлки кеше: “Бер төркем эшне бер тарафка ташлыйммы әллә?” - дип уйлый ала. Чыннан да, күпчелек кеше үзен фикерләүдән ерак тотучы, асыл мәсьәләсенең дөнья өчен бирергә мәҗбүр булганы көрәш булганын белдерер. Туклану, көнкүреш һәм саулык кебек проблемалар аркасында фикерләүнең мөмкин булмаганлыгын сөйләр. Югыйсә, бу - качудан һәм үзен алдаудан башка берни түгелдер. Кешенең җаваплылыклары һәм эчендә булган хәле белән фикерләү арасында һичбер мөнәсәбәт (бәйләнеш) юк. Чөнки Аллаһ ризасы өчен фикерләргә тырышкан кеше, янында Аллаһның ярдәмен табачак. Күрәчәктер ки, үзе өчен проблема кебек күренгән бик күп мәсьәлә бер-бер артлы чишелә, фикерләүгә һәр көн тагын да күбрәк вакыт аера ала. Бу - бары тик мөэминнәр генә яшәп аңлый алачак бер тема.

# ТӨРЛЕ ТӨСЛЕ БЕР ДӨНЬЯНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Юлын дәвам иткән кеше, тирә-ягында һәрмизгелдә Аллаһның аятьләрен, яратылыш могъҗизаларын күрергә, алар турында фикерләп, Раббыбызның бөеклеген тиешенчә бәяләргә тырышыр. Машина тәрәзәсеннән тышка караганда төрле төсле бер дөньяны күрер. Шуңа күрә шулай уйлар: “Ярый, әгәр дөнья төрле төсле булмаса, һәрнәрсә нинди булыр иде?”

Мәсәлән, түбәндәге рәсемнәргә карагыз һәм сез дә фикерләгез. Һичбер төсе булмаган бер диңгез яки бер тау күренешеннән яки бер чәчәктән хәзер ала алганыбыз кебек зәвык (ләззәт) ала алмасак? Күк йөзенең, җимешләрнең, күбәләкләрнең, киемнәрнең, кеше йөзләренең күренешләре хәзер булган кебек ләззәт бирер идеме? Төрле төстәге, ялтыравыклы бер дөньяда яшәвебез безгә Раббыбыз тарафыннан бирелгән бер нигъмәт. Табигатьтә күрелгән һәр төс, җанлыларда булган төсләрнең бер-берсе белән хатасыз рәвештә туры

килүчәнлеге (гармониясе) - Аллаһның тиңдәшсез сәнгатенең һәм охшашсыз яратылышының дәлилләредер. Мәсәлән, бер чәчәкнең яки бер кошның төсләре һәм бу төсләрнең бер-берсе белән туры килүве яки төсләр арасындагы йомшак күчешләре, табигатьтә һәрбер төснең күзебезне рәхәтсез итмәве, мәсәлән, диңгезләр, күк йөзе, агач төсләренең безгә рәхәтлек бирәчәк, күзебезне арытмаячак тоннарда булувы – Аллаһ яратылышының хатасызлыгын күрсәтер. Боларның барысын фикерләгән бер кеше, тирә-ягында күргән һәрнәрсәнең Аллаһның чиксез гыйлеменең һәм кодрәтенең бер әсәре булганын аңлар. Аллаһ безгә биргән бөтен нигъмәтләр каршысында "эче тетрәячәк", Аллаһтан куркып сакланачак һәм хөрмәт-кадерен белмәгән бер кеше булудан Аллаһка сыеначак. Аллаһ, Коръәндә төсләрнең барлыгын хәтерләтеп, бары тик галим булганнарның, ягъни фикерләп эзләштерүче һәм болардан нәтиҗә чыгаручы кешеләрнең Аллаһ куркувына ия булганлыкларын шулай белдерер:

***Аллаһның күктән су иңдергәнен күрмәдеңме? Шулай итеп Без аның белән төрле төстәге, төрле матур җимешләр өлгерттек. Таулардан да ак, кызыл, башка төстәге һәм кап-кара юллар барлыкка китердек. Кешеләр арасында, хайваннар, мал-туар арасында да шундый төстәгеләре бар. Коллары арасында исә Аллаһтан барытик галим булганнар гына "эчләре тетрәп куркарлар." Шик юк ки, Аллаһ һәрвакыт өстен һәм көчле булучы, чиксез ярлыкаучы.*** (Фатыр Сүрәсе, 27-28)

# ЮЛДА КҮРЕЛГӘН БЕР ҖӘНАЗА МАШИНАСЫНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Берәр җиргә барып җитәргә тырышкан кешенең каршысына кинәттән җәназа машинасы чыга ала. Бу исә, асылында, кешене үзенә китерә алачак бик әһәммиятле бер форсат. Каршысына чыккан бу күренеш аңа үлемне хәтерләткән. Бер көн үзе дә шул машинаның эчендә булачак. Монарда һич тә шөбһә юк, никадәр качынылса да иртәме-соңмы үлем аны табачак. Бәлки ятагында, бәлки юлында, бәлки дә ял иткән бер җирендә бу дөньядан шиксез рәвештә аерылачак. Чөнки үлем - качып яшеренә алмаслык бер хакыйкать.

Менә шундый бер мизгелдә мөэминнең акылына Аллаһның шушы аятьләре киләчәк:

***Һәр нәфес үлемне татачак, соңыннан Безгә әйләнеп кайтарылачаксыз. Иман итеп, изге гамәлләрдә булганнарны, аларны, эчендә мәңгелек калучылар буларак, астыннан елгалар аккан Җәннәтнең бөек җирлекләренә һичшиксез урнаштырачакбыз. (Изге) гамәлдә булганнарның әҗере никадәр***

***матур! Алар, сабыр итүчеләр һәм Раббыларына тәвәккәл итүчеләрдер (тапшырылучылыр, таянучылардыр) .*** (Анкәбүт Сүрәсе, 57-59)

Кешенең үз гәүдәсенең дә соңында такта бер табутка куелачагы, өстенең якыннары тарафыннан туфрак белән күмеләчәге, бер кабер ташында исеменең һәм фамилиясенең язылачагы турында уйлануы – аның дөньяга булган баглылыгын уртадан юк итәр. Моңа бик җитди һәм дөрес бер рәвештә төшенгән кеше, бер көнне туфрак астында чериячәк гәүдәгә ия булганлыгының никадәр мәгънәсез икәнен күрер.

## *Бер кешегә очраган җәназа һәрнәрсәдән алда аңа “үзенең үлемен” һәм бу дөньяның кыска һәм үтүче булганын искә төшерергә тиеш*

Аллаһ Анкәбүт сүрәсендәге аятьләрендә сабыр иткәннәрне һәм тәвәккәл итүчеләрне үлемнән соң булучы Җәннәт белән сөендергән. Шуңа күрә, бер көнне үләчәген уйлаган мөэмин, Җәннәткә кавыша алувы өчен Аллаһ әмер иткән матур әхлак буенча яшәргә тырышыр. Үлемнең якынлыгын һәр уйлаганында бу мәсьәләдәге карарлыгы  көчәер һәм гомере үткән саен формалаша биргән өстен әхлакка ия булырга тырышыр.

Һәрвакыт башка фикерләргә әһәммият биреп, буш уйлар белән тормышларын үткәрүчеләр исә, бер җәназа машинасы белән очрашканда гына түгел, һәркөнне каберләр яныннан узсалар да, хәтта бик якын берәүләре үлсә дә, моның бер көнне, шөбһәсез, үз башларына да киләчәген уйламаслар.

# КӨН ЭЧЕНДӘ

Мөэмин көн эчендә очраган вакыйгалар аркылы һәрвакыт Аллаһның аятьләрен фикерләр, вакыйгалардагы нечкәлекләрне, Аллаһ яраткан хикмәтләрне һәм хәерлелекләрне аңларга тырышыр.

Каршысына чыккан берәр матурлыкка яки тискәре кебек күренгән һәр вакыйгага карата гел Аллаһ ризасы булачак матур әхлак мөхитендә каршылык күрсәтер. Иман иткән берәр кеше өчен булган мохитнең бер әһәммияте дә юк; мәктәптә яки сәүдәдә булса да, Аллаһның һәрнәсәне ятатканын фикерләп, Ул яраткан матурлыкларны, вакыйгалардагы хикмәтләрне күрергә тырышыр, Раббыбызның аятьләренә туры килгән итеп яшәр. Инанганнарның бу хәле аятьләрдә шулай хәбәр ителә:

***(Шундый) Кешеләр ки, ни сәүдә, ни алыш-биреш эшләре дә аларны Аллаһны зикер итүдән, дөп-дөрес намаз укудан, зәкят бирүдән берәр нәрсәгә солтап аера алмас. Алар йөрәкләрне тетрәтә торган, күзләргә дәһшәт бирә торган Көннән куркарлар. Чөнки Аллаһ кылган игелекләренә күрә иң гүзәл әҗерне бирәчәк вә аларга үзенең фазыйләтеннән***

***арттырачактыр. Аллаһ ихтияр иткәннәрен (теләгәннәрен) чиксез ризыкландырыр...*** (Нур Сүрәсе, 37-38)

# ЭШЛӘГӘН ЭШТӘ ОЧРАГАН АВЫРЛЫКЛАРНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Кеше көн буена төрле авырлыклар белән каршылаша ала. Әмма, каршылашылган авырлык ни булса булсын, Аллаһка тәвәккәлле хәрәкәт итүве һәм шуларны уйлавы кирәк: “Аллаһ безне бу дөнья тормышында һәр эшләгәнебез белән һәм һәр уйлаганыбыз белән сыный. Бу - бер мизгелгә дә акылыбыздан чыкмаска тиешле бик мөһим бер хакыйкать. Шулай булгач, эшләгән һәртөрле эштә берәр авырлык белән очрашканда яки үз төшенчәбезгә күрә эшләр тиешенчә бармый дип уйланылганда, бу вакыйгаларның безнең хәрәкәтебезне сынау өчен каршыбызга чыгартылганын һич онытырга тиеш түгелбез.”

Кешенең акылыннан үткән бу фикерләр, көндәлек эш эчендә каршылашылган берәр зур яки кечкенә вакыйга өчен яраклы. Мәсәлән, эш җирендә берәр ялгыш аңлашылу аркасында яки берәрсенең игътибарсызлыгы йөзеннән ялгыш җиргә компенсация ясау кирәклеге туарга мөмкин; сәгатьләр буе компьютерда бер папка өстендә эшләнелеп, электрның бетүве аркасында эшләнелгән эшнең бер мизгелдә юкка чыгувы мөмкин; берәр укучы, бик күп тырышувына карамастан, институт экзаменнарын бирә алмаска мөмкин; алып барылган берәр эштә, бик күп бюрократик эш барышы аркылы, кешенең көннәре чиратта көтү белән үтә ала; дәвамлы буларак кимчелекле документ язылa ала һәм бу сәбәптән  эшләр арта кала ала; берәр кеше бик тиз җитешергә кирәк булган берәр җиргә барганда очкычын, автобусын качыра ала... Һәркешенең үз яшәеше эчендә каршылаша алачагы, үзенчә авырлык һәм каршылык (тискәрелек, кирелек) дип уйлаган бу төрле чиксез күренеш бар.

Бу вакыйгаларның һәрбересендә иманлы кеше исә, Аллаһ тарафыннан үзенең хәрәкәте һәм сабырлыгы сыналганын, үләчәк һәм Ахирәттә хисап бирәчәк берәр кешенең, бу вакыйгаларга чумып, алар өчен борчылып вакыт югалтуның урынсыз һәм мәгънәсез икәнлеген аңлар. Барлык бу вакыйгаларның артында берәр хәер булганын белер. Һичбер вакыйга каршында “ах-вах” килмәс. Аллаһка эшләрен җиңеләәтүве өчен дога итәр.

Һәм берәр авырлыкның артыннан җиңеллек килгәнендә, моның Аллаһка юнәлгән доганың бер каршылыгы булганын, Аллаһның догаларны ишеткәнен һәм кабул иткәнен уйлар һәм Аллаһка шөкер итәр.

Боларны фикерләп көнен дәвам иткән кеше, ни белән каршылашса да, катгый өметсезлеккә төшмәс, куркмас, куркып борчылмас, чарасыз хәлдә калмас. Аллаһның һәрнәрсәне бер хәер һәм гүзәллек өчен яратканын белер. Өстәвенә, моның турында барытик башына килә алачак зур вакыйгаларда гына түгел, бераз алда сөйләгәнебез кебек, көнлек тормышы эчендә, кечкенә-зур каршылашкан һәр күренеш вакытында уйлар.

Мәсәлән, планлаган мөһим берәр эше уйлаганы кебек булмаган, барлык уңышка ирешү чаралары үтәлүвенә карамастан, соңгы мизгелдә җитди каршылыкка очраган берәр кешене уйлагыз.

Әгәр бу кеше иман биргән тирән аңлаешка ия булмаса, шунда ук тискәреләнер, авырлыкка бирелер, борчылыр, кыскасы, уңайсызлыклар яшәр. Шулай булгач, һәрнәрсәдә дә берәр хәер булганын аңлаган кеше, Аллаһның бу вакыйга белән үзенә күрсәткән хикмәтләргә төшенеп, аларны табарга тырышыр. Шулай итеп, аңа Аллаһ тарафыннан, бу мәсьәләдә тагын да катгый хәзерлекләр күрүве өчен, ишарәтләр бирелгәне турында уйлар. Техник яктан кирәкле бөтен чараларны күрер һәм “бәлки шулай итеп тагын да олы зарарларның формалашувы алдыннан, чарасы күрелеп болар булмый калган” дип Аллаһка моның өчен шөкер итәр.

Берәр җиргә барып җитәргә тырышканында кирәкле автобусын качырса, “бәлки соңга калувым яки бу автобуска менмәвем мине берәр казадан яки башка берәр начарлыктан саклагандыр”, - дип уйлый алыр. Болар барытик берничә үрнәк. “Моның кебек тагын бик күп хикмәт була ала”, - дип тә уйлар. Бу үрнәкләр кешенең гомеренә кагылышлы буларак тагын да күбәйтелә ала. Фәкать, әһәммиятле булганы шул: кеше төзегән планнар һәрвакыт көтелгән нәтиҗәне бирмәскә дә мөмкин. Кеше үзен бер мизгелдә планлаштырганынан бик аермалы бер мохиттә таба ала. Менә шундый бер хәлдә тәвәккәлле итеп хәрәкәт иткән, очраган вакыйгаларда хәер эзләгән кеше казанышлы (табышлы, керемле). Чөнки Аллаһ аятендә кешеләргә шулай белдерә:

***...Булыр ки хушыгызга китмәгән берәр нәрсә, сезнең өчен хәерледер һәм булыр ки яраткан нәрсәгез дә, сезнең өчен бер начарлыктыр. Аллаһ белер, сез белмәссез.*** (Бакара Сүрәсе, 216)

Аллаһның аятендә дә белдерелгәне кебек, без белмибез, фәкать Аллаһ белер. Гомумән, безнең өчен нәрсәнең хәерле булганын, нәрсәнең начар булганын белгән дә Аллаһтыр. Кешегә калганы, чиксез мәрхәмәт иясе һәм саклаучы Аллаһны дус итенү һәм Аллаһка тулысынча бер тәвәккәл белән тапшырылу.

# БЕРӘР ЭШ ЭШЛӘГӘНДӘ УЙЛАНДЫРГАННАР

Берәр кешенең берәр төрле эш эшләгәндә акылының буш калмавы һәм даими буларак хәер юнәлешендә уйлануы бик әһәммиятле. Чөнки кеше шул ук мизгелдә берничә нәрсәне эшли алу сәләтенә ия. Мәсәлән, машина кулланган, өен чистарткан, спорт белән шөгыльләнгән, юлда йөргән һәркеше, шул ук вакытта хәерле, файдала нәрсәләр турында да дә уйлана ала.

Чисталык ясаган берәр кеше, Аллаһның үзенә су, чистартучы матдәләр кебек мөмкинчелекләрне бирүве аркасында шөкер итәр. Аллаһның чисталыкны һәм чиста кешеләрне сөйгәнен белгәне өчен, эшләгән эшен бер гыйбадәт буларак күрер һәм Аллаһ ризалыгын казаныр. Аеруча, булган

урынын чистартып, башка кешеләр өчен дә рәхәт (комфортлы) мохит ясаудан зәвек алыр.

Яки һәркайсы берәр эштәге кеше эченнән даими Аллаһка дога итәр, ясаган эшне җиңеләйтүвен Раббыбыздан теләр, Аллаһ теләмичә һичбер эшнең дә уңышлы булмаячагына төшенер. Коръәндә безгә үрнәк күрсәтелгән пәйгамбәрләрнең, эчләреннән даими буларак Аллаһка юнәлгәннәрен, берәр囯 эштә булганнарында һәрвакыт Аллаһны уйлаганнарын күрербез. Бу бәхетле кешеләрнең берсе дә Хз. Мусадыр. Хз. Муса юлының өстендә очраган хатыннар төркеменә су эчерүләрендә ярдәмче булганнан соң Аллаһка юнәлгән. Бу вакыйга аятьләрдә шулай хәбәр бирелә:

***Мәдйән суына барган вакытында, су алган бер кеше төркемен күрде. Аларның артларында (хайваннарны су башына китерүдән чигенгән) ике хатын күрде. Диде ки: “Бу хәлегез ни?” “Көтүчеләр малларын эчертмичә, без малларыбызга су эчертә алмыйбыз; әтиебез яше зур булган бер карт”, - диделәр. Шунда ук аларның көтүләрен сулады, соңыннан янә күләгәгә чигенеп әйтте ки: “Раббым, хакыйкатьтә миңа иңдергән һәр хәеренә мохтаҗмын.”***(Касас Сүрәсе, 23-24)

Коръәндә күрелгән башка үрнәгебез дә, Хз. Ибраһим һәм Хз. Исмәгыйль. Аллаһ бу пәйгамбәрләрнең бергә эш эшләгәннәрендә башка иман итүчеләр өчен дә хәерле нәрсәләр уйлаганнарын һәм Үзенә юнәлеп бу мәсьәләдә дога укыганнарын хәбәр иткән. Аятьләрдә шулай боерыла:

***Ибраһим белән Исмәгыйль Кәгъбәтулланың нигезен күтәргәч: “Ий Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син ишетүче һәм күңелләрне белүчесең”, - дип дога кылдылар. “Ий Раббыбыз! Икебезне дә үзеңә итәгать итүче мөселманнардан кыл һәм нәселебездә дә мөселман булган җәмәгатьне насыйп ит һәм безгә хаҗ гамәлләрен өйрәт вә тәүбәләребезне кабул итеп гөнаһларыбызны гафу ит! Син, әлбәттә, тәүбәләрне кабул итүче, рәхимлесең! Ий Раббыбыз! Бездән соң нәселебезгә үзләре арасыннан пәйгамбәр җибәр! Ул пәйгамбәр өйрәтер аларга Синең китабыңны һәм ислам диненең бөтен хөкемнәрен һәм пакьләр аларны мөшриклектән, бидгать гамәлләрдән һәм хәрам нәҗесләрдән. Ий Раббыбыз! Шиксез Сиңа тиңдәш юк, көч-кодрәт иясесең һәм һәр эшне мәслихәтче кылучысың (сәламәтлеккә ирештерүчесең).”*** (Бакара Сүрәсе, 127-129)

## БЕР ҮРМӘКҮЧ ПӘРӘВӘЗЕНЕҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Көнен өендә үткәргән кешенең дә фикерле алачагы бик күп нәрсәсе бар. Мәсәлән, чисталык ясаганда өйнең һәр почмагына пәрәвезен үргән бер

үрмәкүчне күрә алыр. Әгәр, гадәттә, кешенең әһәммият бирмәгән бу бөҗәк турында уйларга тиешлеген аңласа, үзенә яңа ишекләр ачылганын күрәчәктер. Чөнки каршысында күргән кечкенә бөҗәк, Аллаһның өстен яратылышының бер үрнәгедер. Бу үрмәкүчнең үргән пәрәвезендә мөкәммәл (камил) бер симметрия бар. Өстәвенә, үрмәкүч бу пәрәвезне бик тиз һәм ашыгыч рәвештә үрә, бу эшне эшләгәндә кире чигенеп, симметрик булганмы-булмаганмы дип бер тапкыр да контроль итми. Әмма уртада гаять төзек бер эш пәйда була. Кеше бу шакаттыргыч, кимчелексез симметрияне кеп-кечкенә бер үрмәкүчнең ничек башкарып чыга алганын кызыксынып, бераз эзләштергәндә, башка хакыйкатьләр белән дә каршылашыр: үрмәкүч кулланган җеп, шул ук калынлыктагы каучуктан 30%ка тагын да эластиграк. Үрмәкүч үргән бу пәрәвез шулкадәр өстен бер үзенчәлеккә ия ки, кешеләр тарафыннан пуля үткәрмәс жилет ясалуда үрнәк итеп алына. Ягъни күпчелек кеше тарафыннан гади үрмәкүч пәрәвезе буларак күрелгән нәрсә – асылында, дөньядагы иң идеаль индустрия материалы белән тиң кыйммәтлелектәге бер матдә.

Тирә-ягындагы җанлыларның кимчелексез төзеклегенә шаһит булган кеше, бу мәсьәләдә  фикерләвен дәвам итсә, тагын да гаҗәеп хакыйкатьләр белән каршылашыр. Гел күрелгән хәлдә һич игътибар ителмәгән, хәтта, бәлки дә ачуланып үтерергә тырышкан бер чебенне нечкәләп тикшергәндә, аның бик чиста булувына һәм аермалы бер чисталык аңлаешына ия булганын күрер. Чебен еш-еш бер җиргә кунып, кулларын һәм аякларын аерым-аерым чистартыр. Аннан соң канатларын, йөзенә кунган тузанны куллары һәм аяклары белән җентекләп чистартыр. Чиста булувына ышанганчы бу эшләрен дәвам итәр. Башка төрле чебен һәм бөҗәк төрләре дә шул ук рәвештә һәм шундый ук әһәммият биреп чистарыналар. Бу да, чистарынуны аларга Бөек Аллаһ өйрәткәнлеген күрсәтә.

## *Чистарынган бер чебендә бик күп гыйбрәт бар*

Шул ук чебен, очканында канатларын 1 секундта якынча 500 тапкыр кагыр. Мондый тизлеккә кеше ясаган һичбер машина да түзә алмас, ышкылып, ватылып бетәр һәм янар. Фәкать, чебеннең канатларына да мускулларына да, буыннарына да һичбер зарар килмәс. Җилнең ныклыгын һәм юнәлешен дә хисаплап, теләгән якка таба ялгышмыйча оча алыр. Кеше хәзерге  көндә ия булынган технологиясе белән дә хәтта, бу өстен сыйфатларга һәм очыш техникаларына ия булган машина ясалышыннан бик тә ерак. Әмма, чебен дип үтеп киткән һәм күпчелек вакытта игътибар бирелмәгән бер җан иясе, кеше ясый алмаган зур бер эшне башкарып чыга. Әлбәттә, моны чебеннең үзенең үзенчәлекләре һәм акылы белән эшләгәнен раслау мөмкин түгел. Чебендәге бу өстен сыйфатлар – Аллаһның аңа биргән сәләтләредер.

## ***Бал кортларының кечкенә гәүдәләрендә кешеләр өчен шифа булган балны ясаулары - өстендә фикерләргә тиешле бер тема***

Кеше шулай берәр тирә-ягына каранганында, күргән һәр ноктада күз белән күрелгән һәм күрелмәгән бер җанлылык бар. Дөнья өстендә җанлылар булмаган бер сантиметр да юк. Кешеләр, үсемлекләр, хайваннар күрә алган җанлылардан, ләкин кеше күрә алмаган, әмма барлыкларыннан ул хәбәрдар булган җанлылар да бар. Мәсәлән, яшәгән өй эчендәге һәр урын микроскопик җанлылар белән тулы. Шулай ук, сулаган һавада да чиксез вируслар йөри, бакчадагы туфракта күз алдына китерә алмаслык кадәр күпсанлы бактерия яши.

Дөнья өстендәге ышанылмас тыгызлыктагы җанлылыкны фикерләгән кешенең акылына шул җанлылардагы кимчелексез системалары, төзелешләре килер. Күргән җанияләренең барысы да -Аллаһ сәнгатенең ап-ачык бер дәлиле. Шулай ук, микроскопик җанлыларда зур могъҗизалар да яшеренгән. Күз белән күрә алынмаган берәр вирусның, бактериянең яки лечинканың, талпанның, бетләрнең үзләренә күрә гәүдә механизмнары бар. Һәрберсенең яшәгән мөхитен, үрчү шәкелен, үрчү һәм саклану системаларын Аллаһ яраткан. Боларны уйлаган кешенең акылына Аллаһның аятьләре килер. Бер аятьтә шулай боерыла:

***Күпме хайваннар, кошлар,үзләренә ризык хәзерләп куя алмыйлар. Аллаһ аларны да, сезне дә ризыкландырадыр, Ул – Аллаһ сүзләрегезне ишетүче, күңелләрегезне белүчедер.*** (Анкәбүт Сүрәсе, 60)

## ХАСТАЛЫКЛАРНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Кеше – бик күп кимчелекләре булган һәм бу кимчелекләрне бетерү өчен дәвамлы тырышлык күрсәтергә тиешле бер барлык.  Хасталыклар кешенең гаҗизлекләрен бик ачык бер шәкелдә уртага куя. Кеше бу сәбәпле үзе яки берәр танышы чирләгәндә, шөбһәсез, моның хикмәтләре өстендә фикерләргә тиеш. Уйлаганганында, иң гади дип күрелгән грипп авыруының да, кешеләрнең үгет алырлык гыйбрәтләр ташыганын күрер. Хасталанган вакытта шуларны уйлар: башта грипкка сәбәп булган нәрсә - күзгә күренмәслек кадәр кечкенә бер вирус. Барытик бу кадәр кечкенә бер барлык, 60-70 кило авырлыктагы кешене көченнән тайдыруга, йөри алмас, хәтта сөйләшә алмас хәлгә китерүгә илтә. Күпчелек вакытта дарулар, ашаган ризыклар да бер эшкә ярамас. Бердәнбер эшли алачагы – ятып көтү. Гәүдәсендә үзе берничек тә катыша алмаган бер сугыш барлыкка килә. Кеп-кечкенә бер җан иясенең каршында кешенең кулы-аягы баглы калыр. Шундый бер мизгелдә беренче башына килергә тиешле нәрсәсе - Бөек Раббыбыз Аллаһның түбәндәге аятьләре:

***“Мине ашатучы, сусавымны бастыручы да – Ул. Хасталанган чагымда мина шифа биргән дә – Ул. Ул мине утерәчәк, соныннан терелтәчәк. Җәза көнемдә хаталарымны ярлыкаячак, дип өмет иткәнем дә – Ул. Раббым, миңа хикмәт ирештер, гыйлем бир, мине саф мөселманнардан кыл.”*** (Шуара Сүрәсе, 79-83)

Һәртөрле берәр хасталык белән очрашкан кеше, шул вакытында сәламәт чагындагы хәле белән авырган хәлен чагыштырып, икесе арасындагы аерманы төшенергә тиеш. Авырган вакыттагы гаҗиз хәлен, Аллаһка мохтаҗ булганын ничек хис итүвен, мәсәлән, берәр операцияга кергәнендә, һәрнәрсәнең хакиме булган Аллаһка ничек эчтән тырышып дога укыганын, Аны һәрвакыт истә тотырга кирәклеген аңларга тиештер

Бер кешенең хасталыгына шаһит булганда да, шунда ук үз сәламәтлеген уйлап, Аллаһка шөкер итергә тиештер. Мәсәлән, бер мөэмин, аягы гарип калган берсен күргәндә, аягының үзе өчен никадәр бөек һәм мөһим бер нигъмәт булганын аңлар. Һәр иртә торыр-тормас, рәхәтлек белән теләгән җиргә йөрүнең, кирәк булганда йөгерә алуның, беркемгә мохтаҗ булмыйча һәр эшен җиңеллек белән эшли алуның – Аллаһның бер бүләге булуын аңлар. Бу рәвештә чагыштырып фикерләгәне өчен кулындагы нигъмәтләрнең кадерен тагын да яхшырак аңлар.

## *Күзгә күренмәгән бер вирус кешенең зур гәүдәсен ятакка ата ала*

# ГОРУР, КЫЛАНЧЫК, АГРЕССИВ, НАЧАР ӘХЛАКЛЫ БЕРӘРСЕ БЕЛӘН КАРШЫЛАШКАНДА НИЛӘР УЙЛАНЫЛЫР?

Берәр кеше көн эчендә эш урынында яки укуда бик күп төрле кеше белән очраша ала. Әлбәттә, бу кешеләрнең барысы да үзе кебек матур әхлаклы, Аллаһтан курыккан кеше булмаска мөмкин. Андый кешеләр белән каршылашкан кеше, янә Аллаһ әмер иткән өстен әхлак белән яшәр, бервакытта да аларның тәэсирендә калмас. Аларда булган барлык начар әхлакларның сәбәбе – Аллаһ куркувы булмавы һәм Ахирәткә ышанмаганнарыннан  килгәнлеген аңлар. Һәм акылына шулар килер: Аллаһ кешеләрне Җәһәннәм газабы белән куркыта һәм шулай итеп чиксез газапны уйлап, дөньялыктагы хәрәкәтләренең төзәтүләрен, күңелдән Аллаһка юнәлүләрен һәм дини ихласлылык белән яшәүләрен тели. Кеше шундый бөек һәм мөһим бер куркыту белән кара-каршы булганлыгын аңласа, шөбһәсез, бу куркытудан һәм ул кирәктергән нәтиҗәдән сакланыр өчен алдан чарасын күреп, боларны булдырмый калырга тырышыр. Барытик бу куркыту турында

уйланмаган һәм гомумән әһәммиятен аңламаган кешеләр, гүя алар өчен хәзерләнгән ут һәм газап тулы бер урын юк кебек яшәрләр.

Бу хакыйкатьләрне аңлаган кешенең акылына бик әһәммиятле башка фикерләр дә килер. Бу кешеләрнең һәрберсе җәһәннәм утының кырыенда торганда хәлләре, хәрәкәтләре бөтенләй башка булачак. Мәсәлән, бүген кыланчык, әдәпсез һәм горур хәрәкәтләр күрсәтүдән качынмаган кеше, Хисап Көнендә тотылып, җирдән сөйрәлеп һәм дәвамлы түбәнсетелеп Җәһәннәм чокырының янына китерелгәнендә, йөз чагылышы, хәрәкәте, сөйләшү ысулы, кулланган сүзләр шундый, әлеге кебек булмаячак.

***Ул кяферләр фани дөнья тормышына алдандылар. Алар диннәрен бер уен-шаяру кебек итеп тоттылар. Алар шушы көнгә калачакларын онытты, хәтта аятьләребезне инкяр итте, шулай булгач, Без дә аларны оныттык.*** (Араф Сүрәсе, 51)

Яки агрессив, хөрмәт итмәгән, гаеп эшләүдә ачык, һичбер кешелек сыйфаты (дәрәҗәсе) калмаган берәр кеше, шул ук шәкелдә җәһәннәм утының кырыена китерелсә, җәһәннәм газабын күргәне өчен чиксез бер чарасызлыкка төшәчәк (өметсезлеккә биреләчәк).

Дөнья тормышында дин әхлагы буенча яшәү, гыйбадәтләрен җиренә җиткереп үтәү өчен төрле акланулар санаган берәрсе, җәһәннәмнең ишегендә көткәндә, үзенә намаз кылу кушылса, шул ук аклану сүзләрен сөйләмәс.

Менә Аллаһтан курыккан кеше бу хакыйкатьләрне берничек тә акылыннан чыгармас. Җәһәннәм утын фикерләр һәм бу вакытта дөрес хәрәкәтнең, дөрес сүзнең, матур әхлакның ни булганын күрер. Җәһәннәмнең барлыгына катгый ышанганы һәм дәвамлы фикерләгәне өчен, даими Җәһәннәм утының янында кебек күзаллар һәм һәр эшеннән хисапка чигеләчәген төшенеп хәрәкәт итәр.

Аллаһ кешеләргә Җәһәннәмне һәм Хисап Көнен уйлауларын шулар белдергән:

***Аң булыгыз, ул Көнне (Кыямәттә) дөньяда игелек кылган булса да, яманлык кылган булса да, һәркем үз әҗерен табар; кеше кылган яманлыкларыннан ерак арада торырга теләр. Аллаһ асылда сезне (Үзенә каршы килүдән) куркырга боера. Аллаһ колларына чиксез шәфкатьледер.*** (Ал-и Имран Сүрәсе, 30)

# АШАГАН ВАКЫТТА...

***Җирне сезнең өчен яшәү мәйданы иткән дә, Күкне дә сезнең өчен гөмбәз итеп ясаган да, сезгә гүзәл рәвеш-кыяфәт биргән дә һәм сезне саф-пакъ тәгамнар белән ризыкландырган да – Аллаһтыр. Менә ул инде сезнең Раббыгыз. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ – бөекләрдән дә бөектер.*** (Мөэмин Сүрәсе, 64)

## *Аллаһ кешеләрне төрле ризыклар белән нигъмәтләндергән. Төрле тәм һәм исләрдәге, хушыбызга киткән меңләрчә ризык төренең булувы, Аллаһның кешеләр өстендәге мәрхәмәтенең күрсәткече*

Аллаһ кешеләргә дөньяда төрле төрдәге, матур, чиста, ашаганнарга ләззәт бирүче ризык һәм эчемлекләр биргән. Әлбәттә, боларның барысы да - Аллаһның чиксез лотыфын (бүләген, нигъмәтен) һәм кешеләр өстендәге мәрхәмәтенең берәр чагылышы. Кешеләр бертөрле ризык һәм эчемлек белән дә яши алырлар иде дә бәлки, әмма, кешеләргә санаусыз нигъмәт биргән; җиләк-җимешләр, төрле төрдәге итләр...

Бу нигъмәтләрнең барысының Аллаһтан булганын белгән мөэмин дә, өстәл алдына утырганда болар турында фикерләр һәм Раббыбызга шөкер итәр.

## **<u>Ашаган вакытта өстәлдә булган җимешләрне күргәчниләр уйланылыр</u>**

Коръәннең бик күп аятләрендә Аллаһның кешеләрне төрле ризыклар биреп нигъмәтләндергәне турында сөйләнелә. Өстәл алдына утырган бер кешене алдына бу нигъмәтләр тезелгән. Туфрактан чыккан төрле-төрле үсемлекләр, хайваннар җитешрергән ризыклар өстәлләрне бизи. Кеше болардан зәвек алачак рәвештә яратылган. Берсеннән берсе ләззәтле булган бу ризыклар, шул ук вакытта кешенең яшәве өчен дә кирәкле була ала. Бер уйлап карыйк: яшәвебез өчен кирәк булган ризыкларның һич ләззәтләре булмаса, тәмнәре бик начар булса ни эшләр идек? Яки бик ләззәтле булуларына карамастан, болар безгә зарарлы булса иде?... Яки бары тик берничә ризык булса иде һәм кеше алардан бары тик аяктa калу өчен файдаланса иде? Өстәлдә күрелгән рәвештәге бер рәсем, гүзәл манзара белән каршылашуыбызның бердәнбер сәбәбе – Аллаһның безгә булган лотыфы һәм мәрхәмәте. Кеше фәкать җимешләр турында фикерләсә дә, өстендәге нигъмәтләрне аңлый алыр.

Утырган өстәл алдында төрле-төрле җимешләрне күргән акыллы бер кеше шуларны уйлар:

- Кап-кара бер пыяланың эченнән, төрле төсле, төрле исле, эчләре мускус кебек чип-чиста булган җимешләрнең чыгувы – һәрберсенең тәме бик хуш һәм ләззәтле булувы, Аллаһның кешеләргә биргән бөек бер нигъмәте.
- Банан, мандарин, әфлисүн, кавын, карбыз – кыскача, барлык җимешләр үзләренең төргәкләре (төрү материаллары) белән яратылганнар. Һәркайсының кабыгы черүдән, бозылудан һәм тәмләрен саклар. Исләре

дә төргәкләренең эчендә саклана. Төрү материаллары ачылганда исә, бервакыттан соң карала, бозыла башларлар.

- Җимешләрнең һәрберсендә, аерым-аерым тикшергәндә, бик күп нечкәлекләр булганын күрер. Мәсәлән, әфлисүн һәм мандарин узенчәлекле буларак телемләнгән. Бер бөтен хәлендә булсалар, шул кадәр сулы бер җимешне ашау кеше өчен авыр булыр иде. Әмма, Аллаһ аларны кечкенә телем хәленә китереп, кешеләргә җиңеллек тәэмин иткән һәм бер матурлык өстәгән. Шөбһәсез, җимешләрнең эчендәге бу кимчелексез, ихтияҗга күрә һәм бик эстетик төзелеш - өстен бер гыйлем иясе булган Аллаһ яратылышының дәлилләреннән.
- Мәсәлән, җиләк - тышкы күренеше һәм тәме белән бик үзенчәлекле бер җимеш. Өстендәге мотивлары гүя миллиметр-миллиметр үлчәнеп эшләнгән кебек. Кызыл һәм эстетик формасының өстендәге яшел яфраклары белән - Аллаһның тиңдәшсез сәнгать әсәрләреннән берсе. Тәмендәге һәм исендәге матурлык, орлыксыз һәм кабыксыз булганы белән ашаганда һичбер авырлыгының юклыгы, кешегә Җәннәт җимешләрен хәтерләтер. Туфрак эчендә җитлеккән бер җимешнең, шулкадәр матур һәм күзгә ташланып торган бер төскә, шул кадәр тәмле бер искә ия булувы – аны үрнәксез яраткан, сәнгатен, акылын һәм гыйлемен яраткан барлыкларында күрсәтүче Раббыбызны безгә танытыр.
- Һәр ел фасылында аерым җимешләрнең булувы да - өстендә фикерләргә лаяклы бер тема. Мәсәлән, кыш көне кешеләрнең иң күп витаминга ихтыяҗлары булган вакытта, мандарин, әфлисүн һәм грейпфрукт кебек С витамины ягыннан бай җимешләрнең булувы, җәйнең дә кешеләрнең сусавын бетереп рәхәтлек бирә торган чия, кавын, карбыз, персик кебек җимешләрнең чыгувы – Аллаһның кешеләргә лотыфы һәм нигъмәте.
- Җимешләрнең ботакларындагы яки чәчелгән хәлләрендәге күренешләре дә, Аллаһ тарафыннан тәкъдим ителгән бер матурлык. Коп-коры утын өстендә эче сулы, күбесенең тышы үзенчәлек белән ялтыратылган кебек, ботагына ныклы багланган йөзләрчә җимеш күренеше, һәрберсен Аллаһ яратканының дәлилләре. Мәсәлән, тәлгәш-тәлгәш виноградлар, гүя аерым-аерым асылмалы ботакларына урнаштырылган кебектер. Аллаһ һәрберсен тиңдәшсез һәм ишсез яраткан. Ботакларындагы күренешләре исә кешеләрнең хушына китәчәк шәкелдә урнаштырылган. Бу сәбәпле, Аллаһ Коръәндә җәннәтне тасвирлаганда: ***“Җәннәт агачларының күләгәсендә, үрелеп кенә ала торган жимешләр ашап, истирахәт (рәхәтлек) табарлар”*** (Инсан Сүрәсе, 14) аяте белән Җәннәт җимешләренең җыелуга, ягъни ботакларыннан өзелергә хәзер булганнарын белдерә.

Әлбәттә, монда санап үтелгәннәр - бары тик чикле берничә үрнәк. Аллаһ яраткан нигъмәтләр санап бетермәслек кадәр төрле. Ашау өстәлендә моны аңламаган кешенең акылына Аллаһның бер башка аяте килер:

***Яралткан белән яралтырга көченнән килмәгән тиң буламы? Шуны да аңлар дәрәҗәдә түгелмени сез? Аллаһның бәрәкәтен (рәхмәтен, байлыгын) санарга алынсагыз, очына чыга алмассыз. Шик – шөбһәсез ки, Аллаһ ярлыкаучы, гафу итүче.*** (Нахль Сүрәсе, 17-18)

## Тәмнәрнең һәм исләрнең уйлатканнары

Кеше бу рәвешле фикерләргә дәвам иткәнендә, Аллаһ яраткан матурлыкларны һәм нечкәлекләрне бик тә аера башлар. Вөжданлы бер кеше боларның барысын уйлаганда, шул ук вакытта Аллаһ биргән бу нигъмәтләрдән зәвек ала алуның да - янә Раббыбызның иң бөек бер лотыфы булганын акылыннан кичерер. Бигрәк тә, Аллаһның кешеләргә биргән тәм тою һәм ис сизү тойгыларын дөньядагы бик күп матурлыкларны күрүвебез, абайлавыбыз өчен яратканын хәтерләр. Һәм шулай уйлар: әгәр безнең ис сизү тойгысы булмаса иде, чәчәк исеннән, ашаган җимешләрдән, мангалдан хәзер алган зәвегебезне (ләззәтебезне) ала алмас идек. Әгәр тәм тоя алмасак, шоколадның, шикәрнең, итнең, җиләкнең һәм башка нигъмәтләрнең кабатланмас тәмнәренең һичберсен аңлый алмас, тоймас идек.

Шуны онытмаска кирәк: төссез, тәмсез һәм иссез бер дөньяда да яши алыр идек. Һәм Аллаһ боларны безгә нигъмәт буларак бирмәсә, бу матурлыкларны без һичбер шәкелдә куллана алмас идек. Фәкать, Аллаһ һәм исләрне, һәм тәмнәрне, һәм дә боларны сизә алачак тойгы системаларын яратып, моны кешегә чиксез мәрхәмәтеннән биргәндер (насыйп иткәндер).

# БАКЧАДА ЙӨРГӘНДӘ... ТАБИГАТЬТӘ БУЛГАН МАТУРЛЫКЛАРНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Аллаһка иман иткән кеше табигатьтә күргән матурлыклар каршысында Раббыбызны тәсбих итәр, Аны кимчелекләрдән паклар. Булган барлык матурлыкларны хакиме (хуҗасы) булган Аллаһның яратканын аңлар. Барлык матурлыкларның Аллаһка караганлыгын, Аның Җәмал (гүзәллек, матурлык сыйфатлары) сыйфатын чагылдырганын белер.

Кеше табигатьтә йөргәндә алдына һәрвакыттагыдан күбрәк матурлык чыгар. Бер үсентедән чыккан сары ромашка, кошлардан кырмыскага кадәр һәрнәрсә, өстендә фикерләүне кирәк иткән детальләр белән тулы. Кеше болар өстендә уйлаган саен Аллаһның көчен һәм кодрәтен аңлар.

## ***Бөреләрдән үтекләнгән кебек бөрешмичә чыккан чәчәкләр...***

## ***Хушыбызга киткән һәр күренеш Аллаһның сәнгатен танытыр. Бер бакчаның матурлыгын күргән кеше: “Машаллаһ, Аллаһтан башка куәт юктыр”, - диеп Аллаһны бөекләргә, сокланырга тиеш***

## ***Кешенең табигатьтә күргән барлык матурлыклар - Аллаһның өстен һәм тиңдәшсез ярату көченең дәлилләре. Җәннәт исә дөньядагы матурлыклар белән чагыштыра алмаслык кадәр кимчелексез булачак***

Мәсәлән, күбәләкләр - бик эстетик һәм күзләрне сөендергән барлыклар. Неп-нечкә челтәр кебек канатларының өстендәге симметрия, бизәкләрнең кул белән төшерелгән кебек бик төгәл булувы, бер-берсе белән килешеп торган, фосфорлы төсләре белән Бөек Аллаһның тиңдәшсез сәнгатенең һәм өстен ярату көченең дәлилләреннән.

Шул ук шәкелдә җир йөзендәге санаусыз төрдәге үсемлекләр һәм агачлар да Бари булган ягъни яраткан, кимчелексез бар итүче Аллаһ яраткан матурлыклардан. Берсеннән берсе бөтенләй башка төсләргә ия чәчәкләр, аерым күренешле агачлар кешеләргә зәвек бирүче итеп яратылган.
Иман иткән кеше роза, фиалка, ромашка, сөмбел (гиацинт), күке яше (орхидея), канәфер һәм башка чәчәкләрнең ничек итеп шулкадәр шома (тигез, кимчелексез) яссылыклары булганын, бөреләренең эченнән һичбер бөрешкәнлек булмыйча, тип-тигез үтекләнгән кебек ничек чыга алганнарын төшенер.

Аллаһ яраткан бер башка матурлык та - бу чәчәкләрнең искиткеч исләре. Мәсәлән, бер розаның дәвамлы тирә-ягына тараткан, һич үзгәрмәгән ныклы исе бар. Соңгы технология белән дә бу роза исенең бергә бер охшашы ясала алмый. Лабораторияләрдә бу исенең копиясен ясарга тырышканда барлыкка килгән нәтиҗә бик җитешсездер. Бер розаның исенә охшатырга тырышып ясалган исләр, гадәттә, кешедә рәхәтсезлеккә сәбәп булган авыр исләрдер. Югыйсә, роза исе кешедә һичбер рәхәтсезлеккә сәбәп булмас.

Иман иткән кеше боларның һәрберсенең Аллаһны тәсбих ителүве (кимчелекләрдән пакъ дип беленүве), яраткан матурлыкларда Аллаһ сәнгатенең һәм гыйлеменең танылувы өчен яратылган барлыклар булганын белер. Бу сәбәптән бакчасында йөргәндә, бу матурлыкларны күргәндә: ***“Машаллаһ!Аллаһтан башка көч-куәт иясе юк”*** (Кәхф Сүрәсе, 39), - дип Аллаһны бөекләр. Аллаһның барлык бу матурлыкларны кешеләрнең хезмәтенә биргән һәм Ахирәттә алар белән чагыштыра алмаслык

өстенлектәге матурлыкларны иман иткәннәргә бирәчәген хәтерләр. Һәм шуның аркасында Раббыбызга каршы тойган мәхәббәте кат-кат артыр.

## Бакчада йөргәндә күргән бер кырмыска өстендә һич уйландыгызмы?

Кайбер кешеләр тирә-ягындагы күргән җанлылар турында фикерләүне бик кирәк дип тапмас. Һәр көн күргән җан ияләренең кызыксындыргыч үзенчәлекләре була алувы акылларына килмәс. Югыйсә, иман иткән бер кеше өчен, Аллаһ яраткан һәр җанлы хатасыз бер яратылышның эзләрен ташыр. Менә кырмыскалар да бу җан ияләреннән. Иман иткән кеше бакчада йөргәндә, очраткан бер кырмысканы күрмәгәндәй, яныннан үтеп китмәс. Аның шаккатырлык үзенчәлекләрен күреп Аллаһның кимчелексез яратылышына шаһит булыр.

Мәсәлән, бер кырмысканың йөрүвен тикшерү дә уйландыргыч. Миллиметрик нечкәлеккә ия булган аякларын бик тигез шәкелдә бер-бер артлы хәрәкәт иттерер, өстәвенә, кайсы аягының башта, кайсысының соңыннан киләчәген бик яхшы белер. Һич бутамыйча тиз-тиз хәрәкәт итә алыр.

Бу кечкенә бөҗәк, үз гәүдәсеннән тагын да зуррак сыныкларны йөкләр. Бик тырышлык белән аларны өенә ташыр. Үз гәүдәсе белән чагыштырылганда бик озын араларны үтәр. Очы-кырые булмаган бер туфрак нигезендә күренер дә, һичбер юл күрсәтүче булмавына карамастан, өенә таба барыр. Өстәвенә, бу өйнең кереше кешенең исбатлауларында шактый авырланачагы һәм  кечкенә булувына карамастан, ул һич ялгышмас һәм кайда булса да бу өйне табар.

Кеше, бакчада бер-бер артлы төзелгән, зур бер гайрәт белән өйләренә ризык ташырга тырышкан кырмыскаларны күргәч, бу кечкенә җанлының шулай җаны-тәне белән тырышувы өчен нинди максаты була алыр микән дип уйлар. Соңыннан бер кырмысканың бары тик үзе өчен генә түгел, колониясендәге башкалар, королева-кырмыска һәм балалар өчен дә дәвамлы ризык ташыганын аңлар. Шулкадәр кечкенә һәм  үзенең алга киткән мие дә булмаган кырмысканың бу тырышлыкны, дисциплинаны, фәдакарлыкны кайдан белүве - өстендә уйланырга тиешле бер тема. Боларның барысын уйлаганнан соң ясалган нәтиҗә исә: кырмыскалар да, барлык башка җанлылар кебек, Аллаһның илһамы белән хәрәкәт итәрләр, бары тик Аның әмеренә иярерләр.

## Үрелеп үсүче үсемлекләрнең “Акыллы” хәрәкәтләренең уйлатканнары

Бакчада йөргән бер мөэмин, Аллаһ яраткан матурлыклардан берсе булган үрелеп үсүче үсемлекләр белән каршыларшканында, алар турында

уйланыр. Чөнки фикерләгән кеше өчен тирә-ягындагы һәр барлыкта дәрес алачак дәлилләр бар.

Мәсәлән, үрелеп үсүче үсемлекләрнең берәр ботакка яки берәр җисемгә уралулары турында кешеләргә дикъкат, игътибар белән уйланырга кирәк. Әгәр бу үсүне берәр җиргә яздырып, соңыннан тиз кинокадрда карасак, үрелеп үсүче үсемлекләрнең гүя акылга ия бер барлыклар кебек хәрәкәт иткәннәрен күрербез. Гүя алларында берәр ботак булганын күргәннәре кебек, шул ботакка таба үзләрен сузарлар һәм, гадәттә, аркан атып, үзләрен ботакка бagларлар. Хәтта, кайбервакыт берничә тапкыр әйләнеп, үзләрен ныгытып куярлар. Шул рәвештә тиз алга китерләр, юлы беткәннәрендә кире кайтып яки түбәнгә таба төшеп, үзләренә бер юл табарлар. Менә боларга шаһит булган мөэмин, Аллаһ бар иткән барлык җанлыларның үзләренә хас булган, хатасыз системалар белән яратылганын тагын бер тапкыр күрер.

Аеруча берәр үрелеп үсүче үсемлекнең хәрәкәтләрен күзәтүне дәвам иткәнендә, аның тагын бер мөһим үзенчәлегенә шаһит булыр. Үрелеп үсүче үсемлекнең ян тарафларга үсентеләр чыгарып, үзен булган диварның өстенә ныгытып ябыштырганын күрер. Акылсыз бер үсентенең ябышувы шулкадәр көчледер ки, ябышкан дивардан чыгартылганда, диварның буявын да сөртә алыр.

Шундый бер үсентенең барлыгы, боларны күреп өстендә фикерләгән мөэмингә бу үсентене яраткан Аллаһның кодрәтен тагын бер тапкыр күрсәтер.

## Агачларның уйлатканнары

Агачларны һәркөн, һәрҗирдә күрербез, әмма бик биек агачның иң очындагы ботагына, иң очындагы яфрагына кадәр суның ничек ирешә алганлыгы турында һич уйланганыгыз бармы? Бер охшату ясап, андагы гаҗәеплелекне тагын да яхшырак аңлый алырбыз. Квартирагызның подвал катындагы депо эчендәге суның гидрофор яки башка көчле мотор кулланмыйча өске катларга чыгувы мөмкин түгел. Хәтта беренче катка да суны җибәрә алмассыз. Шулай булгач, агачларда да гидрофорга охшаган көчле бер насос системасы бар. Кире хәлдә, агачның гәүдәсенә һәм ботакларына суның ирешә алмавы аркасында, агачлар кыска вакыт эчендә үлә алырлар.

Бары тик Аллаһ һәр агачны кирәкле барлык җиһазлары белән бергә яраткан. Хәтта бик күп агачтагы насос системасы, кешенең үзе яшәгән квартира белән чагыштырылганда, чагыштырылмаслык дәрәҗәдә өстен. Менә тирә-ягындагы һәрнәрсәгә "күргән бер күз" белән караган кешенең, бу барлыкларны күргәндә фикерләгән темалардан берсе дә - шушы.

Бер башка тема исә, яфраклар белән бәйле. Күргәннәре өстендә уйланган берәр кеше агачка караганда, өстендәге яфракларына гадәтләнгән булса да, аларга чираттагы барлыклар буларак карамас. Алар белән бәйле бик

күп кешенең акылына килмәгән нәрсәләр уйлар. Мәсәлән, яфраклар - бик нәфис ясалышлы барлыклар. Барытик, моңа кармастан, кыздырган эсселек астында да корымаслар. Кеше 40 градус эсселек астында бераз торса, тиресенең төсе үзгәрер, кирәгеннән артык су югалтыр. Фәкать, яфраклар, неп-нечкә тамырларыннан бик аз су ала алуларына карамастан, көннәр буе, хәтта айлар буе кыздыручы эсселек астында янмыйча ямь-яшел кала алалар! Менә бу – Аллаһның һәрнәрсәне тиңдәшсез бер гыйлем белән бар иткәнен күрсәткән бер яратылыш могъҗизасы. Иман иткән кеше дә бу яратылыш могъҗизасы турында фикерләп, Раббыбызның бөеклеген бер тапкыр күреп, тәсбих итәр.

***Коры утыннан ямь-яшел һәм җанлы яфракларның чыгувы, метрларча биеклектәге яфракларның неп-нечкә тамырларына кадәр суның ирешә алувы, яфракларның кызган кояш астында да корымаулары... Болар – агачлар уйландырган чиксез темалардан бары тик берничәсе***

## ГАЗЕТА УКЫГАНДА ҺӘМ ТЕЛЕВИЗОР КАРАГАНДА...

Кешеләр, гадәттә, көн эчендә яки кич өйләренә кайткач газета һәм телевизор хәбәрләрен карыйлар. Бу хәбәрдәрдә дә вөҗданлы кеше өчен өстендә фикерләп дәрес алачак, Аллаһның аятьләрен күрәчәк темалар бар.

***Аллаһ куркуы булган кешеләрдә бу күренешләрнең берсе дә булмый***

## Һөҗүм, ачу, җинаять ешлыгының уйлатканнары

Һәркөн газеталарның өченче битләрендә һәм телевизор хәбәрләрендә бик күп кеше үтерү, яралау, бурлык, ташлану, хәйләчелек, үз-үзенә кул салу кебек вакыйгаларның хәбәрләре очрар. Бу вакыйгаларның шулкадәр еш тормышка ашувы, кешеләрнең зур өлеше тарафыннан бу төр хаталарны эшләүгә шулкадәр ачык булувы кешегә Аллаһ динен тотмаган кешеләрнең очраган зарарларын күрсәтер. Бер кешенең акча алу өчен кеп-кечкенә бер баланы корбан итеп алувы, аны бик куркытувы, хәтта үтерә алувы; коралын төбәп, һич курыкмыйча кешенең йөзенә атувы; башка берәрсенең ришвәт алувы, алдавы, үзен-үзе үтерүве... Боларның барысы да - бу кешеләрнең Аллаһтан курыкмауларының, Ахирәтнең барлыгына ышанмауларының бер күрсәткече. Аллаһтан куркып сакланган, Ахирәттә хисап бирәчәген белгән кеше боларның берсен дә эшләмәс. Чөнки боларның һәркайсы - Ахирәттә Җәһәннәм белән каршылык күрсәтеләчәк гамәлләр.

Бер кеше “мин – атеист, Аллаһка ышанмыйм, әмма ришвәт алмам”, - дия алыр. Тик Аллаһтан куркувы булмаган кешенең бу сүзе һич ярарлык булмас. Чөнки булган шартлар үзгәргәндә, сүзендә тормау ихтималы бик көчле. Мәсәлән, бу кеше ашыгыч сәбәп аркасында акча табырга кирәк булганда, каршысына урлауга яки  ришвәт алуга илтүче берәр форсат чыкканында, бу сүзендә тормаска мөмкин. Яки шундый кешенең үз җаны куркыныч астында булганда, янә сүзендә торуы өмет ителмәс. Мәсьәлән: кеше авыр хәлдә ришвәт алудан качынса да, башка бер хәрам фигыльгә юнәлә алыр. Бары тик Аллаһтан куркувы булган кеше өчен шартларның яки урынның алышувы берни үзгәртмәс. Иман иткән кеше, ни булса да, берничек тә Ахирәттә хисабын бирә алмаячак эш эшләмәс.

Бу сәбәпле, һәркөн газеталарда, дус мәҗлесләрендә зарланылган, “бу кешеләргә ни булды?” – дип әйттергән вакыйгаларның сәбәбе - дөньяның төрле өлкәләрендә хаким булган динсезлек. Барлык бу хәбәрләрне күргән мөэмин, боларның өстеннән узып китмәс, бердән-бер чишелешнең кешеләргә Аллаһка мәхәббәтне һәм Аннан куркуны өйрәтеп, мәгънәви кыйммәтләрне җанландыру булганын аңлар. Чөнки Аллаһтан куркып сакланган, Ахирәттә хисап бирәчәген белгән кешеләр катнашкан җәмгыятьтә моның кебек вакыйгаларның булувы мөмкин түгелдер. Шулай итеп, җәмгыятьтә хозур (тынычлык) һәм ышаныч иң өстен дәрәҗәдә булыр.

# ИРТӘГӘ КАДӘР СӨРГӘН (СУЗЫЛГАН) ДИСКУССИЯ ПРОГРАММАЛАРЫНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Яңадан күргәннәре турында уйлануны дәвам иткән кеше өчен телевизорларда урын алган бәхәс программалары да гыйбрәт бирүче.
Бу дискуссия программаларына шул көннең темасы белән иң якыннан таныш һәм шул темада иң күп белеме булган кешеләр чакырыла. Бу кешеләр сәгатьләрчә бер тема турында сөйләшерләр, барытик беркем дә эшнең эченнән чыга алмас һәм бер нәтиҗәгә дә килә алмас. Югыйсә, ул дикуссия программаларына килгәннәр – мәсьәләне  чишә алачак кешеләр.

Өстәвенә, бик күп бәхәснең чишеп табылган җавабы аеруча ачык. Барытик  бер өлеше кешеләрнең шәхси файдалары, тирә-якның басымы астында калулары, җитди чишелеш эзләү юнәлешендәге адымнар урынына, үз исемнәрен алгы планга чыгару гайрәтләре бөтен эшләрне, гадәттә, чишелешсез калдырыр.

Боларның барысына шаһит булган вөҗданлы бер кеше, бу вакыйгалар чыганагының да кешеләрнең Аллаһ диненнән ерак булулары икәнлеген аңлар. Чөнки Аллаһка иман иткән берәр кеше һич тә җаваплылыксыз, чишелешсез һәм ваемсыз бер эш эшли алмас. Аллаһның каршысына чыгарган һәр вакыйгада бер хикмәт булганын; дөньяда һәр мизгел күзәтү астында булганлыгын; акылын, көчен, белемен Аллаһ риза булачак шәкелдә

кулланырга тиешлеген белер. Аеруча, моның кебек программаларны караган бер мөэмин Аллаһның бер аятен дә искә алыр:
***“...кеше күп нәрсә хакында бәхәскә керәдер.”*** (Кәхф сүрәсе, 54)

Бу төр программаларда очраган хәл: кешеләрнең бик күбесендә булган бәхәсләшү , тагы да дөресрәге, тавыш чыгару якларының уртага чыгувы. Бу кешеләрнең зур өлеше, бигрәк тә үзләренә юнәлтелгән сорауны да сизмичә, барытик үзләренең сөйлиячәкләренә генә ияреп, бер мизгел алда аны сөйләргә тырышулары, бер-берләренең сүзен кисүләре, тавышларын җиңеллек белән күтәреп, шунда ук сабырлыкларын югалтып кызып китүләре, хәтта каршындагы кешеләрне хурлап мыскыллаулары, бу кешеләрнең тискәре якларын уртага чыгарулары ягыннан әһәммиятле.

Аллаһ куркувы булган, тулаем җитди һәм дөрес кешеләр җыелган бер мәҗлестә шулкадәргә сузылган һәм нәтиҗәсез калган хәл һич булмас. Максат – Аллаһ ризасы булачак нәтиҗәне табу һәм кешеләргә иң күп файда китерерәчәк, акылга һәм вөҗданга иң туры килгән метод (ысул) табу һәм һич вакыт уздырмыйча тормышка ашыру. Һәркем вөҗдан белән алынган карардан канәгать булганы өчен бернинди дискуссия дә килеп чыкмас.

Берәр кеше каршы чыкса, әгәр бу кешенең ризасызлыгы хаклы сәбәпләргә таянса һәм күрсәткән юлы да дөрес булса, шунда ук аның тәкъдиме кабул ителер. Чөнки Аллаһтан куркып сакланган кешеләр, башкалар кебек горурланып, сүз аңламас бер хәрәкәт күрсәтмәсләр. Аллаһның Коръәндә белдергәне кебек:
***“...һәм һәр белем иясенең өстендә тагы да яхшырак белгән бардыр”*** (Йосыф сүрәсе, 76) дип, иң дөрес булганын тормышка ашырырлар. Киресенчә бер хәлдәге, ягъни бик күп өлкәдә булган, иртәгә кадәр сузылган һәм һичбер нәтиҗә бирмәгән бәхәсләр, кешеләргә дин китергән матур әхлакның һәм бөек характерның булмаганы бер мөхиттә ниләр була алачагын күрсәтүве ягыннан уйландыручы.

## ДӨНЬЯНЫҢ ДҮРТ БЕР ЯНЫНДАГЫ АЧЛЫК ҺӘМ ЯРЛЫЛЫКНЫҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Газета һәм телевизор хәбәрләрендә еш очраган темалардан берсе дә - кешеләр арасында булган гаделсезлек.

Дөньяның бер ягында бик бай һәм мул яшәгән бик зур өлкәләр, икенче ягында да ашар ризыгы, иң гади хасталыкның да дәвалаячак дарувы булмаган, караусызлыктан бер-бер артлы үлгән кешеләр бар. Бу хәл күрсәткән беренче хакыйкат исә - дөньяда булган золым системасы. Чөнки бай булган берничә өлкә өчен шул кешеләрне коткарулары бик җиңел. Мәсәлән, Африкада ачлыктан үлгән кешеләрнең булувына карамастан, анда, Африкада табылган алмаз минералларыннан баеган һәм зур үсеш алып яшәгән җәмгыятьләр бар. Хәерчелек һәм ачлык эчендә яшәгән һәм үлемгә дучар ителгән бу кешеләр урыннарының үзгәртелүве яки яшәгән җирлекләрендә аларның ихтияҗларының тәэмин ителүве бик җиңел булган

хәлдә, дистәләрчә ел бу кешеләр өчен төгәл берәр чишелеш эзләнелми. Югыйсә, бу кешеләргә ярдәм итү - берничә кеше башкарып чыгачак эш түгел. Ныклы җавапның табылувы өчен бик күп кешенең фидакарлыгы һәм үз-үзен аямыйча тырышувы кирәк. Фәкать, бу сыйфатларга ия булучы кешеләр саны дөньяда бик аз.

## *Фәкыйрьләргә һәм ихтыяҗы булганнарга ярдәм итү Аллаһтан куркудан килә*

Боларга карамастан, дөньяның һәр тарафында триллионнарча лира төрле сәбәпләр сәбәпле исраф ителә. Бер якта ризыкның тәмен ошатмаганы өчен чүплеккә аткан, бер якта да ашарына ризык таба алмаганы өчен үлеп яткан кешеләрнең булувы - дөньяда дини әхлак белән яшәмәү китергән бер золым мөхите булувының бик ачык дәлиле.

Боларны күргән кеше, бу золымны юк итәчәк бердәнбер нәрсәнең Аллаһ әмер иткән әхлак буенча яшәү икәнлеген аңлар. Чөнки Аллаһтан курыккан һәм даими вөҗданы белән хәрәкәт иткән кешеләр, шундый золымга һәм хаксызлыкка рөхсәт бирмәсләр. Һичбер рияга юл куймыйча, дөньядагы, кирәк булса бөтен мөмкинлекләрен кулланып, ихтияҗлары булган кешеләргә тиз, кискен һәм һәрвакыт ярдәм итәрләр. Ярлыларга һәм ихтияҗ эчендә булганнарга ярдәм итүнең Аллаһтан һәм Ахирәт Көненнән куркып хәрәкәт иткән кешеләргә карата бер үзенчәлекле сыйфат булганлыгы аятьләрдә шулай аңлатыла:

***Һәм аларның малларында билгеле бер хак бардыр: фәкыйрь һәм ярлы булган(нар) өчен. Алар Кыямәт көненә ышаналар. Раббыларының газабыннан (даими) куркалар.*** (Мәариҗ сүрәсе, 24-27)

***Аңа тойган мәхәббәтләренә карамастан, алар ризыкны фәкыйрьгә, ятимгә һәм әсир булганга бирделәр. "Без сезне бары тик Аллаһның йөзе (ризалыгы) өчен ашатабыз, сездән бер каршылык та, рәхмәт тә көтмибез. Чөнки без куркыныч һәм авыр бер көн аркасында Раббыбыздан куркабыз".*** (Инсан сүрәсе, 8-10)

Ярлыны туендырмау исә, Аллаһтан куркувы булмаган, динсез кешеләрнең сыйфаты. Аятьләрдә шулай боерыла:

***(Аллаһ боера): "Тотыгыз аны һәм шунда ук баглагыз. Соңыннан ут эченә атыгыз. Аннан соң аңа озынлыгы җитмеш аршин булган бер чылбыр тагыгыз. Чөнки ул бөек булган Аллаһка иман итми иде. Ярлыга ризык бирүдә ярдәмче булмый иде. Шуңа күрә бүген аның һичбер якын дусты юктыр. Әрен һәм***

***кан болганчыклыгыннан башка ризыгы да юктыр. Аны хаталанганнардан башкасы ашамас”.*** (Хакка сүрәсе, 30-37)

***1. Гондураста агым һәлакәте 2. Мали Гаода ураган һәлакәте 3. Елгаларның ташувы аркасында сулар астында калган яр буендагы шәһәр 4. Су астында калган башка бер шәһәр 5. Җир белән бер булган бер шәһәр. Барлык бу күренешләр кешеләрнең фикерләп гыйбрәт алулары өчен***

## БӨТЕН ДӨНЬЯДА БАРЛЫККА КИЛГӘН АФӘТЛӘРНЕҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Кешеләрнең телевизорларда яки газеталарда бик еш очраткан хәбәрләреннән берсе – афәт хәбәрләре. Җир йөзендә һәр мизгел кешеләр берәр бәла-каза белән каршылаша ала. Һич көтелмәгән бер мизгелдә ныклы җир тетрәү була ала, янгын чыга ала, агым басувы була ала. Бу хәбәрләрне күргән бер кеше, Аллаһның һәрнәрсәгә көч җиткергәнен, теләгән рәвештә шәһәрне астын өскә китерә алачагын аңлар. Боларны уйлаганда күрер ки: кешенең Аллаһтан башка сыеначак һәм ярдәм сораячак бер барлыгы юк. Иң ныклы биналар, иң алга киткән технология белән җиһазланган шәһәрләр дә Аллаһның газабына каршы тора алмас; бер мизгелдә җир белән бер була алыр.

Аеруча, бу һәлакәт  хәбәрләрен ишеткән яки укыган кеше, Аллаһның бу шәһәргә фәләкәтне бер хикмәт өчен биргәнен дә аңлар. Аллаһ Коръәндә азган кавемнәрне үгет-нәсыйхәт алып уйлансыннар яки эшләгәннәренең каршылыгын күрсеннәр дип дөньяда да газапка дучар иттергәнен белгерткән. Шулай булгач, берәр җәмгыять тә Аллаһ риза булмаячак бер рәвештә яшәсә, Аллаһның газабына очрый ала. Яки Аллаһ бу кешеләрне дөньяда кайбер авырлыклар белән сыный да ала.

Бу ихтималларны уйлаган кеше, боларның барысының үз башына да килә алу мөмкинлегеннән куркыр һәм эшләгән эшләре өчен Аллаһтан гафу үтенер.

Һичбер кеше һәм һичбер кавем башына киләчәк газапны Аллаһ теләмичә киртәли алмас. Бу, теләсә дөньяның иң бай һәи иң көчле өлкәсе булсын, теләсә географик яктан һичбер рискы булмаган бер җир булсын. Аллаһ һичбер өлкәнең башына киләчәк бер бәла-казаны киртәли алмаячагын шулай белгертә:

***Шул өлкә халкы төннәрен йоклаганда аларга авыр газабыбызның килмиячәгеннән имин иделәрме? Яки дә шул өлкә халкы көн яктылыгында, күңел ачканнарында үзләренә авыр***

***газабыбызның  килмиячәгеннән имин иделәрме? (Яки) алар Аллаһның тозагыннан үзләрен сакланган дип уйлый иделәрме? Аллаһның берәр тозагыннан (акылсызларча) иминбез дип, газапка дучар ителгән халыктан башка монардан кем имин була алсын? (Боларның барысы) яшәгән халыктан соң җир йөзенә мирасчы булганнарны дөреслеккә ирештерүве (яки мәйданга чыгарылувы өчен җитмәз) ме? Әгәр без теләсәк, аларга гөнаһлары аркасында бер бәла-каза җибәрер идек һәм йөрәкләренә тап төшерер идек – шулай итеп алар ишетмәс булырлар иде.***(Араф сүрәсе, 97-100)

***Берничә секундлык бер җир тетрәү бөтен шәһәрне җир белән бертигез итү өчен җитәрлек. Барлык бу күренешләрне табигать әсәре дип уйлаганнар ялгышырлар. Чөнки табигать тә, башка барлыклар кебек, үзен яраткан Аллаһның әмерендә.***

Хәбәрләрдә еш-еш очраган бер башка тема да – экономикадагы бозылышлар. Бигрәк тә процент (риба) белән бәйле һәркөнне бик күп кенә тискәре хәбәр чыга. Процентның туктатыла алынмаганын, барлык экономиканы начар якка юнәлткәнен белгерткән хәбәрләрне укыган берәр кеше, харам булган бу күренешнең  шул кадәр таратылувы нәтиҗәсендә, Аллаһ тарафыннан кешеләр керемендәге бәрәкәтне кысып каршылык (җавап) бирелгәнен аңлар.

Коръәннең: ***"Аллаһ рибаны юк итәр дә, сәдакаларны арттырыр. Аллаһ гөнаһкар гөнаһлы) кяферләрнең берсен дә яратмас"*** (Бакара сүрәсе, 276) аятендә белдергәне кебек, Аллаһ процентның бирә алачак керемен юк итә алыр, бәрәкәтен әзәйтә алыр. Янә бу хакыйкать башка бер аятьтә шулай белдерелгән:

***Кешеләрнең малы артсын дип биргән рибагыз Аллаһ катында артмас. Әмма Аллаһның йөзен (ризалыгын) теләп биргән зәкатегез исә, (савапларыгызны һәм керемнәрегезне) кат-кат арттырыр.***(Рум сүрәсе, 39)

Шулай итеп, фикерләгән берәр кеше өчен процент белән бәйле хәбәрләр дә, Аллаһ аятьләренең кешелек җәмгыятьләрендә тормышка ашканлыгын күрсәтүче үрнәклардән.

***Кешеләр газеталарда еш-еш процентның дөнья экономикасына китергән зарар белән бәйле хәбәрләрне***

***укырлар һәм Аллаһ аятьләренең кешеләр өстендә ничек чагылганын уйларлар***

## МАТУР ҖИРЛӘР ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘҮ

Телевизор программаларында, газета һәм журналларда, әлбәттә, Аллаһ яраткан матурлыкларны күрү һәм алар турында фикерләү мөмкин. Монда урын алган матур бер күренешне, матур бер өйне, матур бер бакчаны яки диңгез ярын күзәтү яки шул җирләрдә булу һәркешенең хушына киткән манзаралардан. Бу күренешләр һәрнәрсәдән әввәл кешегә Җәннәтне хәтерләтер. Иманлы  бер кеше дөньяда да бу кадәр бөек нигъмәтләр биргән, бу кадәр гаҗәеп матурлыклар күрсәткән Аллаһның, әлбәттә, Җәннәттә дә тиңдәшсез матур җирләр бар итәчәген бер тапкыр тагын хәтерләр.

Фәкать, боларны күргән кешенең акылына шулар да килер: дөньяда яратылган һәр гүзәллекнең, дөньяның бер имтихан җире булганлыгыннан, төрле кимчелекләре, җитешсезлекләре бар. Мәсәлән, телевизорда күрсәтелгән берәр ял итү җирендә берникадәр вакыт калынганнан соң бу кимчелекләр беленә. Һавасының артык дымлы булувы, диңгезенең кешене рәхәтсез итәчәк кадәр тозлы булувы, тын кысарлык эсселек, чебеннәр - боларның  барытик берничәсе генә. Кояш астында яну һәм шуның аркасында интегү, сәяхәт агентлыгының ялны оештырувындагы кимчелекләр, бергә ял ителгән кешеләрнең чыдый алмаслык дәрәҗәдә булулары кебек дөньяви бик күп авырлыклар һәм теләнмәгән хәлләр булырга мөмкин.

Җәннәттә исә бу гүзәллекләрнең асыллары бар һәм кешене рәхәтсез иткәненең бер нокта кадәре дә булмаячак яки ошатмаган бернинди хәлгә  тап булынмаячак. Кеше дөньяда очраткан һәр гүзәллектә Җәннәткә карата сагыш тояр. Дөньяда Бөек Аллаһның үзенә биргән нигъмәтләр өчен даими шөкер итеп, боларның барысының да Аллаһ рәхмәте белән бирелгән нигъмәтләр булганына төшенеп, монардан зәвек алыр. Әмма, асылларының Җәннәттә булганын белгәне өчен, үзен дөнья матурлыкларына алдатып Ахирәтне дә онытмас. Мәңгелек гүзәллекләргә ия була алырлык, Аллаһның Җәннәтенә керүне хак итәрлек итеп яшәр.

## ГЫЙЛЬМИ БЕР ЖУРНАЛЛАРДА МАТДӘНЕҢ ТӨП ӨЛЕШЕ АТОМ БУЛГАНЛЫГЫН УКУ НИЛӘРГӘ ТӨШЕНДЕРӘ?

Кеше белгән нәрсәләре турында уйланмаса, нечкәлекләренә төшенә алмас, никадәр искиткеч бер мохиттә яшәгәнен аңлый алмас. Шуңа күрә, иман иткән кеше һич тукталмыйча Аллаһ яраткан барлыклар һәм вакыйгалар турында фикерләр. Болар кайвакыт бик күп кеше тарафыннан беленгән

мәсьәләләр булувына карамастан, ул бу мәсьәләләрдән һәркемнән тагын да үзенчәлеклерәк нәтиҗәләр чыгара ала.

Мәсәлән, тирә-яктагы җанлы һәм җансыз һәр барлыкның төп матдәсе атомнар булганлыгын кешеләр яхшы белә. Ягъни күпчелек кеше кулындагы китапның, диванның, эчкән суының һәм тирә-ягында күргән һәрнәрсәнең атомнардан формалашканын белер. Әмма, моның икенче ягын фикерләп, Аллаһның өстен кодрәтен күрүчеләр - барытик вөҗданлы кешеләр. Шулай итеп, кеше бу тема белән бәйле бер хәбәр күргәндә шуларны уйлар: атомнар - җансыз барлыклар. Шулай булгач, атомнар кебек җансыз матдәләр бер арага килеп ничек күрә алган, сизә алган, ишеткәннәрен аңлата алган (тәфсилләгән), тыңлаган музыкадан зәвек ала алган, фикерли алган, карар бирә алган, сөенә яки газаплана алган кешене формалаштырганнар? Кеше үзен башка атом өеме барлыкларыннан бөтенләй аерган бу үзенчәлекләрне ничек туплаган соң?

Әлбәттә, кешегә барлык бу инсани (кешегә хас) үзенчәлекләрне җансыз һәм акылсыз атомнар бирә алмаслар.Кешене шушы сыйфатларга ия булган рух белән бар итүченең Аллаһ икәнлеге ап-ачык бер хакыйкать. Һәм моның артыннан кешенең акылына Аллаһның бер аяте килер. Аятьтә шулай боерыла:

***Ул яраткан һәрнәрсәсен иң матур бар иткән һәм кешене бер балчыктан ярата башлагандыр. Соңыннан аның нәселен бер нигездән (буыннан), гади бер судан ясагандыр. Шуннан соң, аны формалаштырып, бер шәкелгә китерде һәм аңа рух өрде. Сезнең өчен дә колак, күз һәм йөрәк бар итте. Ә сез никадәр аз шөкер итәсез!*** (Сәҗдә сүрәсе, 7-9)

***Сәгатегезнең, ашалган ризыкларыгызның, яшәгән бинагызның, машинагызның, күзлегегезнең, песиегезнең, бакчадагы чәчәкләрнең, компьютерыгызның, диңгезләрнең, күк йөзенең һәм үз гәүдәгезнең төзелеше шул ук атомнар булганын моңа кадәр уйлаганыгыз бар идеме?***

# КЕШЕЛӘР ТИРӘН ФИКЕРЛӘҮ АРКЫЛЫ ИРЕШКӘН КАЙБЕР ХАКЫЙКАТЬЛӘР...

Һәрнәрсәнең кеше өчен яратылганын уйлаган идегезме?

Аллаһка ышанган кеше тирә-ягында булган җанлы-җансыз бөтен барлыкларны һәм системаларны диккатьле (игътибарлы) күз белән нечкәләгәндә, аларның барысының да кеше өчен яратылганын ачык итеп күрер. Бернәрсәнең дә очраклы булмаганын, Аллаһның һәрнәрсәне кеше яшәешенә туры килгән шәкелдә бар иткәнен аңлар.

Мәсәлән, кеше һәр мизгел бик рәхәт сулый ала. Сулаган һава ни тын юлын ялкынсындырыр, башны да әйләндермәс, башны авырттырмас та. Чөнки һавадагы газларның пропорциясе кеше гәүдәсенә иң яраклы микъдарда көйләнгән. Боларны уйлаган кешенең акылына бик мөһим бер нечкәлек тә килер: әгәр атмосферадагы кислород контингенты (өлеше) бар булган микъдарыннан аз гына күбрәк яки бераз гына азрак булса , һәр ике хәл җанлы барлыкларның юк булувына сәбәп булыр иде. Шуңа күрә, кайбер һавасыз җирдә калынганда никадәр авыр сулыш алынганлыгын төшенер. Иманлы кеше бу тема өстендә фикерләвен дәвам иткән саен, даими рәвештә Раббыбызга шөкер итер. Чөнки дөнья атмосферасының, бик күп планеталардагы кебек, авыр суланачак шәкелдә була алувын, тик шулай булмаганлыгын һәм дөнья атмосферасының миллиардларча кешенең рәхәтлек белән сулый алырлык рәвештә бик хатасыз бер тигезлек һәм тәртип эчендә яратылганын күрер.

Янә өстендә яшәгән планета турында уйлануvын дәвам иткән кеше, Аллаһ яраткан суның кеше тормышында никадәр зур әһәммияте булганын аңлар. Акылына шулар килер: кешеләр озак вакыт судан мәхрүм калганда суның кадерен аңлар. Югыйсә, су гомеребезнең һәр мизгелендә кирәк булган бер нәрсә. Мәсәлән, күзәнәкләребезнең, гәүдәбезнең һәр ноктасына ирешкән каныбызның зур бер өлешен су тәшкил итә. Әгәр шулай булмаса, канның ага торган сәләте әзәер, тамырларыбызда хәрәкәт итүве авыр хәлгә килер иде. Суның агу сәләте бары тик безнең гәүдәбез өчен түгел, үсемлекләр өчен дә бик әһәммиятле. Шуның өчен су, яфракларның неп-нечкә тамырларыннан үтеп, яфракның иң очына ирешә ала.

Диңгезләрдәге күп су массалары дөньябызның яши алынган бер планета булувын тәэмин итә. Әгәр дә җир йөзендәге диңгезләрнең пропорциясе булганыннан түбәнрәк булса, ул вакытта җир йөзе чүлгә әйләнер һәм яшәү мөмкин булмас иде.

Боларга төшенгән вөжданлы кеше, дөньяда шул кадәр хатасыз бер тигезлек саклануның, әлбәттә, очраклы булмавын катгый рәвештә аңлар. Боларның барысын да күрү һәм фикерләү аңа кодрәтле, көч иясе булган Аллаһның һәрнәрсәне бер максат өчен бар иткәнен күрсәтер.

Өстәвенә, бу тема буенча сөйләнелгән үрнәкләрнең бик чикләнгән булувы да акылына килер. Шулай ки, дөньядагы тигезлекләр белән бәйле үрнәкләрне санап бетерүве мөмкин түгел. Барытик фикерләгән кеше генә тирә-якның һәр почмагында булган төзеклекне, кимчелексезлекне һәм тигезлекне ачык итеп күрә алыр һәм моның нәтиҗәсендә Аллаһ һәрнәрсәне кеше өчен яратканын аңлар. Аллаһ бу хакыйкатьне Коръәндә шулай белдерә:

***Үзеннән (бер нигъмәт буларак) күкләрдә һәм җирдә булганнарның барчасын сезгә баш идертте. Шиксез монда фикерләгән бер кавем өчен төгәл аятьләр (ишарәтләр) бар.*** (Җасия сүрәсе, 13)

# МӘҢГЕЛЕКНЕҢ УЙЛАТКАННАРЫ

Мәңгелек төшенчәсен һәркем белер, ләкин сезнең мәңгелек турында уйлаганганыгыз бармы? Аллаһка иман иткән кешенең уйланган нәрсәләренең берсе дә бу.

Аллаһның Җәннәт һәм Җәһәннәм тормышын мәңгелек итеп яратканлыгы - һәр кеше фикерләргә тиешле бик мөһим бер тема. Моны уйлаган кешенең акылына шулар килер: Җәннәтнең мәңгелек булувы, үлемнән соңгы тормышта бирелгән иң бөек нигъмәт һәм бүләкләрдән берседер. Чөнки Җәннәттәге күркәм яшәүнең һич соңы булмаячак. Кеше дөньяда иң күбе 100 елга кадәр яши ала. Әмма Җәннәттәге яшәү катрильон тапкыр  катрильон  ел буе , һич бетмичә, мәңге дәвам итәчәк.

Боларны исендә тоткан кешенең акылына кешеләрнең мәңгелекне аңлавы бик авыр булганы да килер. Моны түбәндәге бер үрнәк ачыклый ала: 100 триллион кеше булса, көн-төн һич туктамыйча 100 триллионны 100 триллион белән тапкырлап алга барсалар, 100 триллион еллык гомерләре булса һәм гомерләре буе шул эш белән мәшгуль булсалар, ирешкән саннары янә дә мәңгелек тормыштагы ел саны янында “ноль” кебек калыр!

Менә шуларны уйлаган кеше шушы нәтиҗәгә килер: Аллаһ шундый бөек гыйлемгә иядер ки, кешегә күрә “мәңгелек” булган, Аның Катында юк хәлендә.

Заманның беренче яратылган мизгеленнән мәңгелеккә кадәр узачак һәр вакыйга, һәр төшенчә, вакытлары һәм шәкелләре белән Аның гыйлеме белән билгеләнгән һәм беткән (тәмамланган) хәлдә.Аллаһны заман белән чикли алмавыбыз сәбәпле: Аллаһ катында һәрнәрсә инде булып беткәндер.

***Өстендә яшәгән планетабыз, космосыбыз кешенең яшәве өчен кирәк булган үзенчәлекләрнең барысына да ия. Моның турында уйланган кеше бөтен тирә-якны Аллаһның үзе өчен яратканын ачык итеп күрәчәк.***

Кешенең шулай ук Җәһәннәмнең  инкярьчылар өчен мәңге калыначак бер урын булганын  да аңлавы кирәк. Җәһәннәмдә төрле-төрле газаплар, җәзалар һәм авыр бер тормыш бар. Җәһәннәмдәге инкярьчылар өзлексез физик һәм мәгънәви җәзага тартылырлар. Бу җәзаларның ахыры булмас, йокы яки ял итүгә һич мөмкинчелекләре юк. Әгәр Җәһәннәмдәге тормышның бер азагы булса, бу катрильоннарча елдан соң да булса, Җәһәннәм әһеле өчен бер өмет булыр иде. Фәкать, бу дөньялык тормышта эшләгән гөнаһларының каршылыгы мәңгелек бер газаптыр:

***Аятьләребезне ялган диючеләр һәм аларга каршы бөекләнгәннәр – утның дусларыдыр, анда мәңге калачаклардыр.*** (Әграф сүрәсе, 36)

Бу сәбәптән мәңгелекне уйлап аңларга тырышу һәркем өчен бик әһәммиятле. Кешенең Ахирәт өчен булган тырышлыгын арттырыр, куркувын һәм өметен куәтләндерер. Мәңгелек газаптан бик куркып сакланувы белән, мәңгелек Җәннәткә керү өметенә дә ия булыр.

## ТӨШЛӘР ТУРЫНДА НИЛӘР УЙЛАНЫР?

Фикерләгән бер кеше өчен төшләрендә дә әһәммиятле хикмәтләр бар. Мондый кеше йоклаганда күргән төшләренең никадәр “чынлыкта кебек” булганлыгын, хәтта уянган вакытыннан әллә ни бик аерылмаганлыгын уйлар. Мәсәлән, төнлә гәүдәсенең ятакта ятувына карамастан, төшендә эшкә чыккан, кешеләр белән танышкан, музыка тыңлаган, ризык ашагандыр. Хәтта ризыгының тәмен татыган, музыкага биегән, булган вакыйгалардан хисләнгән, сөенгән, борчылган, курку тойган, арыганлык хис иткән, хәтта шул көнгә кадәр һич кулланмаган һәм ничек кулланылганын да белмәгән бер җиһазны куллана алган.

Гәүдәсенең бер урында хәрәкәтсез ятувына һәм күзләренең капланган булувына карамастан, дәвамлы яшәгән гадәти урыныннан аермалы манзаралар күргән. Димәк ки, күрүче – аның күзләре түгелд. Йоклаган бүлмәсе буп-буш булувына карамастан, тавышлар ишеткән. Димәк ки, ишеткән - аның колаклар түгел. Һәрнәрсә миенең эчендә тормышка ашкан. Барытик, гүя һәр күргәненең асылы булганы кебек, һәрнәрсә бик чынлыкка охшаган. Ярый, дөньяда асылы булмавына карамастан, моның кадәр чынга охшаган сәхнәләрне кешенең миенә нәрсә урнаштыра? Кеше йоклаганда боларны белеп һәм теләп акылында бар итә алмас. Миенең исә үз-үзенә шундый күренешләрне барлыкка китерүве мөмкин түгелдер. Ми - протеин молекулаларыннан бар ителгән бер ит өеме генә. Шундый бер матдәнең үзлегеннән күренеш бар итүвен, хәтта шул көнгә кадәр һич күрелмәгән кеше йөзләрен, табигатьне, тавышларны ясавын раслау бигрәк тә мантыксыз (логикасыз) булыр. Шулай булгач, йоклаганда төштәге сәхнәләрне кем күрсәтә? Боларны уйлаган кеше ачык дөреслекне бер тапкыр яңадан күрер: кешеләрне йоклаткан, йокы вакытында рухларын алган, уянганнан соң кире биргән һәм йокыда төшләрне күрсәткән Аллаһтыр.

Төшләрне Аллаһ күрсәтә дип белгән кеше, төшләрнең хикмәтләрен һәм яратылыш максатын да уйлар. Төш вакытында, уяник булганындагы кебек, яшәгән вакыйгалардан һәм кешеләрдән иминдер кеше. Һәркайсысын чыннан да бар икәнен, төшендә күргән яшәешнең өзлексез һәм дәвамлы дип уйлый. Хәтта берәрсе янына килеп: “ Хәзерге вакытта төш күрәсең, уян!” - дисә, аңа ышанмас. Боларны аера белгән кеше исә шулай уйлар: “ Бу дөнья тормышының да үтүчән һәм төшкә охшаган бер яшәү булмаганлыгын кем әйтә алыр? **Шул ук төштән уянганым кебек беркөнне бу дөнья тормышыннан да уяначакмын һәм бөтенләй башка күренешләрне, мәсәлән, Ахирәт күренешләрен күрәчәкмен...”**

***Аллаһ үләчәк вакытларында җаннарын алыр, үлмәгәнне дә йокысында (бер төрле үлемгә хөкем итәр). Шулай итеп үзе турында үлем карары бирелгәнне (ң рухын) тотар, икенчесенең дә билгеле бер әҗәлгә кадәр соңга калдырыр. Шиксез, монда фикерләгән кавем өчен чыннан да аятьләр бардыр.*** ***(Зүмәр сүрәсе, 42)***

# КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ ӨСТЕНДӘ УЙЛАНУ

Изге китабыбыз Коръән – Аллаһның бөтен кешеләргә иңдергән соңгы китабы. Дөньяда яшәгән һәркеше Коръәнне өйрәнү һәм анда белдерелгән әмерләрне үтәү белән вазифалы. Тик кешеләрнең зур өлеше Коръәнне изге бер китап буларак кабул итүләренә карамастан , аны өйрәнмәсләр һәм Коръәндәге Аллаһ әмерләрен җиренә җиткермәсләр. Бу – Көръән турында һич уйланмаганлыкларының, Коръәнне тегеннән-моннан ишетелгәннәр аркылы тануларының бер нәтиҗәсе. Фикерләгән бер кеше өчен Коръәннең әһәммияте һәм кеше тормышындагы урыны исә бик зур.

Һәрнәрсә алдыннан "уйланган" кеше, үзен һәм эчендә булган тирә-якны юктан бар иткән, үзе һичнәрсә булмаганы килне җан биргән, санаусыз нигъмәт һәм матурлык белән бүләкләгән Яратучыбызны таныргa һәм Аның кайсы хәрәкәтләрдән, гамәлләрдән хуш (риза) булганын белергә теләр. Аллаһның илчесе вәсиләсе аркылы Коръән - кешенең бу сорауларына җавап биргән юл күрсәтүче. Бу сәбәптән, кешенең Аллаһ кешеләргә туры юл күрсәтүче буларак иңдергән, дөреслек һәм ялгышларны бер-берсеннән аерган китабын бик яхшы белүве, һәр аять өстендә фикерләп, Аллаһның әмер иткәннәрне иң тугры һәм иң матур рәвештә тормышка ашырувы кирәк.

Аллаһ Коръәннең кешеләргә нинди максат белән иңдерелгәнен шулай хәбәр итә:

***(Бу Коръән) аятьләрен яхшы аңласыннар һәм чиста акылга ия булганнар үгет-нәсыйхәт алсыннар дип сиңа иңдергән мөбарәк китабыбыздыр.*** (Сад сүрәсе, 29)

***Хакыйкать (шул ки): ул (Коръән), әлбәттә, бер үгеттер. Моннан соң кем тели, үгет алып фикерләр.*** (Мүддәссир сүрәсе, 54-55)

Бик күп кеше Коръәнне укыр, фәкать мөһим булганы, Аллаһ аятьләрендә дә белдерткәнчә, укылган һәр Коръән аяте турында фикерләү, шул аятьтән бер үгет алу һәм хәрәкәтләрен бу үгетләргә күрә төзәтү. Мәсәлән, Коръәндә хәбәр бирелгән: ***"Димәк ки, чынлыкта авырлыктан соң җиңеллек бар. Чыннан да, авырлыктан соң җиңеллек бар."*** Бу (Инширах сүрәсе, 5-6) аятьләрне укыган кеше, бу аятьләр өстендә уйланыр. Аллаһның һәр авырлыктан соң бер җиңеллек бар итәчәген, шулай булгач, һәртөрле бер авырлык белән каршылашканында (очрашканында) бердәнбер эшлиячәгенең – Аллаһка тәвәккәл итеп (тапшырып), җиңеллек көтү булганын аңлар. Аллаһның шундый бер вәгъдәсе булганда, авыр вакытларда паникага яки өметсезлеккә бирелүнең исә иманда бер зәгыйфлек галәмәте булганына төшенер. Һәм бу аятьне укып фикерләгәч, хәрәкәтләре гомере буе аятьтә әйтелгәнчә булыр.

Аллаһ безгә Коръәндә элек яшәгән пәйгамбәрләрнең һәм илчеләрнең тормышларыннан кайбер нәрсәләрне Үзе риза булачак гамәлләрнең, сөйләшүләрнең һәм тормышның нинди булганлыгын күрсәтер һәм үрнәк булувы өчен җиткерә. Аллаһ илчеләре кыйссалары (хикәяләре) турында уйлануның һәм кешеләргә бу кыйссалардан үгет алуның кирәклеге кайбер аятьләрдә шулай белдерелә:

***Ант булсын ки, аларның кыйссаларында чиста акылга ия кешеләр өчен гыйбрәтләр бардыр.*** (Йосыф сүрәсе, 111)

***Муса (вакыйгасын)да да (уйландыручы аятьләр бардыр). Без аны ачык бер дәлил белән Фиргавенгә җибәргән идек.*** (Зариат сүрәсе, 38)

***Шулай итеп Без аны (Нухны) һәм көймәдәге халыкны коткардык һәм моны галәмнәргә бер аять (эченнән дәрес чыгачак бер вакыйга) иттек.***(Анкәбүт сүоәсе, 15)

Коръәндә үткән кавемнәрнең кайбер сыйфатлары, ия булган әхлаклары һәм башларына төшкән бәла-казалары турында да сөйләнелә. Бу темалар белән бәйле аятьләрне, барытик үткән җәмгыятьләрнең башларыннан үткәннәре турында сөйләнелгән тарихи вакыйгалар буларак уку гына зур бер хата булыр. Чөнки Аллаһ моны, башка барлык аятьләре кебек, үткән кавемнәр турында булган аятьләре өстендә фикерләвебез һәм бу кавемнәрнең башларына килгәннәрдән гыйбрәт алып хәрәкәтләребезне төзәтү өчен безгә белдергән. Аятьләрдә шулай боерыла:

***Ант булсын ки, Без сезгә охшаганнарны һәлакәткә очраттык. Фәкать, үгет алып фикерләгән бармы?***(Камәр сүрәсе, 51)

***Һәм аны да такталар һәм кадаклар (белән төзелгән көймә) өстендә ташыдык, күзләребез алдында агып китә иде. (Үзе һәм ул китергәннәр) сукырларча инкярь ителгән (Нух)ка бер бүләк булсын дип. Ант булсын ки, Без моны бер аять (дәрес) буларак җиткердек. Фәкать, үгет алып фикерләгән бармы? Шулай булгач, Минем газабым һәм искәртеп куркутувым ничек булган? Ант булсын ки, Без Коръәнне зикер (нәсыйхәт алып фикерләү) өчен җиңеләйттек. Фәкать, үгет алып уйланган бармы?*** (Камәр сүрәсе, 13-17)

Аллаһ Коръәнне бөтен кешеләргә бер туры юл күрсәтүче итеп индерде. Гомүмән, Коръәннең һәр аяте турында уйлану, һәм һәрбер аятьтән бер дәрес һәм үгет алып, Коръәнгә күрә яшәү Аллаһның ризалыгын, мәрхәмәтен һәм Җәннәтен казануның бердәнбер юлы.

## АЛЛАҺ КОРЪӘНДӘ КЕШЕЛӘРНЕ НӘРСӘЛӘР ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА?

***(Аларны) ап-ачык дәлилләр һәм китаплар белән (җибәрдек). Сиңа да зикерне (Коръәнне) бирдек ки – кешеләр үзләре өчен иңдерелгәнне ачыкласын һәм алар да <u>яхшылап уйласыннар дип</u>.*** (Нахль сүрәсе, 44)

Нахль сүрәсендәге бу аятьтә булганы кебек, Аллаһ бик күп аятендә кешеләрне фикер йөртергә чакыра. Аллаһ кушкан мәсьәләләр турында фикерләү, Раббыбыз бар иткән хикмәт һәм яратылыш могъҗизаларын күрү бер гыйбадәттер. Өстендә уйланылган һәр мәсьәлә Аллаһның чиксез көчен, акылын, гыйлемен, сәнгатен һәм башка сыйфатларын танып аңлавыбызга сәбәп булачак.

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕҢ ЯРАТЫЛЫШЫ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Кеше дия ки: “Мин үлгәннән соң чыннан да терелеп чыгачакмынмы?” Кеше башта берни булмаганда чынлыкта Безнең аны ратканыбызны (бар иткәнебезне) <u>уйламыймы?</u>***
(Мәрьям сүрәсе, 66-67)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ КҮКЛӘРНЕҢ ҺӘМ ҖИРНЕҢ ЯРАТЫЛЫШЫ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Шөбһәсез, күкләрнең һәм җирнең яратылувында, төн белән көннең бер-бер артлы килүвендә, кешеләргә яраклы нәрсәләр белән диңгездә йөзгән көймәләрдә, Аллаһ яудырган һәм үзе белән җир йөзенең үлеменнән соң терелткән суда, һәр җанлыны анда үрчетеп таратувында, җилләрне истерүвендә, күк белән җир арасында баш идергән болытларны күчерүвендә <u>фикерләгән бер җәмәгать өчен</u> хакыйкый аятьләр бардыр.***
(Бакара сүрәсе, 164)

***Кешенең яратылышында да фикерләгән кешеләр өчен бик күп гыйбрәт бар.***

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ ДӨНЬЯ ТОРМЫШЫНЫҢ ФАНИ (ҮТҮЧЕ) БУЛГАНЛЫГЫН УЙЛАРГА ЧАКЫРА

***Дөнья тормышы бары тик күктән иңдерелгән су кебектер: ул җир йөзендәге үсемлекләр белән кушылгач, аның белән кешеләр һәм хайваннар туклана. Шулай ки, җир матурлыгын тагып бизәнгән һәм халкы чыннан да аңа көч җиткерә алабыз дип уйлаганда,(нәкъ шушы вакытта) төн яки көн аңа әмеребез килгәндер дә, кичә гүя бернинди байлыгы юк кебек аны тамырыннан урылып атылган бер хәлдә кылганбыз. Фикерләгән туплылык өчен Без аятьләрне берәм-берәм ачыкларбыз.*** (Юныс сүрәсе, 24)

***Кайсыгыз теләр ки, алдыннан елгалар аккан, хөрмәләре, виноградлары булган бер бакчасы булсын, эчендә барлык уңышлары да булсын; фәкать үзенә картлык килсен, өстәвенә зәгыйфь һәм кечкенә балалары булсын (шундый бер хәлдә булганда) аңа (бакчасына) утлы бер давыл туры килеп янып бетсен. Менә Аллаһ сезгә аятьләрне фикерләсеннәр дип, шулай ачыклар.*** (Бакара сүрәсе, 266**)**

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ ИЯ БУЛГАН НИГЪМӘТЛӘР ӨСТЕНДӘ ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Һәм Ул - җирне киңәйтеп озынайткан, анда какшамас таулар һәм елгалар бар иткәндер. Анда уңышларның һәр төреннән икешәр пар яраткандыр, төнне көнгә бөркидер. Шиксез, боларда фикерләгән туплылык өчен хакыйкый аятьләр бардыр. Җир йөзендә бер-берсенә якын күрше материклар бар; йөзем бәйләмнәре, чәчүлекләр, ботаклы һәм ботаксыз хөрмәлекләр дә бар ки, болар берүк су белән суланыр, әмма уңышларында (күләм һәм ләззәттә) кайберсен өстенрәк кыларбыз. Шөбһәсез, боларда акылны кулланган бер җәмгыять өчен чыннын да аятьләр бар.*** (Рад сүрәсе, 3-4)

### *Кеше, Аллаһ яраткан җанлы-җансыз бөтен барлыклар турында фикерләргә тиеш*

# АЛЛАҺ КЕШЕНЕ БӨТЕН ТИРӘ-ЯКНЫҢ КЕШЕ ӨЧЕН ЯРАТЫЛГАНЫН АҢЛАРГА ЧАКЫРА

***Үзеннән (бер нигъмәт буларак) күкләрдә һәм җирдә булганнарның барчасын сезгә баш идертте. Шиксез монда фикерләгән бер кавем өчен төгәл аятьләр (ишарәтләр) бар.*** (Җасия сүрәсе, 13)

***Аның белән сезнең өчен иген, зәйтүн, хөрмәлекләр, виноградлар һәм җимешләрнең һәр төрлесенән үстерер. Шиксез, монда фикерли алган бер кавем өчен аятьләр бар. Төнне, көнне, Кояшны һәм Айны сезнең әмерегезгә бирде; йолдызлар да Аның әмере белән әмергә хәзер кылынган. Шөбһәсез, монда акылны куллана алган бер җәмәгать өчен аятьләр бар. Җирдә сезнең өчен устереп җитештергән төрле төстәгеләрне дә (файдагызга бирде). Шиксез, монда дәрес алып фикерләгән кешеләр өчен аятьләр бар. Диңгезне дә сезнең әмерегезгә биргән Улдыр, аннан чиста ит ашыйсыз һәм кияр өчен аннан бизәк әйберләр чыгарасыз. Көймәләрнең анда (суларны) яра-яра агып киткәнен күрәсез. (Боларның барысы) Аны күбрәк эзләвегез һәм шөкер итүвегез өчендер. Сезне тетрәүгә очрамасыннар дип, җирдә какшамас таулар урнаштырды, елгалар һәм юллар да (ясады). Өмет ителә ки, туры юлны табарсыз. Һәм (башка) ишарәтләр дә (яратты), алар йолдызлар белән туры юлны таба алырлар. Яраткан һич яратмаган кебекмедер? Моннан соң дәрес алып фикерләмәссезме?*** (Нахль сүрәсе, 11-17)

***Төн һәм көннең барителүвен, Дөнья һәм Кояш урыннарын һәм хәрәкәтләрен очраклылыкка бәйләү бөек бер гафләт. Аллаһ төн һәм көнне кешеләр өчен яраткан.***

***Төнне, көнне, Кояшны һәм Айны сезнең әмерегезгә бирде; йолдызлар да Аның әмере белән әмергә хәзер кылынган. Шөбһәсез, монда акылны куллана алган бер җәмәгать өчен аятьләр бар.*** (Нахль сүрәсе, 12)

***Өсләрендәге күккә карамыйлармы? Без аны ничек итеп ясадык һәм аны ничек бизәдек? Аның һичбер чатнаган җире юк. Җирне дә (ничек) җәеп салдык? Анда какшамас таулар куйдык***

***һәм анда күзалгыч һәм искиткеч һәр төрдән (нечкә усемлекләр) утырттык. (Болар) - “куңел белән Аллаһка юнәлгән” һәр кол өчен, “хикмәт белән караган бер күңел күзе” өчен бер зикер (искә төшерү).*** (Каф сүрәсе, 6-8)

## АЛЛАҺ КЕШЕЛӘРНЕ ҮЗ НӘФЕСЛӘРЕ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Уз нәфесләре турында уйланмыйлармы?...*** (Рум сүрәсе, 8)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ МАТУР ӘХЛАК ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Ятимнең малына, ул балигълык (җитлегү, өлгерү) чагына ирешкәнчегә кадәр тимәгез, әгәр ул аның файдасына булмаса. Үлчәвен һәм чамасын гаделлек буенча итегез. Һичбер нәфескә ташый алачагыннан авыррак йөк йөкләмибез. Сөйләгән вакытта, якыныгыз булса да, гадел хөкем итегез. Аллаһ белән килешүдә тугрылык күрсәтегез. Менә боларны, үгет алып фикерләсеннәр дип, сезгә киңәш (әмер) итте.*** (Әнгам сүрәсе, 152)

***Шөбһәсез, Аллаһ гаделлекне, игелекне, якыннарга бирүне әмер итәр, ямьсез оятсызлыклардан (фәхешлектән), начарлыклардан һәм изелүләрдән саклар. Сезгә, нәсихәт алып фикерләсеннәр дип, дәрес бирә.*** (Нахль сүрәсе, 90)

***Әй иман иткәннәр, өйләрегездән башка өйләргә, якынлык корып (рөхсәт алмыйча) һәм (өй хуҗаларына) сәлам бирмичә кермәгез. Бу сезнең өчен тагын да хәерледер, бәлки сез үгет-нәсыйхәт алып фикерләрсез.*** (Нур сүрәсе, 27)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ, АХИРӘТНЕ, КЫЯМӘТ ҺӘМ ХИСАП КӨНЕН УЙЛАРГА ЧАКЫРА

***Һәрбер нәфеснең хәерле эшләренең булувын һәм һәр эшләгән начарлыгы белән үзе арасында ерак бер ара булувын теләгән ул көнне (уйлагыз). Аллаһ сезне Үзеннән саклар. Аллаһ колларына карата шәфкатьледер.*** (Ал-и Имран сүрәсе, 30)

***Көч һәм аеклылыкка (дөрес күрүгә) ия булган колларыбыз Ибраһимны, Исхакны һәм Якубны да хәтерлә. Чынлыкта, Без***

***аларны Ахирәттәге асыл йортны төшенеп, искә алучы ихласлы бәндәләр иттек.***(Сад сүрәсе, 45-46)

***Моннан соң алар кыямәт сәгатенең үзләренә һич көтмәгәндә килүвеннән башкасын көтәләрме? Менә аның ишарәтләре килгән. Фәкать, аларга килгәннән соң үгет алып фикерләүләре аларга нәрсә бирер?*** (Мөхәммәд сүрәсе, 18)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ ЯРАТКАН ҖАНЛЫЛАР ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Раббың бал кортына ваһи (илһам итте) җиткерде: "Тауларда, агачларда һәм яшелчә һәм җимешләр үрмәләп үссен өчен ясалган корылмаларда үзегезгә өй ясагыз. Соңыннан җимешләрнең барысыннан ашагыз, шулай итеп, Раббыгыз җиңеләйткән юллардан йөреп очыгыз. Аларның карыннарыннан төрле төстәге нектарлар чыгар, анда кешеләр өчен бер шифа бардыр. Шиксез, фикерләгән бер кавем өчен хакыйкатьтән монда бер аять бардыр.*** (Нахль сүрәсе, 68-69)

***Ул, Аллаһтыр, Үзеннән башка иляһ юктыр. Башта да, ахырда да мактау Аныкыдыр. Хөкем Аныкыдыр һәм Аңа кайтарылачаксыз.*** (Касас сүрәсе, 70)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ КИНӘТ КИЛӘ АЛАЧАК ГАЗАПЛАР ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Әйт ки: "Сезнең уйлаганыгыз бармы: әгәр дә сезгә Аллаһның газабы килсә яки сәгать (Кыямәт) килеп җитсә, Аллаһтан башкасын чакырачаксызмы? Әгәр дә тугры (дөрес) сүзлеләр булсагыз (чакырыгыз, бер карыйк)".*** (Әнгам сүрәсе, 40)

***Әйт ки: "Сезнең фикерләгәнегез бармы: әгәр Аллаһ сезнең ишетүвегезне һәм күрүвегезне алса, һәм йөрәкләрегезне мөһерләсә, аларны сезгә Аллаһтан башка кайсы иляһ кайтара алачак?" Кара, ничек итеп Без аятьләрне төрле шәкелләрдә ачыклыйбыз да, соңыннан алар (яңадан) аркалары белән борылып, баш тарталар?*** (Әнгам сүрәсе, 46)

***Әйт ки: "Сез кайчан да булса уйландыгызмы: сезгә Аллаһның газабы һич көтмәгәнегездә яки ачык итеп килсә,***

***дөрес юлдан тайпылган, золым иткән кавемнән башка берәр кавем бәла-казага очраячакмы?”***(Әнгам сүрәсе, 47)

***Фикерләгән кеше Аллаһ яраткан барлыклардагы булган бик күп искиткеч узенчәлекләрне күрә алыр. Һәм бу рәвештә Аллаһның чиксез көчен һәм гыйлемен таный алыр.***

***Әйт ки: “Һич уйлаганыгыз бармы: әгәр дә Аның газабы сезгә төнлә яки көндез килсә, хаталы-гөнаһкарлар ничек итеп аны вакытыннан алда татырга теләрләр?”*** (Юныс сүрәсе, 50)

***Күрмиләрме ки, чынлыкта алар һәр ел бер яки ике тапкыр бәлага очрап торалар да соңыннан тәүбә итмиләр һәм үгет алып (дәрес чыгарып) төшенмиләр***. (Тәүбә сүрәсе, 126)

***Ант булсын ки, беренче нәселләрне һәлакәткә очраттырганнан соң, Мусага кешеләр өчен (күзләрен хикмәт белән ачып нурландырачак) гыйбрәт, һидәят (тугры юл) һәм мәрхәмәт йөзеннән китап бирдек. Үгет алып фикерләсеннәр дип.*** (Кассас сүрәсе, 43)

***Ант булсын, Без сезгә охшаганнарны һәлакәткә очраттык. Фәкать дәрес алып фикерләгән бармы?*** (Камәр сүрәсе, 51)

***Ант булсын, Без дә, Фиргавен гаилә(тирә-ягын)сен дәрес алып фикерләсеннәр дип, еллар буе корылыкка һәм ачлыкка очраттык.*** (Әграф сүрәсе, 130)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ КОРЪӘН ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА.

***Алар һаман Коръән турында <u>яхшылап уйланмыйлармы</u>? Әгәр ул (Коръән)Аллаһтан булмаса, алар анда бик күп каршылыклар (ихтилафлар, хаталар) табар иде***. (Ниса сүрәсе, 82)

***Алар барыбер ул сүзне (Коръәнне) тиешле рәвештә <u>төшенмәделәрме</u>, югыйсә, аларга үткәндәге аталарына килмәгән берәр нәрсәме килде?*** (Мөэминүн сүрәсе, 68)

***(Бу Коръән) - аятьләрен <u>яхшыдан яхшы төшенсеннәр</u> һәм чиста акылга ия булганнар дәрес алсыннар дип сиңа иңдергән изге Китабыбыздыр.*** (Сад сүрәсе, 29)

***Бәлки алар үгет алып фикерләр дип, Без аны (Коръәнне) синең телең белән җиңелләштердек.*** (Духан сүрәсе, 58)

***Хакыйкать шул: ул (Коръән) әлбәттә бер үгеттер. Моннан соң кем теләсә, үгет алып уйлансын.*** (Мүддәссир сүрәсе, 54-55)

***Шулай итеп, Без аны гарәпчә бер Коръән буларак иңдердек һәм анда куркылачак нәрсәләрне төрле шәкелләрдә ачыкладык, куркып сакланырлар яки алар өчен фикерләү (сәләтен) бар итәр дип.*** (Таха сүрәсе, 113)

## АЛЛАҺНЫҢ ИЛЧЕЛӘРЕ АҢЫ КАПЛАНГАН КАВЕМНӘРНЕ ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА.

***Әйт ки: "Сезгә Аллаһның хәзинәләре янымда дип әйтмим, яшеренне дә белмим һәм мин сезгә мин - фәрештә дип тә әйтмим. Мин, миңа ваһи ителгәннән башкасына иярмәм". Әйт ки: "Сукыр булган белән күрүче бер булырмы? Шулай да фикерләмиячәксезме?"*** (Әнгам сүрәсе, 50)

***Кавеме аның белән тартыша (бәхәсләшә) башлады. Әйтте ки: "Ул мине туры юлга ирештергәч, сез минем белән Аллаһ мәсьәләсендә бәхәскә керәсезме? Сезнең Аңа ширк кушувыгыздан мин куркмыйм, фәкать Аллаһның минем турында берәр нәрсә теләве – башка. Раббым гыйлем ягыннан һәрнәрсәне уратып алгандыр. Шулай да дәрес алып фикерләмиячәксезме?"*** (Әнгам сүрәсе, 80)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ ШАЙТАННЫҢ ТӘЭСИРЕНӘ КАРШЫ ЧЫГУ ӨЧЕН ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА

***Әгәр сиңа шайтаннан бер котырту (вәсвәсә) килсә, шунда ук Аллаһка сыен. Чөнки Ул ишетүче, белүче. (Аллаһтан) сакланганнарга шәйтаннан бер вәсвәсә килгәндә (башта) яхшылап уйларлар. (Аллаһны зикер итеп искә алырлар), соңыннан күреп аңларлар. (Шәйтанның) туганнары исә, аларны туры юлдан тайпылдырырлар, соңыннан (аларны буш) иректә калдырмаслар.*** (Араф сүрәсе, 200-202)

## АЛЛАҺ ДӘГЪВА  ЯСАЛГАН (ЧАКЫРЫЛГАН) КЕШЕНЕ ФИКЕРЛӘҮГӘ ЮНӘЛТЕРГӘ КИҢӘШ ИТӘ

***Син һәм туганың аятьләрем белән бергә китегез  һәм Мине зикер итүдә сүлпән булмагыз. Икегез Фиргавенгә барыгыз, чөнки ул азган. Аңа йомшак сүз сөйләгез, бәлки дәрес алыр яки эче тетрәнеп куркыр.*** (Таха сүрәсе, 42-44)

## АЛЛАҺ КЕШЕНЕ ҮЛЕМ ҺӘМ ЙОКЫ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘРГӘ ЧАКЫРА.

***Аллаһ үләчәк вакытларында җаннарын алыр, үлмәгәнне дә йокысында (бер төрле үлемгә хөкем итәр). Шулай итеп үзе турында үлем карары бирелгәнне (ң рухын) тотар, икенчесенең дә билгеле бер әҗәлгә кадәр соңга калдырыр. Шиксез, монда фикерләгән кавем өчен чыннан да аятьләр бардыр***. (Зүмәр сүрәсе, 42)

***Аллаһ...Аннан башка иляһ юктыр. Тередер, даимидер. Аны йокы басмас. Күкләрдә һәм җирдә ни булса – барысы да Аныкыдыр. Рөхсәте булмыйча Аның Катында кем шәфәгать (яклау) итәчәк? Ул, киләчәктәгеләрне һәм үткәннәрне белер. (Алар исә) теләгән кадәреннән тышында, Аның гыйлеменнән бернәрсәне дә ала алмаслар. Аның көрсие (тәхете) бөтен күкләрне һәм җирне каплагандыр. Аларның сакланышы Аңа авыр килмәс. Ул, бик Бөектер***. (Бакара сүрәсе, 255)

# НӘТИҖӘ

Китапның максаты – уйлануга этәрү. Кешегә хакыйкатьләр төрлечә аңлатылырга мөмкин; бөтен нечкәлекләр, дәлилләр, детальләр күптөрле мөмкинчелекләр аркылы аңа күрсәтелергә мөмкин. Ләкин, бу кеше бөтен бу хакыйкатьләр турында үзе, җитди һәм дөрес рәвештә, хакыйкатькә төшенү максаты белән уйланмаса, аларга төшенергә тырышмаса, бөтен бу күрелгән чараларның һичбер тәэсире дә булмас. Шул сәбәптән, Аллаһ илчеләре кавемнәрен Аллаһ юлына чакырганнарында хакыйкатьләрне, дөрес нәрсәләрне аларга бөтен ачыклык белән аңлатканнар һәм аларны уйланырга, фикер йөртергә чакырганнар.

Уйланучы кеше Аллаһ яратылышындагы серләргә, дөнья тормышының мәгънәсенә, хакыйкатенә, Җәннәт вә Җәһәннәмнең барлыгына, тирә-якта бөтен булып беткәннәргә төшенер. Аллаһ разый булачак кеше булуның әһәммиятен тагын да яхшырак аңлар, дин әхлагын кирәгенчә яшәр, күргән һәрнәрсәсендә Аллаһның сыйфатларын күрер, кешеләрнең гаять күпчелеге кебек түгел, ә Аллаһ кушканча уйлана башлар. Моның нәтиҗәсе буларак та бөтен гүзәллекләрдән, һәрнәрсәдән башкалардан тагын да күбрәк зәвык алыр һәм кирәксез, буш шөгыльләргә, дөньяга юнәлгән теләкләргә тагылып калып үзен хәсрәткә этәрмәс.

Болар фикерләгән кеше тарафыннан дөньяда казанылган гүзәллекләрдән тик берничәсе. Уйланып, фикерләп, дәвамлы дөресне, хакыйкатьләрне күрүче кешененең Ахирәттәге казанышы исә дә - Аллаһның сөюве, ризасы, рәхмәте һәм Җәннәте.

Дөньяда булган хәлләрендә уйланып, фикерләп хакыйкатьләрне күрүдән качкан, уз-узләрен алдаучы механизмнарга бирелуче кешеләрне уйландырачак, өстәвенә, “тирән һәм яхшыдан яхшы иттереп” уйландырачак һәм хакыйкатьләрне бөтен ачыклыгы белән күрсәтәчәк бер Көн, Кыямәт һичшиксез киләчәк. Ләкин ул Көндәге уйланулары инде аларга һичнинди дә файда китермәячәк, хәтта аларны ләгънәтләячәк. Аллаһ бу ише кешеләрнең кайчан уйлый башлаячакларын Көръәндә шулай белдерә:

***Инде ул, “һәрнәрсәне батырып күмүче бөек һәлакат” (кыямәт) килгәндә. Ул көнне кеше нәрсә өчен тырышлык күрсәткәнен уйлап аңлар. Күрә алганнар өчен җәһәннәм дә хәзерләнгән.*** (Назиат сүрәсе, 34-36)

Уйланмыйча җаваплылыктан кача алуларын исәпләгәннәрне, бәлки тап булачаклары соңнарын уйларлар һәм Аллаһның диненә кайтырлар дип кешеләрне уйлануга чакыру мөэминнәрнең гыйбадәте, вазыйфасы. Әмма, иман итүчеләр Көръәндә Раббыбыз белдергәнчә хәрәкәт итәрләр. Аятьтә шулай белдерелә:

***Инде кем теләсә, үгет алып уйланыр.*** (Мүддәссир сүрәсе,55)

# Эволюция ялганы

Дарвинизм , ягъни эволюция теориясе, яратылыш хакыйкатен инкяр итү максаты белән уртага атылган, ләкин уңышлы булмаган гыйлемнән тыш бер сафсатадан башка бер нәрсә дә түгел. Җанлыларның җансыз мәддәләрдән үзеннән-үзе барлыкка килгәнен яклаган бу теория, космоста һәм җанлыларда бик ачык бер система барлыгының гыйлем тарафыннан исбат ителүве белән җимерелгән. Шулай итеп, Аллаһның бөтен космосны һәм җанлыларны яраткан булувы хакыйкате гыйлем тарафыннан да расланган. Бүген эволюция теориясен аякта тотар өчен дөньякүләм масштабында алып барылган пропоганда, барытик гыйльми хакыйкатьләрнең үзгәртелүвенә, тарафлы юралуга, гыйльми буларак күрсәтелгән ялганнарга һәм эшләнгән фабрикацияләргә таяна.

Ләкин, бу пропоганда дөреслекне яшерә алмый. Эволюция теориясенең белем тарихындагы иң бөек хата булганлыгы, соңгы 20-30 ел гыйлем дөньясында бара-бара тагын да көчлерәк тавыш белән телгә китерелә башлады. Бигрәк тә 1980 нәрдән соң үткәрелгән эзләнүләр Дарвинист исбатлауларның бөтенләй ялгыш булганын уртага куйган һәм бу хакыйкать бик күп галим тарафыннан телгә китерелгән. Бигрәк тә АКШда биология, биохимия, палеонтология кебек төрле тармаклардан килгән күп сандагы галимнәр, Дарвинизмның яраксызлыгын күрәләр, җанлыларның башлангычын барытик яратылыш хакыйкате аркылы ачыклый алалар. Бүген гыйльми технологияләр космосның һәм җанлыларның Аллаһ тарафыннан яратылган икәнлеген бер хакыйкать буларак күрсәтә.

Эволюция теориясенең бетүвен һәм яратылыш дәлилләрен башка бик күп хезмәтләребездә бөтен гыйльми үзенчәлекләре белән аңлаттык һәм аңлатувыбызны дәвам итәбез. Ләкин теманы, бик әһәммиятле булганы өчен, монда да кыска гына аңлатуда файда бар.

## Дарвинны еккан читенлекләр

Эволюция теориясе, борынгы Грециягә кадәр барып тоташучы бер фәлсәфә булувына карамастан, күләмле итеп 19 нчы гасырда уртага чыкты. Теорияне гыйлем дөньясының көнкүрешенә атучы иң мөһим вакыйга, Чарльз Дарвинның 1859 нчы елда басылган “Төрләрнең килеп чыгышы” исемле китабы иде. Дарвин бу китапта дөньядагы бөтен җанлы төрләрнең Аллаһ тарафыннан аерым – аерым буларак яратылувы хакыйкатенә каршы килә иде. Дарвинга күрә, бөтен төрләр уртак бер атадан яралганнар һәм вакыт белән кечкенә үзгәрешләр күреп, аермалы хәлгә килгәннәр.

Дарвинның теориясе һичбер конкрет гыйльми ачышларга таянмый иде; үзе дә кабул иткәне кебек, барытик бер “мантык кылудан” гыйбарәт иде. Хәтта, Дарвин китабындагы “Теориянең авырлыклары” исемле озын

бүлегендә үзе белдерүвенчә, теория бик күп кенә әһәммиятле сорауларга җавап таба алмый иде.

Дарвин теориясе каршысындагы авырлыкларның алда булучы гайлем тарафыннан үтеләчәгенә, яңа гыйльми ачышларның теориясен көчләндерүвенә ышана иде. Моны китабында еш-еш белдерде. Ләкин, алга баручы гыйлем, Дарвин өметләренең киресе буларак, теориясенең асылларын бер-бер артлы таянычсыз калдырды.

Дарвинизмның гыйлем каршысындагы җиңелүве өч асыл кысымга бүленеп җентекләнә ала:

1) Теория җир йөзендәге тормышның иң башта ничек килеп чыкканлыгын һич тә ачыклый алмый.
2) Теория белдергән "эволюция механизмнарының" эволюциягә китерерлек берәр тәэсиргә ия булувын күрсәтүче һичбер гыйльми ачыш та юк.
3) Фосиллияләр калдыклары эволюция теориясе тасвирлаган тарихның бөтенләй киресен аңлата.

Бу бүлемдә бу өч асыл кысымга гомуми һәм кыска буларак кагылып китәрбез.

## Үтелә алмаган беренче киртә: тормышның килеп чыгышы

Эволюция теориясе бөтен җанлы төрләрнең моннан якынча 3,8 миллиард ел алда, беренчел дөньяда уртага чыккан тик бер җанлы күзәнәктән килгәннәрен белдерә. Ләкин, бер күзәнәкнең ничек миллионларча комплекслы җанлы төрләрен булдырганы һәм әгәр чыннан да бу төр эволюция булган булса, нигә моның эзләре фосиллияләрдә табылмаганы теория ачыклый алмый торган сораулардан. Әмма, бөтен болардан алданрак теория яклаган беренче этапта тукталып китәргә кирәк. Сүз ителгән шул "беренче күзәнәк" ничек барлыкка килгән?

Эволюция теориясе яратылышны инкяр итүве һәм һичбер табигатьтән өстен булган көчне кабул итмәгәнлегеннән, ул "беренче күзәнәкнең" һичбер проект, план һәм системалаштыру булмастан, табигать кануннары аркылы очраклы рәвештә барлыкка килгәнен белдерер. Ягъни, теориягә күрә, җансыз маддә очраклы сәбәпләр нәтиҗәсендә җанлы күзәнәк булдырган. Ләкин , бу беленгән иң асыл биологик кануннарга да каршы килә.

## “Тереклек тередән килә”

Дарвин китабында тереклекнең килеп чыгышыннан һич сүз итмәгән. Чөнки аның дәверендәге элеккеге гыйлем җансызларның бик гади төзелешкә ия булганнарын исәпли иде. Урта гасырлардан бирле инанылган “spontane jenerasyon” исемле теориягә карата, җансыз маддәләрнең очраклы рәвештә бер арага килеп, җанлы барлык булдыра алачагына ишаныла иде. Бу дәвердә бөҗәкләрнең ризык калдыкларыннан, күсәләрнең дә бодайдан барлыкка килүләре таралган бер фикер иде. Моны исбатлау өчен дә кызык эксперементлар үткәрелә иде. Пычрак берәр чүпрәк өстенә бераз бодай сибелә һәм бераз көтелгәннән соң бу кушылудан күселәрнең барлыкка киләчәге көтелә иде.

Итләрнең кортлануvы да тереклекнең җансыз маддәләрдән ярала алувына бер дәлил итеп санала иде. Югыйсә, соңыннан аңлашылачак иде ки, ит өстендәге кортлар үз-үзеннән барлыкка килмиләр, ә чебеннәр калдырган күзгә күренмәгән лечинкалардан чыгалар.

Дарвин “Төрләрнең килеп чыгышы” исемле китабын язган дәвердә исә, бактерияләрнең җансыз маддәләрдән килеп чыга алувына инану гыйлем дөньясында таралган һәм кабул ителгән иде.

Югыйсә, Дарвин китабының таралувыннан биш ел үткәннән соң, мәшһүр биолог француз Луи Пастер эволюциянең фундаментын тәшкил иткән бу инануны бөтенләй буларак черетте. Пастер күрсәткән олы тырышлыгын һәм ул үткәргән эксперементлар аркылы киленгән нәтиҗәне кыска гына шулай аңлаткан иде:

***“Җансыз маддәләрдән тормыш килеп чыга алувын белдерүче караш инде бөтенләй тарихка күмелгән.”*** (Sidney Fox, Klaus Dose, ”Molecular Evolution and The Origin of Life”, New York: Marcel Dekker, 1977, 2 нче бит).

Эволюция теориясен яклаучылар Пастер тарафыннан ачылганнарга карата озын вакыт каршы тордылар. Ләкин, алга баручы гыйлем җанлы күзәнәкнең авыр төзелешен уртага чыгаргач, тормышның үзеннән-үзе килеп чыга алувы карашының яраксызлыгы тагын да ачык хәлдә күренде.

## 20 нче гасырдагы нәтиҗәсез эзләнүләр

20 нче гасырда тормышның ничек килеп чыгышын беренче буларак мәшһүр эволюционист, рус биологы Александр Опарин җентекләде. Опарин, 1930 нчы елларда уртага аткан берничә тезислары аркылы, җанлы күзәнәкнең очраклы рәвештә килеп чыга алувын исбат итәргә тырышты. Ләкин, бу эзләнүләр уңышсызлык белән соңланачак һәм Опарин шуны белдерергә мәҗбүр калачак:

***“Кызганычка каршы, күзәнәкнең килеп чыгышы – эволюция теориясен бөтенләй үз эченә алучы иң караңгы ноктадан гыйбәрәт.”*** (Alexander I. Oparin, “Origi of Life”, (1936) New York, Dover Publications, 1953(Reprint), 196 нчы бит).

Опарин эзләреннән баручы эволюционистлар, тереклекнең килеп чыгышын чишелешкә китерәчәк эксперементлар эшләргә тырыштылар. Бу эксперементларның иң мәшһүре Америкалы химик Стэнли Миллер тарафыннан 1953 нче елда үткәрелде.

Миллер беренчел дөнья атмосферасында булганлыгын белдергән газларны бер эксперементаль җиһазында берләштереп һәм бу кушылмага энергия өстәп, протеиннарның төзелешендә кулланылган берничә органик молекуланы (аминооксидны) синтезлады. Ул елларда эволюция өчен әһәммиятле бер ачыш кебек танытылган бу эксперементның яраксыз булувы һәм эксперементта кулланылган атмосфераның шул вакыттагы чын дөнья шартларыннан бик тә аермалы булганлыгы киләчәк елларда уртага чыгачак иде. (“New Evidence on Evolution of Early Atmosphere and Life”, Bulletin of the American teorological Society, 63 нче том, ноябрь 1982, 1328-1330 нчы битләр).

Озын итеп дәвам иткән бер тавышсызлыктан соң, Миллер үзе дә кулланылган атмосфераның чын булмаганын белдерде. (Stanley Miller, “Molecular Evolution of Life: Current Status of the Prebiotic Synthesis of Small Molecules, 1986”, 7 нче бит).

Тереклекнең килеп чыгышын ачыклау өчен 20 нче гасыр буенча күрсәтелгән бөтен эволюцион тырышлыклар гел уңышсызлык белән нәтиҗәләнде. Сан Диегоның Скрайс институтының мәшһүр геохимигы Джефрей Бэйда, эволюцион “Earth” журналында, 1998 нче елда чыккан бер мәкаләсендә бу хакыйкатьне шулай кабул итә:

***“Бүген , 20 нче йөзьелны артта калдырганыбыз вакыт, һаман 20 нче йөзьелга кергәнебездә ия булганыбыз иң бөек чишелә алмаган проблема белән кара-каршыбыз: тормыш җир йөзендә ничек башланды?”*** (Jeffrey Bada, Earth, февраль 1998, 40 нчы бит).

## Тормышның комплекслы төзелеше

Эволюция теориясенең тереклекнең килеп чыгышында бу хәтле бөек бер чарасызлыкка таб булувының төп сәбәбе, хәтта иң гади саналучы җанлы организмнарның да инанылмас дәрәҗәдәге комплекс төзелешләргә ия булулары. Җанлы күзәнәк – төзелеше белән адәм баласы җитештергән бөтен технологик җиһазлардан тагын да авыррак. Шулай ки, буген дөньяның иң алга киткән лабороторияләрендә дә хәтта, җансыз мәддәләр бер арага китерелеп , җанлы берәр күзәнәк эшләнә алмый.

Бер күзәнәкнең барлыкка килүве өчен кирәк булган шартлар, һич тә очраклы рәвештә булганлыгы ачыклана алмаячак кадәр күп. Күзәнәкләрнең иң асыл төзелеш ташлары саналган протеиннарның очраклы рәвештә синтезлану ихтималы: 500 аминооксидлы уртача бер протеин өчен **$10^{-950}$**дә 1 дер. Ләкин, математикада $10^{-50}$ дә 1 дән әзрәк булучы ихтималлар практик буларак “була алмас” дип санала. Күзәнәкнең төшендә урын алган һәм генетик информацияне саклаган ДНК молекуласы исә, инаныла алмаслык

бер информация банкы. Әгәр кеше ДНК да булган информацияне кәгазьгә күчерергә алынса, 500 шәр биттән торган 900 томлык бер китапханә булачагы хисаплана.

Монда бик кызыклы тагын бер дилемма бар:

ДНК барытик берничә махсус протеиннарның (энзимнарның) ярдәме белән генә парлана ала. Әмма, бу энзимнарның синтезы да барлык ДНК дагы информация аркылы гына тормышка аша. Бер-берләренә бәйле булганнарынан, парлану барлыкка килә алувы өчен дә берүк вакытта бар булулары кирәк. Бу исә, тормышның үзеннән-үзе килеп чыгу сценариясен тупикка китерә. Сан Диегодагы Калифорния университетыннан мәшһүр эволюционист, профессор Лесли Оргел "Scientific American" журналының 1994 нче елгы октябрь санында бу хакыйкатьне шулай белдерә:

***" Соңгы дәрәҗә комплекс төзелешләргә ия булган протеиннарның һәм нуклеин оксидларының (РНК һәм ДНК) берүк урында һәм берүк вакытта очраклы рәвештә барлыкка килүләре – ашкан дәрәҗәдә ихтималдан тыш нәрсә. Әмма, боларның берсе булмыйча икенчесенең барлыкка килүве мөмкин түгел. Шулай итеп, кеше яшәешенең химик юллар белән урта чыгувының һич тә мөмкин булмавы нәтиҗәсенә килү мәҗбүриятендә калабыз."*** **(**Leslic E. Orgel, "The Origin of Life on Earth", Scientific American, 271 нче сан, октябрь 1994, 98 нче бит**).**

Шиксез, әгәр тормышның табигый факторлар аркылы уртага чыгувы мөмкин түгел исә, ул хәлдә тормышның табигатьтән өстен рәвештә, "яратылганын" кабул итәргә кирәк. Бу хакыйкать, иң асыл максаты Яратучыны инкяр итү булган эволюция теориясен, ачык иттереп яраксыз калдыра.

# ЭВОЛЮЦИЯНЕҢ ФАНТАСТИК МЕХАНИЗМНАРЫ

Дарвинның теориясен яраксыз кылучы икенче олы нокта, теория тарафыннан "Эволюция механизмнары" буларак белдерелгән ике төшенчәнең дә, чынлыкта, һичбер эволюциягә китерүче көчкә ия булмауларының аңлашылган булувы. Дарвин уртага аткан эволюция өйрәтмәсен бөтенлеге белән "табигый селекция" механизмына бәйләгән иде. Бу механизмга бирелгән әһәммият китабының исеменнән дә ачык буларак аңлашыла иде: "Төрләрнең килеп чыгышы, табигый селекция юлы аркылы..."

Табигый селекция табигый сайлауны аңлата. Табигатьтәге яшәү өчен барган көрәш эчендә табигать шартларына яраклы һәм көчле җанлыларның тормышта калулары фикеренә таяныр. Үрнәге, ерткыч хайваннар тарафыннан куркыныч янаган болан көтүвендә тизрәк чаба алган боланнар исән калачаклар. Шулай итеп, болан көтүве тиз һәм көчле индивидлардан формалашачак. Әмма, әлбәттә бу механизм боланнарны эволюцион үзгәрешләргә китермәс, аларны башка берәр җанлы төренә, үрнәге - атларга әйләндермәс.

Шул сәбәпле , табигый селекция механизмы һичбер эволюциягә китерерлек көчкә ия түгел. Дарвин да бу хакыйкатьне белә иде һәм “Төрләрнең килеп чыгышы” исемле китабында “файдалы үзгәрешләр барлыкка килмәве дәвамлылыгында, **табигый синтез һичбер нәрсә эшләмәс”** дип әйтәргә мәҗбүр калган иде (Charles Darwin,“The Origin of Species : A Facsimile of the First Edition”, Harvard University Press, 1964, 189 нчы бит).

## Ламаркның тәэсире

Ярар, бу “файдалы үзгәрешләр” ничек барлыкка килә ала иде? Дарвин, дәверенең беренчел гыйлем аңлаешы эчендә, бу сорауга Ломарка таянып җавапларга тырышты. Дарвиннан алданрак яшәгән француз биологы Ламаркка күрә, җанлылар яшәешләре буенча кичергән физик үзгәрешләрне киләчәк нәселләргә ирештерәләр, нәселдән нәселгә җыелган бу үзенчәлекләр нәтиҗәсендә яңа төрләр барлыкка килә иде. Үрнәге, Ламаркка күрә, жирафлар боланнардан килеп чykканнар иде, югары агачлардагы яфракларны ашар өчен сузыла-сузыла, нәселдән-нәселгә муеннары озынайган иде.

Дарвин да охшаш үрнәкләр биргән. Үрнәге, “Төрләрнең килеп чыгышы” исемле китабында, ашамлык табыр өчен суга кергән кайбер аюларның, заман үтү белән китларга әверелгәнен белдергән иде!? (Charles Darwin, “The Origin of Species : A. Facsimile of the First Edition”, Harvard University Press, 1964, 184 нче бит).

Әмма, Мендель ачкан һәм 20 нче йөзьелда алга киткән генетика фәне белән расланган калучанлык кануннары, казанылган үзенчәлекләрнең киләчәк нәселләргә калу легендасын юк итте. Шулай итеп, табигый селекция “ялгыз башын” һәм бөтенләй тәэсирсез механизм буларак калды.

### Неодарвинизм һәм мутацияләр

Дарвинистлар бу мәсьәләгә берәр чишелеш табыр өчен 1930 нчы елларның соңнарында “Модерн синтетик теорияне” яки тагын да таралган исеме белән беленгән “неодарвинизмны” уртага аттылар. Неодарвинизм табигый селекциягә “файдалы үзгәрешләр сәбәбе” буларак мутацияләрне, ягъни җанлыларның геннарында радиация кебек тышкы тәэсирләр яки копияләү хаталары нәтиҗәсендә барлыкка килгән бозылуларны өстәде.

Бүген әле һаман дөньяда дарвинизм ягыннан яраклы саналган модель – неодарвинизм. Теория җир йөзендәге миллионнарча җанлыларның, аларның колак, күз, үпкә, канат кебек сансыз комплекслы органнарының “мутацияләр”, ягъни генетик бозылуларга таянучы бер процесс нәтиҗәсендә барлыкка килгәнлеген белдерә. Әмма , теорияне чарасыз калдырган ачык бер гыйльми хакыйкать бар: мутацияләр җанлыларга файдалы үзгәрешләр китермәс, киресенчә, һәрзаман җанлыларга зарар китерер.

Моның сәбәбе бик гади: ДНК бик комплексلы системага ия. Бу молекулада очраклы рәвештә барлыкка килгән һәрнинди берәр тәэсир барытик зарар гына бирер. Америка генетигы Б.Г. Рэнгэнэзан моны шулай ачыклый:

***“Мутацияләр кечкенә, очраклы һәм зарарлы. Бик сирәк буларак барлыкка килерләр һәм иң күп очракта тәэсирсезләр. Бу өч сыйфат мутацияләрнең эволюцион берәр үзгәреш китерә алмауларын күрсәтер. Һәм бик махсус берәр организмда барлыкка килә алырлык берәр очраклы үзгәреш, йә тәэсирсез булачак, йә зарарлы. Берәр кул сәгатендә барлыкка киләчәк үзгәреш кул сәгатенә файдалы үзгәреш китермәячәк. Бөек ихтимал, аңа зарар бирәчәк яки иң күп очракта файдасыз булачак. Берәр җир тетрәве шәһәргә файда китермәс, аны һәлакәткә китерер.” ( B. G. Rangathan, “Origins”, Pensylvania : The Banner Of Tharh Trust, 1988).***

Шулай итеп, бүгенгә кадәр һичбер яраклы, ягъни генетик яктан файда китерүче мутация үрнәге күрелмәде. Бөтен мутацияләрнең зарары булганы күренде. Аңлашылды ки, эволюция теориясе тарафыннан “эволюция механизмнары” буларак күрсәтелгән мутацияләр, чынлыкта җанлыларга барытик зарар китерә, аларны инвалид итә (кешеләрдә мутациянең иң еш күрелгән тәэсире-рак). Әлбәттә, зарар китерүче механизм “эволюция механизмы” була алмый. Табигый селекция исә, Дарвин үзе дә кабул иткәне кебек, “үзе генә һичбер нәрсә эшләмәс”. Бу хакыйкать безгә табигатьтә һичбер “эволюция механизмының” булмавын күрсәтә. Эволюция механизмы булмаганга күрә, эволюция диелгән фантастик процесс та яшәлмәгән.

## Фосиллияләр калдыклары: ара формалардан әсәр юк

Эволюция теориясен яклаган сценариянең яшәлмәгән булганын иң ачык рәвештә фосиллияләрнең калдыклары күрсәтер.

Эволюция теориясенә күрә, бөтен җанлылар бер-берсеннән килеп чыккан. Башта бар булмаган “бер” җанлы төре, вакыт үтү белән башкага әверелгән һәм бөтен төрләр шулай итеп барлыкка килгән. Теориягә карата, бу әверелү йөз миллионнарча ел дәвам иткән һәм адым-адым тормышка аша биргән.

Бу хәлдә, белдерелгән озын әверелү процессы вакытында сансыз “ара төрләрнең” барлыкка килгән һәм яшәгән булулары кирәк.

Үрнәге, элек балык үзенчәлекләренә ия булуларына карамастан, бер яннан кайбер сөренүчеләрнең дә үзенчәлекләрен казанган ярым балык – ярым сөренүче җанлыларның яшәгән булулары кирәк. Яки сөренүче үзенчәлекләренә ия булган вакытында, бер яннан кайбер кош үзенчәлекләрен казанган сөренүче-кошлар барлыкка килгән булулары тиеш. Болар, бер үзгәрү процессы күргәннәре өчен, инвалид,

җитешсезлекле, кимчелекле җанлылар булырга тиеш. Эволюционистлар үткәннәрдә яшәгән дип инанылган бу теорик җанлыларга “ара формалар” исеме бирер.

Әгәр чыннан да бу төр җанлылар үткәндә яшәгән булсалар, аларның саннары һәм төрләре миллионнарча, хәтта миллиардларча булырга тиеш. Һәм бу үзенчәлекле җанлыларның калдыклары, һичшиксез фосиллияләр калдыклары арасында табылырга тиеш. Дарвин “Төрләрнең килеп чыгышы” китабында моны шулай ачыклый:

***“Әгәр теориям дөрес исә, төрләрне бер-берсенә бәйләүче сансыз ара формалар төрләре һичшиксез яшәгән булырга тиеш... Боларның яшәгән икәнлекләренең дәлилләре дә барытик фосиллияләр калдыклар арасында табыла ала.” (Charles Darwin, “The Origin of Species : A Facsimile of the First Edition”, Harvard University Press, 1964, 179 нчы бит).***

## Дарвинның тормышка ашмаган өметләре

Ләкин, 19 нчы йөзләрнең уртасыннан алып бүгенгегә хәтле дөньяның дүрт ягында лихорадкалы рәвештә фосиллияләр эзләнүләре ясалувына карамастан, бу ара формалар һич тә табылмаган. Үткәрелгән казылмалар һәм эзләнүләр аркылы ия булынган бөтен ачышлар, эволюционистлар көткәненең киресе буларак, җанлыларның җир йөзендә берьюлы, көтелмәгәндә, кимчелексез һәм җитешсезлексез бер рәвештә килеп чыкканнарын күрсәтте.

Мәшһүр инглиз палеонтологы (фосиллияләр буенча махсус галим) Дэрэк В. Эйджер, бер эволюционист булувына карамастан, бу хакыйкатьне шулай белдерә: ***“Проблемабыз шул: фосиллияләр калдыкларын ничкәлекләре белән җентекләгәнебездә , төрләр яки сыйныфлар дәрәҗәсендә булсын, гел бертөрле хакыйкатьләр белән каршылашабыз; адым-адым үзгәрешләргә китерүче эволюция аркылы түгел, берьюлы җир йөзендә барлыкка килгән группалар күрәбез.”*** (Derek A/ Ager, “The Nature of the Fossil Record”, Proceedinns of the British Geological Association, 87 нче том , 1976, 133 нче бит).

Ягъни фосиллияләр калдыклары буенча, бөтен җанлыларның төрләре, араларында һичбер ара формалар булмастан, кимчелексез рәвештә берьюлы уртага чыкканнар. Бу Дарвин исәпләгәннәрнең бөтенләй киресе. Өстәвенә , бу җанлы төрләрнең яратылганнарын күрсәтүче бик көчле бер дәлил. Чөнки берәр җанлы төренең үзеннән эволюцион үзгәреш күреләчәк һичбер атасы булмыйча, бер мизгелдә һәм кимчелексез буларак уртага чыгувының бердәнбер аңлатылмасы – ул төрнең яратылган булувы. Бу хакыйкать мәшһүр эволюционист , биолог Дулас Фютюйма тарафыннан да кабул ителә:

***“Җанлыларның килеп чыгышын барытик яратылыш яки эволюция аркылы гына ачыкларга мөмкин. Җанлылар дөньяда, йә бөтенләй камиль һәм кимчелексез рәвештә уртага чыкканнар, йә болай булмаган.***

***Әгәр болай булмаган булса, бер үзгәреш процессы аркылы үзләреннән алданрак бар булган кайбер җанлы төрләреннән эволюция күреп барлыкка килгән булулары кирәк. Әмма, әгәр кимчелексез һәм камиль бер рәвештә уртага чыкканнар исә, ул хәлдә, чиксез көч иясе бер акыл тарафыннан яратылган булулары кирәк.”*** (Douglas J. Futuyma, “Science on Trial”, New York Pantheon Books, 1983, 197 нче бит).

Фосиллияләр җанлыларның җир йөзендә кимчелексез һәм камиль рәвештә уртага чыкканнарын күрсәтә. **Ягъни “төрләрнең килеп чыгышы”, Дарвин исәпләгәненең киресе буларак, эволюция түгел , яратылыш.**

## Кеше эволюциясе турында әкият

Эволюция теориясен яклаучылар тарафыннан иң күп көндәлеккә китерелгән тема – кешенең килеп чыгышы темасы. Бу теманың дарвинистик эчтәлеге, бүген яшәгән модерн кешенең маймылсыман берничә җанлылардан килеп чыкканын исәпләү. 4-5 миллион ел элек башланган дип саналган бу процесста, модерн кеше белән аталары арасында кайбер “ара формаларның” яшәгәнлеге белдерелә. Чынлыкта, бөтенлеге белән хыялый булган сценариядә дүрт фундаменталь “категория” саналып кителә:

1- Australopithecus (австралопитек)
2- Homo habilis (эшчәнлек күрсәтә алучы кеше)
3- Homo erectus (туры йөрүче кеше)
4- Homo sapiens (акыллы кеше)

Эволюционистлар, тик сүздә генә булган кешенең беренче маймыл сыман атасына, “көнчыгыш маймылы” дигәнне аңлаткан “Australopithecus” исемен бирерләр. Бу җанлылар, чынлыкта, нәселе тәмамлынган бер маймыл төреннән башка берни түгел.

Лорд Салли Зукерман һәм профессор Чарльз Окснард кебек Англиянең һәм АКШның дөньякүләм мәшһүр ике анатомистының, Astralopithecus үрнәкләре өстендә үткәрелгән бик киң аланлы эзләнүләр нәтиҗәсендә, бу җанлыларның барытик нәселе тәмамланган бер маймыл төре икәнлеген һәм кешеләргә һичбер охшашлыклары булмаганлыгы күренде. (Solly Zuckerman, “Beyond The Ivori Tower”, New York: Toplinger Publications, 1970, 75-94 нче битләр; Charles E. Oxhard, “The Place of Australopithecines in Human Evolution Grounds for Doubt”, “Nature”, 258 сан, 389 нчы бит).

Эволюционистлар кеше эволюциясенең соңгы стадиясен “homo”, ягъни кеше буларак сыйныфландырыр. Белдергәннәренә күрә, “homo” стадиясендәге җанлылар “Australopithecus”lardан тагын да алга киткән үзгәреш күргәннәр. Эволюционистлар бу төрле-төрле җанлыларга кагылышлы фосиллияләрне бер-бер артлы төзеп, хыялый эволюция схемасы төзерләр. Бу фантастик схема, чөнки чынлыкта бу төрле сыйныфлар арасындагы эволюцион бәйлелек булувы һич тә исбатланмаган. Эволюция теориясенең 20 нче гасырдагы иң күренекле яклаучыларыннан

берсе булган Эрнст Майр, “**homo sapienska илтүче чылбыр чынлыкта югалган**” диеп, моны кабул итәр. (J. Renic, “Darwin´s Current Bulldog: Ernst Майр”,”Scientific American”, декабрь 1992).

Эволюционистлар “Australopithecus - Homo habilis - Homo erectus - Homo sapiens” чиратын язган вакытта, бу төрләрнең һәрберсе анардан соң килүченең атасы булганын белдерә. Югыйсә, палеантологларның соңгы ачышлары “Australopithecus”, “Homo habilis” һәм “Homo erectusның” дөньяның төрле урыннарында бер үк вакытта яшәгәнлекләрен күрсәтте. (Alan Walker,”Sciense”, 207 нче сан, 1980, 1103 нче бит; A. J. Kelso, “Physical Antropology”, 1 нче басма, New York: J. B. Lipincott Co., 1970, 221 нче бит; M. D. Leakey, “Olduvai Gorge”, 3 нче том, Canbridge: Cambridge University Press, 1971, 272 бит).

Тагын “Homo erectus” дип сыйныфланган кешеләрнең бер өлеше бик модерн заманнарга кадәр яшәгәннәр, “Homo sapiens neandertalensis” (неандерталь кешеләр) белән берүк урында бергә яшәгәннәр. (“Time”, ноябрь, 1996).

Әлбәттә, бу әлеге сыйныфларның бер-берсенең аталары булганын яклауның яраксыз икәнлеген ачык рәвештә уртага сала. Гарвард университеты палеонтологларыннан Стефан Джей Гоулд , үзе дә бер эволюционист булувына карамастан, дарвинист теория кергән бу тупикны шулай ачыклый:

***“Әгәр бер-берсе белән паралель рәвештә яшәгән өч төрле гоминидның (кешесыманнарның) эзе бар исә, ул вакыт безнең нәсел агачыбызга ни булган? Ачык ки, боларның берсе башкасыннан килә алмый. Тагын, берсе башкасы белән чагыштырылганында эволюцион үзгәреш юнен күрсәтми.”( S. J. Gould, “Natural History”, 85 нче сан, 1976, 30 нчы бит).***

Кыскасы, медиада яки дәреслекләрдә урын алган фантастик берничә “ярым маймыл - ярым кеше” буларак рәсемләнгән җанлылар, ягъни барытик пропоганда юлы белән генә аякта торувы тырышылган кешенең эволюция сценариясе , һичбер гыйльми фундаменты булмаган бер әкияттән генә гыйбарәт.

Бу теманы озын елллар буе җентекләгән, “Australopithecus” фосилияләр өстендә 15 ел буенча махсус эзләнүләр үткәргән Англиянең иң мәшһүр һәм ихтирам ителгән галимнәреннән булучы Лорд Салли Зукерман, бер эволюционист булувына карамастан, уртада маймылсыман җанлылардан кешегә барып тоташучы чын нәсел агачы булмаган нәтиҗәгә килгән.

Зукерман үз чиратында кызыклы бер “гыйльми шкала” да ясаган. Аның тарафыннан гыйльми буларак танылган белем тармакларыннан алып, гыйлемнән тыш буларак кабул ителгән белем тармакларына кадәр бер шкала барлыкка китергән. Зукерманның бу таблицасына күрә, иң “гыйльми” – ягъни конкрет күрсәткечләргә таянучы – белем тармаклары химия һәм физика. Шкалада болардан соң биология белемнәре һәм аннан соң социал белемнәр килә. Шкаланың иң очында, ягъни иң “гыйлемнән тыш” саналган

кысымда исә, Зукерманга күрә, телепатия, алтынчы хис кебек “хис тышындагы сиземләү” төшенчәләре һәм “кеше эволюциясе” бар. Зукерман бу шкаланың очын шулай ачыклый:

***“Объектив хакыйкатьләрнең аланыннан чыгып, биологик белем дип саналган бу аланнарга - ягъни хис тышындагы сиземләүгә һәм кеше ясаган фосиллияләр тарихының юрымлавына – кергәнебез вакыт, эволюция теориясенә инанучы берәү өчен һәрнәрсәнең мөмкин икәнлеген күрербез. Шулай ки, теорияләренә бөтенләй ышанучы бу кешеләрнең, бәхәсле кайбер фикер йөртүләрне берүк вакытта кабул итүләре дә хәттә мөмкин.”*** (Solly Zuckerman, “Beyong The Ivory Tower”, New York Toplinger Publications, 1970, 19 нчы бит).

Менә кеше эволюциясе әкияте дә, теорияләренә сукырларча ышанучы кайбер кешеләр тарафыннан табылган фосиллияләрне үзләренә кирәк булган бер рәвештә юрауларыннан гына гыйбарәт.

# ДАРВИН ФОРМУЛАСЫ

Хәзергегә чаклы кыска гына карап үткәнебез бөтен гыйльми дәлилләр белән бергә, теләсәгез, эволюционистларның нинди уйдырма бер инануга ия булганлыкларын, хәтта балалар да аңлый алачак кадәр ачык булган үрнәкләр белән нитиҗә ясыйк.

Эволюция теориясе җанлыларның очраклы рәвештә барлыкка килгәнен яклый. Шулай итеп, бу теорияга карата, җансыз һәм зиһенсез атомнар бер арага килеп башка күзәнәкне бар иткәннәр һәм соңыннан шулук атомнар бер рәвешле башка җанлыларны һәм кешене дә барлыкка китергәннәр. Хәзер уйланыйк, җанлыларның “төзелеш ташлары” ролень уйнаган карбон, фосфор, азот, калий кебек элементларны бергә туплаганыбызда бер масса барлыкка килә. Бу атомнар массасы, нинди процесстан үтсә үтсен, берәр җанлы барлыкка китерә алмый. Теләсәгез моның өчен берәр “эксперимент” үткәрийк һәм асылында эволюционистлар тарафыннан якланылган, әмма югары тавыш белән телгә китерелмәгән “Дарвин формуласы” аркылы җентеклийк: эволюционистлар күп сандагы бөек пробиркаларның эчләрен җанлылар төзелешендә булган фосфор, азот, карбон, һава, тимер, магний кебек элементлар белән мул итеп тутырсыннар. Хәтта нормаль шартларда булмаган, ләкин бу кушылма эчендә булувы кирәк дип күрелгән бөтен маддәләрне дә бу пробиркаларга кушсыннар. Кушылмалар эченә теләнелгән кадәр аминооксидлар, теләнелгән кадәр дә (хәтта моның берүзенең генә дә очраклы рәвештә барлыкка килү ихтималы $10^{-950}$ булган) протейн тутырсыннар. Бу кушылмаларга теләнелгән пропорциядә җылылык һәм дымлылык бирсеннәр. Боларны теләнелгән модерн җиһазлар белән карыштырсыннар. Пробиркалар янында дөньяның алдынгы галимнәре җыелсын. Бу галимнәр атадан балага, нәселдән нәселгә күчә-күчә, кизү тора-тора, миллиардларча, хәтта триллиардларча ел дәвамында пробиркалар янында көтсеннәр. Бер җанлының барлыкка килүве

өчен ниндидер шартларның бар булувы кирәклегенә инаныла икән, һәммәсен дә куллану ирекле булсын. Ләкин, ни эшләнсә эшләнсен, ул пробиркалардан һич бер җанлы чыгара алмаслар. Жирафларны, канарейкаларны, былбылларны, попугайларны, атларны, дельфиннарны, гөлләрне, архидеяларны, лилияләрне, канәферлерне, бананнарны, апельсиннарны, алмаларны, хөрмәләрне, помидорларны, кавыннарны, карбызларны, инҗирләрне, зәйтүннәрне, йөземнәрне, шәфталиләрне, тавис кошларын, фазаннарны, төсле-төсле күбәләкләрне һәм болар кебек миллионнарча җанлы төрләрнең һичберсен дә барлыкка китерә алмаслар. Монда беркадәр санап үтелгән бу җанлы барлыкларга түгел, боларның тик бер күзәнәге генә дә ия була алмаслар!

Кыскасы, зиһенсез атомнар бер арага килеп күзәнәкне булдыра алмас. Соңыннан яңа берәр карар биреп, бер күзәнәкне икегә бүлгән, соңыннан берәр-берәр башка карарлар алып, электрон микроскопны уйлап тапкан, соңыннан үзенең күзәнәге төзелешен бу микроскоп аша караган профессорларны барлыкка китерә алмаслар. Маддә барытик Аллаһның өстен яратувы белән генә барлыкка килер. Моның киресен яклаучы эволюция теориясе исә, акылга бөтенләй каршы килүче бер сафсата. Эволюиoнистлар тарафыннан уртага атылганнар өстендә бераз гына булса да уйлану, югарыдагы үрнәктә булганы кебек, бу хакыйкатьне бик ачык рәвештә күрсәтер.

## Куз һәм колак технологиясе

Эволюция теориясе тарафынан һич тә ачыклана алмаган башка бер тема исә, күз һәм колакның өстен сиземләү сыйфатлары. Күз белән бәйле темага күчәр алдыннан, кыска гына ничек иттереп күрувебезне аңлатып үтик. Берәр җисемнән килүче нурлар күздәге ретинага киресенчә төшәр. Бу нурлар мондагы күзәнәкләр тарафыннан электрик сигналларга әйләндерелер һәм минең арткы өлешендәге “күрү мәркәзе” диелгән кечкенә генә бер ноктага ирештерелер. Бу электрик сигналлар берничә процесстан соң, мидәге бу мәркәздә күрү буларак тоемланыр. Хәзер болардан соң уйланыйк:

Ми яктылыкка ябык. Ягъни минең эче кап-караңгы, яктылык ми булган җиргә хәтле керми. Күрү мәркәзе диелгән урын кап-караңгы, яктылыкның һич ирешмәгән, бәлки дә һич күрелмәгән кадәр караңгы бер урын. Әмма, сез бу кап-караңгылыкта якты, нурлы дөньяны тамаша кыласыз.

Өстәвенә, бу шул кадәр ачык һәм сыйфатлы бер күренеш ки, хәтта XXI нче йөз технологиясе дә, һәртөрле мөмкинчелекләренә карамастан, бу ачыклылыкка ирешә алмаган. Үрнәге, хәзер укыганыгыз китапка, китапны тотучы кулларыгызга карагыз, соңыннан башыгызны күтәреп тирә-яныгызга карагыз. Хәзер күрелгән ачыклылыктагы һәм сыйфаттагы бу күренешне башка берәр җирдә күрдегез ме? Бу кадәр ачык күренешне сезгә дөньядагы телевизорлар җитештерү буенча беренче булган ширкәт тарафыннан

чыгарылган иң әйбәт экран да бирә алмаячак. 100 ел буенча меңнәрчә инженер бу ачыклыкка ирешергә тырыша. Моның өчен фабрикалар, дәү корылмалар төзелә, эзләнүләр үткәрелә, планнар һәм проектлар әзерләнә. Тагын бер телевизор экранына карагыз һәм тагын хәзер кулыгызда тотканыгыз бу китапка. Арада бөек ачыклык һәм сыйфат аермасы булувын күрәчәксез. Өстәвенә, телевизор экраны сезгә ике үлчәмле күренеш күрсәтер, ә сез өч үлчәмле, тирәнлекле бер манзара күрәсез.
Озак еллар буенча ун меңнәрчә инженер өч үлчәмле телевизор ясарга, күзнең күрү сыйфатына ирешергә тырышты. Әйе, өч үлчәмле телевизор системасы ясый алдылар, әмма аны да күзлек кимичә өч үлчәмле итеп күркү мөмкин түгел, бу ясалма өч үлчәмлелек. Арткы тараф тагын да болганчык, алгы тараф исә кәгазьдән декорация кебек тора. Һичбер заман күзнең күргәне кебек ачык һәм сыйфатлы күренеш формалашмый. Камерада да, телевизорда да мәҗбүри рәвештә күренеш югалтувы барлыкка килә.

Менә эволюционистлар, бу сыйфаттагы һәм ачыклыктагы күренешне булдырган механизмның очраклы рәвештә формалашканын яклыйлар. Хәзер кемдер сезгә бүлмәгездә торучы телевизор очраклы сәбәпләр нитиҗәсендә барлыкка килде, атомнар бер арага килде һәм бу күрсәтүче җиһазны барлыкка китерә дисә ни уйларсыз? Меңнәрчә кеше бер арага килеп ясый алмаганны, зиһенсез атомнар ничек ясасын ?

Күз күргәненнән тагын да гадирәк булучы бер күренешне булдырган җиһазның очраклы барлыкка килә алмавы көн кебек ачык. Шундый ук хәл колак өчен дә яраклы. Тышкы колак тирәдәге тавышларны колак раковинасы ярдәмендә туплап урта колакка ирештерер, урта колак алынган тавыш вибрацияләрен көчләндереп эчке колакка илтеп җиткерер, эчке колак бу вибрацияләрне электрик сигналларга әйләндереп мигә җибәрер. Күрүдә булганы кебек, ишетү процессы да мидәге “ишетү мәркәзендә” тормышка ашар.

Күздәге  хәл колак өчен дә яраклы, ягъни ми яктылык белән бергә тавыш өчен дә ябык, тавыш үткәрми. Шуңа күрә, тышта ни кадәр тавыш булса да, ми эче бөтенләй тавышсыз. Моңа карамастан, иң ачык тавышлар ми тарафыннан тоемланыр. Тавыш үткәрмәгән миегездә бер оркестрның симфонияләрен тыңларсыз, бер күп халык җыелган урынның бөтен гаугасын ишетерсез. Әмма, шул вакытта махсус бер җиһаз белән миегез эчендәге тавыш дәрәҗәсе үлчәнсә, миегездә бөтенләй тынлык булганы күреләчәк.

Ачык бер күренешкә ия булу ниятеннән технология ничек кулланылса, тавыш өчен дә шулук тырышлыклар уннарча елдан бирле дәвам итә. Тавыш язу җиһазлары, музыкаль центлар, күп кенә электроник җиһазлар, тавышны сизүче музыкаль системалар бу тырышлыкларның кайберләре. Ләкин, бөтен технология, бу технологияләр өчен эшләгән меңнәрчә инженерга һәм специалистка карамастан, колак булдырган ачыклыктагы һәм сыйфатлылыктагы тавышка ирешә алмаган. Музыкаль җиһазлар җитештерү буенча иң беренче саналган ширкәт тарафыннан җитештерелгән иң сыйфатлы музыкаль центрны алыйк. Тавышны язган вакытында гел

тавышның бер өлеше югалыр яки әз дә булса комачау итүче тавышлар барлыкка килер яки музыкаль центрны кабызган вакытыгызда, әле музыка башламастан, чытырт иткәнен ишетерсез. Әмма, кеше гәүдәсендәге технологиянең продукты булучы тавышлар соңгы дәрәҗәдә ачык һәм кимчелексез. Кеше колагы һичбер заман, музыкаль центрдагы булганы кебек, чытыртлы яки комачау итүче тавышлар белән бергә тоемламас, тавыш ни исә, бөтен һәм ачык килеш аны тоемлар. Бу хәл кеше яратылган көннән алып бүгенгегә хәтле дәвам итә.

Хәзергегә хәтле адәм баласы ясаган һичбер күрү һәм тавыш җиһазы күз һәм колак кадәр сиземле һәм уңышлы тоемлаучы була алмаган.

Әмма, күрү һәм ишетү феноменында бөтен болардан тыш булучы тагын бер бик бөек хакыйкать бар.

## Ми эчендә күрүче һәм ишетүче кем ?

Ми эчендә якты, төсле дөньяны тамаша кылучы, симфонияләрне, кошларның сайрауларын тыңлаучы, гөлләрне иснәп хушланучы кем?

Кешеләрнең күзләреннән, колакларыннан, борыннарыннан килүче сиземләүләр электрик сигналлар булып мигә бара.

Биология, физиология һәм биохимия китапларында моның мидә ничек барлыкка килүвен аңлатучы күп кенә детальләр белән танышырсыз. Әмма, бу тема белән бәйле булган иң мөһим хакыйкатьне һичбер җирдә очрата алмассыз: мидә бу электрик сигналларны күрү, тавыш, ис һәм хис буларак тоемлаучы кем? Минең эчендә күзгә, колакка, борынга мохтаҗ булмыйча, бөтен боларны тоемлаган бер зиһен бар. Бу зиһенгә кем ия ?

Әлбәттә , бу зиһенне минең төзелешендә булучы нервлар, май катламы һәм нерв күзәнәкләре булдыра алмый. Менә шул сәбәптән, һәрнәрсәнең маддәдән гыйбарәт булганын исәпләүче дарвинист-материалистлар, бу сорауларга һичбер җәвап таба алмый. Чөнки бу зиһен – Аллаһ яраткан рух. Рух – күрү өчен күзгә, ишетер өчен колакка, уйлау өчен мигә мохтаҗ түгел.

Бу ачык һәм гыйльми хакыйкатьне укыган һәр кешенең, ми эчендәге берничә сантиметр кубтагы, кап-караңгы урынга бөтен галәмне өч үлчәмле, төсле, күләгәле һәм якты буларак сыйдыручы бөек Аллаһ турында уйланып, Аңардан куркып, Аңа сыенувы кирәк.

## Материализм дине

Югарыда җентекләнгәннәр эволюция теориясенең гыйльми ачышларга карата ачык рәвештә каршылыклы булганын күрсәтә. Теориянең тормышның килеп чыкканлыгын аңлатувы гыйлемгә каршы килә, аның тарафыннан белдерелгән “эволюция механизмнарының” һичбер эволюцияга китерерлек тәэсире юк һәм фосиллияләр бу теория кирәктергән ара

формаларның яшәмәгәнлекләрен күрсәтә. Бу хәлдә, әлбәттә, эволюция теориясенең гыйлемгә каршы килүче бер төшенчә буларак читкә атылувы кирәк. Тарих буенча, дөньяны космосның үзәге дип белдергән галәм моделе кебек, күп кенә төшенчәләр гыйлем көндәлегеннән чыгарылган. Әмма, эволюция теориясе зур теләк белән гыйлем көндәлегендә тотыла. Хәтта кайбер кешеләр теориянең критикасын "гыйлемгә һөҗүм" буларак та күрсәтергә тырыша. Ни өчен ?

Бу халәтнең сәбәбе, эволюция теориясенең кайбер тирәләр өчен үзеннән һичничек тә ваз кичә алмаслык догматик бер инану булувында. Бу тирәләр материалист фәлсәфәгә сукырларча бәйле һәм дарвивизмны да табигатьтәге нәрсәләрне аңлата алырлык бердәнбер материалист ачыклау булганы өчен хуплый. Кайвакыт моны ачык итеп белдерәләр. Гарвард унивеситетынын мәшһүр генетик һәм шулук вакыта алдынгы эволюционист Ричард Левонтин, "башта материалист, соңыннан галим" булганын шулай белдерә:

***"Безнең материализмга инанувыбыз бар, "априори" ( алдан кабул ителгән, дөрес дип саналган) инану бу. Безне дөньяга материалист ачыклау китерегә мәҗбүр итүче нәрсә гыйлемнең методлары һәм кануннары түгел. Киресенчә, материализмга булган "априори" бәйлелегебез сәбәпле, дөньяга материалист ачыклау китерүче эзләнү методлары һәм төшенчәләрне булдырабыз. Материализм абсолют дөрес булганы өчен, теологик берәр ачыклауның сәхнәгә керүвенә рөхсәт бирмиячәкбез."*** (Richard Levontin, "The Demon-Haunted World", The New York Review of Books, 8 нче январь, 1997, 28 нче бит).

Бу сүзләр, дарвинизмның материалист фәлсәфәгә бәйле булувы сәбәпле, яшәтелгән бер догма икенлегенә ачык буларак ишарәт итә. Бу догма маддәдән башка һичбер барлык булмаганын исәпләр. Шул сәбәпле, җансыз, зиһенсез маддәнең яшәешне яратувына инаныр. Миллионннарча аермалы җанлы төрләренең; үрнәк өчен кошларның, балыкларның, жирафларның, юлбарысларның, бөҗәкләрнең, агачларның, чәчәкләрнең, китларның һәм кешеләрнең маддәнең үз эчендәге тәэсирләре аркылы, ягъни яуган яңгыр, яшнәгән яшен сәбәпле, җаннсыз маддәнең эченнән килеп чыгувын кабул итәр. Чынлыкта исә, бу һәм акылга һәм гыйлемгә каршы килә. Ләкин, дарвинистларның үзләренең әйтеме белән әйткәндә, "теологик берәр ачыклауның сәхнәгә кермәве" өчен моны яклауны дәвам итәләр.

Җанлынарның килеп чыгышына материалистлар кебек "априори" итеп карамаган кешеләр исә, шул ачык хакыйкатьне күрәчәкләр: бөтен җанлылар өстен бер көч, белем һәм акыл иясе булган Яратучының әсәре. Яратучы – бөтен космосны юктан бар иткән, иң кимчелексез рәвештә ситемалаштырган һәм бөтен җанлыларны яратып аларга сүрәт биргән Аллаһ.

# ДӨНЬЯ ТАРИХЫНЫҢ ИҢ ТӘЭСИРЛЕ СИХЕРЕ – ЭВОЛЮЦИЯ ТЕОРИЯСЕ

Монда шуны да билгеләп үтәргә кирәк, ал - карарсыз, һичбер идеологиянең тәэсире астында калмыйча, барытик акылын һәм мантыгын кулланучы һәркеше, белем һәм мәдәнияттән ерак җәмгыятьләрнең хорафатларын хәтерләткән эволюцияия теориясенә иманувы мөмкин түгел икәнлеген җиңеллек белән аңлаячак. Югарыда белдерелгәнчә, эволюцияитеориясенә иманучылар зур берәр пробирка эченә атомнарны, молекулаларны, җансыз маддәләрне тутырган хәлдә, боларның кушылмасыннан заман эчендә фикер йөртүче, аңлаучы, ачышлар ясаучы профессорларның, университет студентларының, Эйнштейн, Хаббл кебек галимнәрнең, Фрэнк Синатра, Чарльтон Хостон кебек музыкантларның, моның белән бергә боланнарның, лемон агачларының, канәфер гөлләрнең чыгувына ышаналар. Өстәвенә бу уйдырмаларга иманучылар – галимнәр, профессорлар, мәдәниятле, мәгарифле кешеләр. Шул сәбәптән, эволюция теориясен "дөнья тарихының иң бөек һәм иң тәэсирле сихере" дип билгеләү бик урынлы. Чөнки кешеләрнең бу дәрәҗәдә акылларын башларыннан алган, акыл һәм мантык белән фикер йөртүләренә мөмкинчелек бирмәгән, күзләрен пәрдә белән каплаган кебек бик ачык булган хакыйкатьләрне күрүләренә комачау иткән тагын берәр башка инану яки өйрәтмә юк. Бу иске мисырлыларның кояш алласы Рага, Африкада кайбер кабиләләрнең тотемнарга, Сәбә халкының кояшка табынувыннан, Ибраһим пәйгамбәр (а.с) кавеменең үз куллары белән ясаган потларына, Муса пәйгамбәр (а.с) кавеменең алтыннан ясаган бозауларына табынуларыннан да бик күпкә хәтәр һәм акыл алмаслык сукырлык. Чынлыкта бу халәт, Аллаһ Көрьәндә – ишарәт иткән акылсызлык. Аллаһ кайбер кешеләрнең аңлаешлары томалачагын һәм хакыйкатьләрне күрмичә гаҗиз халәткә төшәчәкләрен күп кенә аятьлерендә белдерә. Бу аятьләрнең кайберләре шундый:

***Шиксез, инкяр итүчеләрне кисәтсәң дә, кисәтмәсәң дә алар өчен барыбер. Аллаһ аларның йөрәкләренә һәм колакларына тамга суккан; күзләрендә пәрдәләр бар. Һәм бөек газап аларныкы. (Бакара сүрәсе, 6-7).***

***... Йөрәкләре бар, алар белән төшенеп аңламаслар. Күзләре бар, алар белән күрмәсләр. Колаклары бар, алар белән ишетмәсләр. Болар хайваннар кебек, хәтта тагын да түбәнрәк. Менә болар гафиль булучылар. (Араф сүрәсе, 179).***

Аллаһ Һиҗр сүрәсендә исә, бу кешеләр хәтта могҗизаларны күрсәләр дә, инанмыйча тәкәбберләнәчәкләрен шулай белдерә:

***Аларга күк йөзеннән берәр ишек ачсак, аннан югары күтәрелсәләр дә, шиксез: Ккүзләребезгә нидер булды, белки без сихерләнгән бер туплылык",-диячәкләр. (Һиҗр сүрәсе, 14-15).***

Бу хәтле киң массага бу сихернең тәэсирле булувы, кешеләрнең хакыйкатьләрдән бу хәтле ерак тотылулары һәм 150 елдан бирле бу сихернең бозылмавы исә, сүз белән аңлатыла алмаслык, хәйран калдыручы

хәл. Чөнки берәр яки берничә кешенең була алмаган сценарияләргә, уйдырмалар һәм алогизмнар тулы нәрсәләргә ышануларын аңлап була. Әмма, дөньянын дүрт ягындагы кешеләрнең, зиһенсез һәм җансыз атомнарның очраклы берәр карары белән бер арага килеп, могҗизалы организацияне, дисциплинаны, акылны һәм зиһенне күрсәтүче, кимчелексез система белән эшләүче космосны, җанлылар өчен яраклы һәртөрле сыйфатларга ия булучы Дөнья планетасын һәм сансыз комплекслы системаларны үзендә ташучы җанлыларны барлыкка китергәннәренә ышануларын "сихердән" башка берәр нәрсә аркылы аңлатып булмый.

Шуңа да, Аллаһ Көрьәндә инкярчы фәлсәфәне яклаучы кайберәүләр тарафыннан ясалган сихерләрнең кешеләргә тәэсир иткәнлеген Муса пәйгамбәр (а.с) һәм фирьгавен арасында булган бер вакыйга аркылы безгә белдерә. Муса пәйгамбәр фирьгавенгә хак динне аңлатканда, фирьгавен Муса пәйгамбәргә (а.с) аның "белгеч сихерчеләре" һәм халык тупланачак җирдә каршылашуларын сөйләр. Муса пөйгамбәр (а.с) сихерчеләр белән карчылашкач, башта сихерчеләргә үзләренең белгәннәрен күрсәтүләрен әмер итә. Бу вакыйганы аңлатучы аять шулай:

***(Муса):"Сез атыгыз!",-диде. (Таякларын) атканнан соң, кешеләрнең күзләре сихерләнде, аларны дәһшәттә калдырдылар һәм (уртага) бөек сихер китергән булдылар. (Араф сүрәсе, 116).***

Күрелгәнче, фирьгавеннең сихерчеләре үзләре ясаган "алдатмалар" аркылы, Муса пәйгамбәр (а.с) һәм аңа иман иткәннәрдән башка, кешеләрнең һәммәсен дә сихерли алганнар. Әмма, аларның атканнарына каршы буларак, Муса пәйгамбәрнең (а.с) уртага салган дәлиле аларның бу сихерен тәэсирсез калдырган. Көрьәндә бу "уйдырмаларын йотты" дип китерелә:

***Без дә Мусага: "Асаңны (таягыңны) ат!"-дип вахый кылдык. (Ул да аткач) бер карадылар ки, ул бөтен уйдырганнарын җыя, туплап йота бирә. Шулай итеп хак урынын тапты, аларның бөтен эшләгәннәрен яраксыз кылды. Анда җиңелгән булдылар һәм түбәнсетелгәннәр буларак йөз асты калдылар. (Араф сүрәсе, 117-119).***

Аятьләрдә дә белдерелгәнчә, элеккеге заманнарда сихер аркылы халыкка тәэсир итүче бу кешеләрнең эшләгәннәре ялган икәнлеге аңлашылувы белән, югарыда әйтеп үтелгән кешеләр түбәнчелеккә төшкән. Хәзерге көндә дә, бер сихернең тәэсире сәбәпле, фән кыяфәтендә соңгы дәрәҗәдәге уйдырмаларга инанган һәм аларны яклар өчен тормышларын багышлаганнар, әгәр бу ялганнардан ваз кичмәсәләр, хакыйкатьләр бөтенлеге белән ачыкка чыккач һәм "сихер бозылгач" түбәнчелеккә төшәчәкләр. Шуңа да, якынча 60 яшенә чаклы эволюцияны яклаган һәм атейст фәлсәфәче булган, ләкин, соңыннан хакыйкатьләрне күргән Малколи Маггерайдж, эволюция теориясенең якын киләчәктә ни хәлдә булачагын шулай ачыклый:

***"Мин үзем эволюция теориясенең, бигрәк тә ул кулланылган аланнарда, киләчәкнең тарих китапларындагы иң бөек анекдот***

***булачагын аңладым. Киләчәк нәсел бу хәтле черек һәм билгесез гипотезаның ышана алмаслык акылсызлык белән кабул ителүвен хәйранлык белән каршылаячак”.*** (Malcolt Muggeridge, “The End of Christendom”, Grand Rapids: Eerdmans; 1980, 43 нче бит).

Бу киләчәк ерак түгел, киресенчә, бик якын киләчәктә кешеләр “очраклы сәбәпләрнең” иляһ була алмаганлыкларын аңлаячаклар һәм эволюция теориясе дөнья тарихының иң бөек уйдырмасы һәм иң көчле сихере буларак танылачак. Югары тизлек белән бу көчле сихер дөньякүләм рәвештә юкка чыга башлады. Эволюция алдатмасының серен өйрәнгән күп кенә кеше, бу алдатмага ничек килеп эләккәне турында хәйранлык һәм шашкынлык белән уйлана.

1. Sidney Fox, Klaus Dose, Molecular Evolution
and The Origin of Life, New York: Marcel Dekker, 1977, 2 бит
2. Alexander I. Oparin, Origin of Life, (1936)
New York, Dover Publications, 1953 (Reprint),
196 бит
3. "New Evidence on Evolu tion of Early Atmosphere and Life",
Bulletin of the American Meteorological
Society, 63 нче том, ноябрь 1982, 1328-
1330 битләр
4. Stanley Miller, Molecular Evolution of Life:
Current Status of the Prebiotic Synthesis of Small
Molecules, 1986, 7 бит
5. Jeffrey Bada, Earth, Şubat 1998, 40 бит
6. Leslie E. Orgel, The Origin of Life on Earth,
Scientific American, 271нче том, январь 1994, 78 бит
7. Charles Darwin, The Origin of Species: A Facsimile of the First
Edition, Harvard University Press, 1964, 189 бит
8. Charles Darwin, The Origin of Species: A Facsimile of the First
Edition, Harvard University Press, 1964, 184 бит
9. B. G. Ranganathan, Origins?, Pennsylvania: The Banner Of Truth
Trust, 1988
10. Charles Darwin, The Origin of Species: A Facsimile of the First
Edition, Harvard University
Press, 1964, 179 бит
11. Charles Darwin, The Origin of Species: A Facsimile of the First
Edition, Harvard University
Press, 1964, 172, 280 битләр
12. Derek A. Ager, "The Nature of the Fossil Record", Proceedings of
the British Geological Association,
87 нче том, 1976, 133 бит
13. Douglas J. Futuyma, Science on Trial, New
York: Pantheon Bo oks, 1983. 197 бит
14. Solly Zuckerman, Beyond The Ivory Tower,
New York: Toplinger Publications, 1970, 75-
94 битләр ; Charles E. Oxnard, "The Place of Australopithecines in
Human Evolution: Grounds for Doubt", Nature, 258 том, 389 бит
15. J. Rennie, "Darwin's Current Bulldog: Ernst Mayr", Scientific
American, декабрь1992

16. Alan Walker, Science, 207 том, 1980, бит 1103; A.
J. Kelso, Physical Antropology, 1. басым, New
York: J. B. Lipincott Co., 1970, 221 бит; M. D. Leakey, Olduvai Gorge,
3 нче том, Cambridge: Cambridge University Press, 1971, 272 бит
17. Time, ноябрь1996
18. S. J. Gould, Natural History, 85 нче том, 1976, 30 бит
19. Solly Zuckerman, Beyond The Ivory Tower,
New York: Toplinger Publications, 1970, 19 бит
20. Richard Lewontin, The Demon-Haunted
World, The New York Review of Books,
январь 9, 1997, 28 бит
21. Malcolm Muggeridge, The End of Christendom, Grand Rapids:
Eerdmans, 1980, 43 бит

***... Син Бөек, безгә өйрәткәнеңнән башка безнең һичбер белгәнебез юк. Чыннан да, Син һәрнәрсәне белуче, хөкем һәм хикмәт иясе. (Бакара сүрәсе, 32).***